## СӘНӘКНЕ – МЫЛТЫККА?

Авыл хуҗалыгында якынча 10 меңләп хезмәткәр бронь алырга хокуклы

> 5

## КЫЗЫК АВЫЛ

Түбән Биш халкы ырымнарга ышана, гадәтләрне онытмый

> 15

## ЕЛАТМАСЫН ЖЫР

Бүгенге вазгыятьтә концертлар куеп, җырлап йөрү кирәкме?

> 18


# ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 147 (28920) | Җомга | 7 октябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

# КЕМГӘ – НӘРСӘ?

## МОБИЛИЗАЦИЯ ТУРЫНДАГЫ СОРАУЛАРГА ҖАВАПЛАР

**Россиядә өлешчә мобилизация игълан ителгәнгә ике атна узды. Шушы вакыт эчендә Татарстанда берничә мең ир-егет хәрби хезмәткә чакырылды. Әмма хәрби кием киделәр дә бетте түгел. Мобилизация буенча бик күп сораулар килеп чыкты. Кемнәр китә, кемнәр кала, ничек түлиләр? «ВТ» китүчеләр генә түгел, аларның өйдә калган якыннарын да борчыган төп сорауларга җавапларны барларга тырышты.**

> 7

### Ишетми калмагыз

Президент Рөстәм Миңнеханов Татарстан Дәүләт Советына еллык Юлламасы белән 20 октябрьдә мөрәҗәгать итәчәк. Бу хакта Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты утырышында хәбәр иттеләр. Республиканың эчке һәм тышкы хәле турындагы еллык юллама VI чакырылыш Татарстан Дәүләт Советының 35 нче утырышында җиткереләчәк. Утырыш Салих Сәйдәшев исемендәге Дәүләт зур концерт залында узачак. Сүз уңаеннан, Рөстәм Миңнеханов депутатларга беренче Юлламасы белән 2010 елның 13 октябрендә мөрәҗәгать иткән иде.

Хәзерге вакытта республика юлларында кагыйдә бозу очракларын терки торган 897 видеокамера эшли. Татарстанның ЮХИДИ идарәсе хәбәренә караганда, ел ахырына кадәр тагын 88 комплекс урнаштырырга ниятлиләр. Камералар санын «Имин һәм сыйфатлы юллар» федераль проекты, шулай ук «2014–2025 елларда Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» программасын тормышка ашыру кысасында арттыралар.

Россиядә кулланылышка тапшырылган торак күләме арткан. Бу хакта Россия Премьер-министры Марат Хуснуллин үзенең «Телеграм» каналында язган. Хәбәрдә әйтелгәнчә, 2022 елның соңгы тугыз аенда, узган елның әлеге чоры белән чагыштырганда, кулланылышка тапшырылган торак күләме 21 процентка, ягъни 75,9 млн квадрат метрга арткан. «Әлеге саннар яңа рекорд кую мөмкинлегенә өметләндерә», – дигән ул. Татарстанда сентябрь башында кулланылышка тапшырылган торак күләме 2,5 млн квадрат метрга җиткән. Бу – еллык планның 91 проценты.


## Сөенечле хәбәр!

**2022 елның 3–13 октябрь көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!**

**П2435** җомга саны — Ташламалы бәя **444 сум 54 тиен**, гадәти бәясе – ~~512 сум 70 тиен~~

**П2409** атнага дүрт тапкыр чыга — Ташламалы бәя **980 сум 10 тиен**, гадәти бәясе – ~~1143 сум 96 тиен~~

Реклама 16+

Фараз

# Бюджет имтихан тотачак

**Хөкүмәт йортында киләсе елның бюджетын карадылар. Аны икътисади билгесезлек шартларында планлаштырырга туры килә.**

Шулай итеп, бюджетны дефицитлы итеп ясарга уйлыйлар, ягъни чыгымнар керемнәрдән 27 млрд сумга күбрәк булачак. Шул ук вакытта бюджетның 80 процентка якыны социаль өлкәгә тотылачак.

– Ел саен федераль законга үзгәрешләр кертү, бер яктан, керемнәр базасын киметә, икенче яктан – безнең бюджетның чыгымнар өлешен арттыра. Нәтиҗәдә республика бюджеты нык авырлаша. Киләсе 3 ел бюджеты менә шундый гадәти булмаган шартларда формалашты, – диде финанс министры Радик Гайзатуллин.

Аның сүзләре буенча, 2023 ел һәм 2024–2025 елларга бюджетны соңгы ярты елда эшләгәннәр.

Шулай итеп, республика 333,9 млрд сум керем алырга һәм 361 млрд сум чыгым планлаштыра. «Беренче чиратта эшли торган һәм социаль әһәмияткә ия булган чыгымнар саклана. Киләсе елның планлы бюджетында алар гомуми чыгымнарның 80 процентын тәшкил итәчәк», – диде Радик Гайзатуллин. Аның сүзләренчә, узган елларда башланган социаль-мәдәни өлкә һәм җәмгатьчелек инфраструктуралары төзелешләре һәм капиталь ремонтлар дәвам итәчәк. Шулай ук социаль әһәмияткә ия булган чаралар да игътибар үзәгендә булачак. Моннан тыш, яңа бюджет оешмалары төзү, резерв фондны формалашу, юлларны карау, авылларга грантлар бирү, кешеләрнең үзара салым акчасын үзара финанслауга да акча бүлеп бирелячәк.

Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов сүзләренчә, республика үз мөмкинлекләре буенча яши.

– Безнең бюджет керемнәр буенча да, чыгымнар буенча да тигез. Президент бит юкка гына тулай төбәк продуктын 5 триллион сумга җиткерү бурычын куймады. Бу республикага 500 млрд сум үз керемен бирәчәк, – диде Марат Әхмәтов.

Аның сүзләренчә, шушы күрсәткечкә ирешкән очракта, алга куелган бурычларны үтәргә мөмкинлек булачак. Шулай ук ул республиканың социаль-икътисади үсеш фаразы «бик көчле оптимизмга ия» булуын да ассызыклады.

– Бу безнең икътисад һәм бюджет өчен имтихан булачак. Куелган бурычларны үтәп чыгарга язсын, – дип теләде Марат Әхмәтов.

# ЯҢА ТОРМЫШ ТӨЗҮЧЕДӘН БАШЛАНА

tatarstan.ru

**Бу көннәрдә Казан төзүчеләр башкаласына әйләнде. Чәршәмбе көнне «Казан Экспо» халыкара күргәзмә үзәгендә II халыкара төзелеш чемпионаты ачылды. 8 октябрьгә кадәр дәвам итәчәк чарада 2 меңгә якын кеше катнаша, алар арасында егерме илдән килүчеләр дә бар.**

Ачылыш тантанасы башланганчы Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Россия төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Ирек Фәйзуллин, «Росатом» дәүләт корпорациясе генераль директоры Алексей Лихачев һәм башка кунаклар чемпионат кысасында оештырылган күргәзмәне карадылар.

Рөстәм Миңнеханов мондый халыкара чараның нәкъ менә Казанда узуын зур дәрәҗә дип билгеләп узды.

– Яхшы якка үзгәрешне барыбыз да ярата, әлбәттә. Кая гына барсак та, юлының нинди булуын, анда эш урыннары бармы-юкмы икәнлеген карыйбыз. Ә бит боларның барысын да төзүчеләр башкара! Алардан башка тормышны берничек тә үзгәртеп булмас иде. Шуңа күрә сез иң кирәкле һөнәрне сайлагансыз, – дип мөрәҗәгать итте Рөстәм Миңнеханов, чемпионатта катнашучыларны сәламләп. – Сездән башка беркем дә бернәрсә дә эшли алмаячак. Хөрмәтле төзүчеләр, бу чемпионат сезгә үзегезне күрсәтергә мөмкинлек бирәчәк. Мондый күнекмәләргә һәм сәләтләргә ия булу – киләчәктә яхшы өстенлекләргә ия булу дигән сүз.

Чарада Россиянең төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Ирек Фәйзуллин да чыгыш ясады. «Төзелеш чемпионатын оештыруга да, «Казан Экспо» халыкара күргәзмә үзәгендәге Илһам Шакиров исемендәге бу матур залны төзүдә дә катнашым барлыгы белән горуранам», – диде ул.

Ирек Фәйзуллин ассызыклаганча, бүген төзүчеләр бик зур күләмдә бурычлар башкара. Төзелеш тармагы санкция шартларында яңа әһәмияткә ия: бу – предприятиеләрнең эшлисе эшләре күп булу да, эш урыннары да дигән сүз.

– Без Татарстанда башкарыла торган төзелеш эшләренең күләмен күрдек. Мин монда эшләгәндә ул 360 млрд сумны тәшкил итә иде, хәзер тагын 100 млрд сумга артты, – дип билгеләп узды.

Ирек Фәйзуллин шулай ук II Халыкара төзелеш чемпионатында 5 чит ил делегациясе – Әрмәнстан, Казахстан, Беларусь, Төрекмәнстан, Азәрбайҗан булуын да искәртте. Ул барлык катнашучыларга да җиңү теләде.

«Росатом» дәүләт корпорациясе генераль директоры Алексей Лихачев Татарстанга кунакчыллыгы өчен рәхмәт белдерде.

– Казан профессионаллар алдында үз ишекләрен беренче тапкыр гына ачмый, – диде ул. – Бу безнең өчен бик мөһим. Чемпионатта җиңүгә ирешер өчен бөтен көчне һәм бөтен осталыкны бирергә кирәк. Бүген бу залда утырган катнашучыларга, үз һөнәре итеп төзелешне сайлаган студентларга һәм төзелеш отрядлары вәкилләренә – җитди, бәлки, тормышының иң мөһим мәктәбен үтүчеләргә иң җылы сәламләү сүзләрен җиткерәм. Һәм, әлбәттә, төзүчеләрнең барысына да – үз куллары, акылы һәм йөрәге белән илебезне төзүчеләргә рәхмәт. Алар аерым объектлар да, яңа суверен Россияне дә төзи. Илебезнең киләчәге сездән тора.

## ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

**Рөстәм Миңнеханов «Алтын көз – 2022» бөтенроссия агросәнәгать күргәзмәсендә катнашты. Татарстан экспозициясен Россия Хөкүмәте Рәисе Михаил Мишустин да килеп күрде.**

Рөстәм Миңнеханов аңа республика авыл хуҗалыгы тармагындагы күрсәткечләр турында сөйләде. Татарстанда – 5 млн тоннага якын ашлык, 1,65 млн тонна шикәр чөгендере, 800 мең тоннадан артык бәрәңге һәм 260 мең тонна яшелчә җыеп алынган. Терлекчелек тармагына федераль ярдәм чаралары турында да сөйләштеләр. Субсидияләр хисабына хуҗалыклар саны арткан, агымдагы елда 16 мең баш мөгезле эре терлеккә исәпләнгән 14 объект төзелгән. Ел ахырына кадәр тагын 6 ферма ачылачак. «Безнең фермерлар ярдәм чараларыннан актив файдалана. Нәтиҗәдә республикада 2 млн тоннага якын сөт савып алына. Бу – илебездәге иң югары күрсәткеч», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Күргәзмәдә Татарстан Президентына Җир сөрү буенча Россия ачык чемпионатының рәсми символын тапшырдылар. Әлеге ярыш киләсе елда бездә узачак.

***

**Рөстәм Миңнеханов «Динамо – Ак барс» чирәмдәге хоккей клубын Россия чемпионы булып танылулары белән котлады.**

Татарстан командасы әлеге титулны 20 нче мәртәбә яулады. Моннан тыш, «Динамо – Ак барс» быел Россия Кубогы һәм Суперкубогын да отты. «Бу – бөтен Татарстан спорты өчен зур уңыш. Пьедесталның иң югары баскычы – бөтен коллективның планлы, максатчан эш нәтиҗәсе», – диде Президент һәм команда җитәкчелегенә, уенчыларга, тренерлар составына, шулай ук республиканың чирәмдәге хоккей федерациясе җитәкчелегенә, клуб спонсорларына рәхмәт әйтте.

# КАДЕРЛӘП САКЛАРГА

**Мин кулыма китап алам**

**Китап һәм аның әһәмияте турында ешрак сөйләшергә кирәк. Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев китапханә фондларына багышланган халыкара конференцияне әнә шундый сүзләр белән ачып җибәрде. Ә чара башланыр алдыннан Татарстан Милли китапханәсенә шәхси фондыннан дүрт меңләп китап бүләк итте.**

Гади китаплар гына түгел алар. Һәркайсы – үзе бер тарих. Шул китаплардан җыелган күргәзмә белән таныштырганда, Минтимер Шәймиев хатирәләрен яңартты. Аларның барысы диярлек авторы яки бүләк итүчесе тарафыннан имзаланган. Китапларның беренче битләрендә шагыйрә Белла Әхмәдуллина, шахматчы Анатолий Карпов, космонавт Алексей Леонов, волейболчы Екатерина Гамова, язучылар Чыңгыз Айтматов һәм Олжас Сөләйманов кебек шәхесләрнең Татарстанның Беренче Президентына багышлап язган җылы сүзләре дә урын алган. Теләгән һәр кешенең, Милли китапханәгә килеп, бу китаплар белән танышу мөмкинлеге бар. Якын киләчәктә бу исемлекне тагын бер мең китап тулыландырачак, дип вәгъдә бирде Минтимер Шәймиев.

Бу китапларны ул «Бизнес, хакимият һәм җәмгыятьнең китаплар сакланышын тәэмин итүдә фонд саклаучылар белән хезмәттәшлеге» дип аталган халыкара конференция алдыннан тапшырды. Ике көнлек чарада китапханә, музей, архив, фәнни-тикшеренү, белем бирү оешмалары җитәкчеләре, коммерцияле булмаган оешмалар вәкилләре китап саклауга бәйле проблемалар турында фикер алышты.

– Моңарчы без матди мирасыбызны кайгырттык. Шәһәр кадәр шәһәрләр торгыздык. Борынгы шәһәрләребезнең кыйммәтен ЮНЕСКО да таныды. Инде хәзер рухи кыйммәтләребез турында уйлар, рухыбызны кайгыртыр чак җитте. Безгә китаплар һәм аларның

әһәмияте турында ешрак сөйләшергә кирәк. Чөнки алар – күренекле галимнәрнең, фәлсәфәчеләрнең, әдәбиятчыларның белем чыганагы, хезмәтләре, киләчәккә мирас итеп калдырган ядкарьләре, – диде Минтимер Шәймиев, катнашучыларны сәламләп. – Мәктәптә укыганда район үзәгендә урнашкан китапханәдәге бөтен китапны укып бетергәнем хәтердә. Безнең авылдан чакрым ярым гына ераклыкта иде ул. Күз ачкысыз буранда да шунда чаба идек. Гомумән, китапханәләр кеше язмышында зур роль уйнады һәм уйнаячак та.

Конференциянең максат-бурычлары турында Россия Дәүләт китапханәсе генераль директоры Вадим Дуда сөйләде.

– Дәүләт инде күп еллар буе китапханәләргә һәм китапханә фондларының сакланышына ярдәм итеп килә. Бу эшнең чын мәгънәсендә дәүләтнең мөһим бурычына әйләнүе сөендерә, әлбәттә. Ләкин мәдәниятнең бу тармагы җәмгыять, хакимият, бизнесның да ярдәмен таләп итә. Миңа калса, әлеге конференциянең темасы гаять актуаль. Соңгы арада без бизнес, сәяси эшлеклеләр тарафыннан игътибарның артуын күрәбез. Бу өлкәдәге тәҗрибәбез, уңышлы алымнар турында башкаларга да сөйләр вакыт җитте. Китапханәләр бизнес, хакимият һәм җәмгыять белән берлектә эшләгән очракта гына без мәдәни мирасыбызны киләчәк буынга тапшыра алачакбыз, – диде ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

**САН**

Хәзерге вакытта Россия төбәкләре фондларында 12 миллионнан артык сирәк китап һәм документ саклана. Шуларның өч миллионнан артыгын яңартырга (реставрацияләргә) кирәк.

**Дәүләт Советында**

**Бөтенроссия дәүләт юстиция университетының Казан институтында (РФ Юстиция министрлыгының Россия хокук академиясе) хакимият органнарының коммерциячел булмаган оешмалар белән үзара хезмәттәшлеге турында фикер алыштылар.**

Россия Юстиция министрлыгының 220 еллыгына багышлап оештырылган илкүләм фәнни-гамәли конференциядә катнашучыларны республика җитәкчелеге исеменнән Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин сәламләде.

Аның сүзләренә караганда, бу вакыйга Татарстан өчен аеруча әһәмиятле, чөнки Россия юстициясенең беренче министры, күренекле дәүләт эшлеклесе һәм атаклы шагыйрь Гавриил Романович Державин Казан губернасының Сокуры авылында туып-үскән. Фәрит Мөхәммәтшин конференциядә күтәрелгән мәсьәләләрнең дә көн кадагында булганын әйтте. «Республика хакимияте органнары өчен гражданлык җәмгыяте институтлары белән хезмәттәшлек һәрвакыт өстенлекле булды», – диде ул. Хәзерге вакытта Татарстанда социаль, мәдәни, яшьләр, экология һәм башка өлкәләрдә эшләүче 6 меңнән артык коммерциячел булмаган оешма теркәлгән.

Дәүләт Советы Рәисе фикеренчә, коммерциячел булмаган оешмалар белән эшне муниципаль дәрәҗәдә ныгытырга кирәк. Халык өчен мөһим программаларны һәм проектларны уңышлы гамәлгә ашыру шуңа бәйле.

# КҮПНЕ КҮРСӘТТЕ

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘГЕ ӘДӘБИ ӘСӘРЛӘРГӘ БӘЙГЕ БЫЕЛ ДА УЗАЧАК

**Татар әдәбиятын яңа биеклеккә күтәрәбез. Әдәби тәнкыйть тә читтә калмаячак. Президент каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәмендә инде икенче мәртәбә үткәрелә торган әдәби бәйгегә быел да зур өметләр баглыйлар.**

Әлеге бәйге нинди максаттан үткәрелә? Бу сорауга матбугат очрашуында Татарстанның Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла җавап бирде.

– Узган елгы бәйгегә 1500ләп әсәр килде. Бу – әдәбиятыбыз яши һәм үсә дигән сүз. Бүген безгә ничек тә бөек язучыларыбыз ирешкән биеклекне сакларга иде. Ул биеклекне югалтмау бик зур уңыш булачак, – диде ул.

Ркаил Зәйдулла быелгы бәйгенең үзенчәлекләре турында да сөйләде. Быел җәмгысы 10 номинация буенча әсәрләр кабул ителә. Номинацияләр исемлегенә әдәби тәнкыйть мәкаләсе һәм рецензия дә өстәлгән.

– Без, татарда әдәби тәнкыйть өлкәсе аксый яки бөтенләй юк, дияргә күнеккән. Әйе, китап чыккан уңайдан гына сирәк-мирәк рецензияләр күренгәли анысы, ләкин барысына да түгел. Заманында Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев, ниндидер яңа әсәр чыкса, кечкенә генә мәкалә белән булса да, шундук мөнәсәбәтен белдерәләр иде. Бүген безгә әлеге жанрга кызыксындыру уятырга кирәк, – диде Язучылар берлеге рәисе.

Әдәби бәйгедә катнашу өчен татар телендә язылган, моңа кадәр массакүләм мәгълүмат чараларында, төрле җыентыкларда басылмаган әсәрләр генә кабул ителә. Мәгълүм булганча, бәйгедә катнашучылар әсәрләрен тәхәллүс белән җибәрергә тиеш. Авторның исеме җиңүчеләрне игълан иткәндә генә билгеле булачак. Тагын бер яңалык – быел бер автор бер генә тәхәллүс белән катнаша алачак.

– Авторларның кем булуы кызык та, мөһим дә түгел. Без әсәрләр белән эшлибез. Гомер буе шушы өлкәдә «кайнагач», авторларның стилен чамалыйсың инде ул. Төгәл әйтеп булмаса да, барыбер сиземлисең. Тик үз стиле булган язучылар күп түгел, берничә генә. Әсәр уңышлы булса да, аның үз стиле бар дигән сүз түгел әле. Язучының мөмкинлекләре әсәрендә күренә. Явызмы ул, киң күңеллеме, белемлеме, надан кешеме – әсәрендә чагыла, – диде Ркаил Зәйдулла.

«Казан утлары» журналының баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин фикеренчә, узган елгы бәйгедә җиңмәгән әсәрләр дә журналда басылырга лаеклы.

– Проза һәм шигърият жанрларында җиңгән әсәрләр гыйнвар аеннан бирле «Казан утлары»нда авторларының фамилияләре белән басылып килә. Җиңмәгән әсәрләрне дә карап, укып барабыз. Күбесе «Казан утлары»нда басылырга лаеклы. Бу безне бик сөендерә. Аларны да бастырачакбыз. Башка газета-журналларга да таратабыз, – диде ул матбугат очрашуында.

Узган бәйгедән соң әсәрләрнең авторлык хокуклары мәсьәләсе берникадәр бәхәс уяткан иде. Моңа Рөстәм Галиуллин ачыклык кертте:

– Авторлар үз хокукларын югалтмый. Бердәнбер шарт – автор исеме янына әсәрнең бәйгедә җиңгәнен белдерә торган тамга кую, – дип аңлатты ул.

Әдәбият галиме Дания Заһидуллина фикеренчә, әлеге бәйге татар әдәбияты турындагы карашларны уңай якка үзгәрткән.

– XX–XXI гасырлар чигендә татар әдәбиятын шактый тәнкыйтьләп килдек. Аның үткәне, авыл тормышыннан ерак китә алмавы, заманча проблемаларны аз яктыртуы, үсмерләр өчен әсәрләрнең аз булуы һәрдаим әйтелә торган төп кимчелекләр иде. Узган елгы бәйге безгә татар әдәбиятының потенциалы зур булуын, заманча темаларга алынучы, үсмерләрне дә канәгатьләндерерлек әсәрләр язучы әдипләребезне күрсәтте, – диде ул.

Дания Заһидуллина, әсәрләрне бәяләгәндә, иң беренче чиратта нәрсәгә игътибар итүләрен атады. Болар – әсәрнең укылышлылыгы, заманча булуы һәм аның дөнья әдәбиятында барган процесслар, яңалыклар белән аваздашлыгы. Ркаил Зәйдулла исә әсәрнең чын татар әдәби телендә язылуының мөһимлеген, татар халкының милли үзаңын үстерүгә өлеш кертергә тиешлеген искәртте.

– Әсәрне укыгач, кеше я «Нишләп без болай соң әле?» дигән әрнү кичерергә, я «Без бит – бөек халык, без алга барырга тиеш!» дигән өмет һәм горурлык хисе тоярга тиеш. Бу – бик югары максат инде. Ләкин бу максатка омтылырга кирәк, – диде ул.

Ләйсән САФИНА

Әдәби бәйге җиңүчеләренә акчалата призның гомуми күләме – 3 миллион 895 мең сум. Быел бәйгенең номинацияләре – «Роман», «Повесть», «Хикәя», «Поэма яки шигырьләр шәлкеме», «Повесть (үсмерләр әдәбияты)», «Хикәя (үсмерләр әдәбияты)», «Поэма яки шигырьләр шәлкеме (балалар һәм үсмерләр әдәбияты)», «Хикәя (балалар әдәбияты)», «Кыска драма әсәрләре, скетчлар (балалар әдәбияты)», «Әдәби тәнкыйть мәкаләсе, Рецензия». Романнар – 2023 елның 1 декабренә, башка номинацияләрдәге әсәрләр 2023 елның 1 сентябренә кадәр кабул ителә.

Әйтеп кенә бактым

# *Тиле күке*

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Быел дачада сентябрь беткәнче яшәргә хыялланган идек. Җәйнең соңгы ае бик эссе булгач, җәй кызуы озакка сузылыр дип уйладык. Әмма быел табигать саташты.

Бу саташу кош-кортларга да күчте кебек. Сентябрь урталары узгач, күке тавышы ишеттем. Туктап-туктап өч мәртәбә кычкырды бу. Әллә ялгыш ишеттем микән дип, аллеяга чыктым. Күршеләр килмәгән иде, шуңа күрә үткән-сүткәннәрдән: «Күке кычкырганын ишеттегезме?» – дип сораштыра башладым. Кайберәүләр иңнәрен генә сикертте. Берничәсе: «Вроде куковала», – диделәр. Бу вакытта күке кычкырамыни, дип артык игътибар итмәгәннәр.

Үзем колактан зарланмыйм, ишетү сәләтем гаҗәп дип мактана да алам. Ни дисәң дә, университетның татар хорында биш ел җырлап йөргән кеше бит! Хорда һәр партияне тыңлый-ишетә белергә кирәк.

Өйгә кердем дә интернеттан күке турында мәгълүмат эзли башладым. Ни гаҗәп, без җырларда җырлаган күкене «паразит кош» дип язып куйганнар. Кәеф китте. Рифкать Закиров сүзләренә Ренат Еникеев иҗат иткән «Кәккүк моңнарын тыңларга» дигән җыр бар. Аны Римма Ибраһимова гаҗәп матур итеп башкара, аны тыңлаганда, күкене сандугачтан да матур сайраучы моңлы кош итеп күз алдына китерәсең. Баксаң, күке, кайбер кошларны куркытып ояларыннан китәргә мәҗбүр итү өчен, әллә нинди тавышлар чыгарып та кычкыра ала икән. Кыскасы, «кеше җилкәсе»ндә яшәүче бер ерткыч инде. Кайбер сирәк тәрләрен исәпкә алмаганда, үзе оя да ясамый. Чит ояда күкәй сала да, «шуның белән шул Сәлахиев Мәхмүт». Балалары да аналарыннан ерак китми, йомыркадан иртәрәк чыга да хуҗа кошның балаларын этеп-тәртеп, оядан төшерә икән.

Вакытсыз кычкырган күке күңелгә шом да сала әле. Сатай-матай сөйләшкән кешегә без «тиле күке» дип әйткәлибез. Әмма күке тиле була алмыйдыр ул. Аны табигатьнең үзгәрешләре генә саташтыргандыр дип уйлыйм. Минем: «Әгәр күке вакытсыз кычкырса, берәр күңелсезлек көт тә тор», – дип әйткәннәрен дә ишеткәнем бар. Кайчак, бүген бөтен дөньясы тилерә, акылдан шаша кебек тә тоелып китә. Кешедә күңел тынычлыгы югалды. Психолог ярдәменә мохтаҗлар саны артканнан-артуы турында укып-ишетеп торабыз.

Бер уйлаганда, монда Казансу буендагы агачлыкта саташып кычкырган нәни генә кошның гаебе юктыр. Шул ук вакытта кошлар, җәнлек-җанварларның бәхетсезлек киләсен кешедән алдарак сизүе дә хак бит.

Аптыраганнан әйтү инде. Арабызда тиле күкеләр артмагае дип тә шикләнәм. Бар тереклекнең үз-үзен тотышы үзгәрү табигатькә бәйле булган кебек, җәмгыятьтәге үзгәрешләр дә адәм баласының яшәү рәвешенә йогынты ясамый калмый. Минем дача янындагы агачлыкта күкенең шулай вакытсыз кычкыруы безгә берәр кисәтү, хәбәр булмады микән, дип тә уйлап куям. Ярар, күке турында бүтән язмыйм, бөтенләй мистикага бирелә башладым бугай. Янында берәр кеше булмаса, вәсвәсәгә бирелү бик ансат икән ул.

Үзем дә сизмичә: «...ялгыз кайгы кайгымыни, илгә кайгы килмәсен...» – дип җырлап җибәрдем. Ну бу тиле күкене, шайтан вәсвәсәсенә кертеп җибәрә язды бит, Аллам сакласын!

Әгәр әни берәр ялгыш сүз әйтсә, әти аңа: «Әй, тиле күкем!» – дия иде. Яратып әйтә иде ул аны, әниемнең иңеннән дә сыйпап куя иде.

Сентябрь ахырында кычкырган күкене сыйпап, минем дә: «Әй, тиле күкем!» – дип әйтәсе килеп китте. Бит башыбызга төшкән бөтен бәлаләрдә без үзебез гаепле. Ярый әле бөтенләй коелып төшмәскә тырышабыз. Ходайдан илгә иминлек, җитәкчеләребезгә зирәклек, акыл бирүне сорап, сугышлар гына булмасын, дигән теләкләр теләп яшәп ятабыз. Ә син, күке, безгә матур таңнар, матур көннәр сана, озаклап сана! Ярты юлда туктап калма.

# ГЛИЦИН КОТКАРЫРМЫ?

Яңалыклар тасмасы безгә гел күңелсез хәбәрләр алып килә. Россиядә соңгы өч атнада тынычландыргыч препаратлар сату 10 процентка арткан әнә. Валериана экстракты, глицин һәм корвалол иң күп сатылган дарулар икән.

Мәсьәләнең бит шундый ягы да бар: кешеләр болай да соңгы ике-өч ел эчендә психологик дискомфорт кичерә һәм антидепрессантларны күп эчә иде. 10 процентка арту – болай да күп кулланылган дарууларның тагын да күбрәк кулланылуы ул. Соңгы ике атнада эчкечелек дәрәҗәсенең кискен югарыга күтәрелүе дә сер түгел. Газетабыз сайтыннан «Татарстанда үз-үзенә кул салучылар арта» дигән хәбәрне ачып та тормыйм. Авыр, билгеле. Социаль челтәрләрдә кешеләр сагышлы, төшенкелек һәм ачыргалану белән тулы постларны ешрак урнаштыралар. Автор үзе дә кайчакларда «Төшме болар барысы да, өнме?» дигән сорау белән төннәрен еш уяна. Әмма антидепрессантлар юк минем аптечкамда, спиртлы эчемлекләрне бөтенләй кулланмыйм.

Кешеләр матди югалтуларга бик игътибар итми хәзер. Алар ничектер үзеннән-үзе арткы планга күчте. Яңа йорт төзү шатлыгы шатлык булудан туктады. Әйе, әйе, әле кайчан гына кешеләрне хезмәт хакының кечкенә булуы, затлы машинага акча җитмәү, фатирның тар булуы күңелсезләндерә иде. Болар барысы да кечкенә нәрсәләр булып калды. Депрессия тынычландыргыч дарулар сәүдәсендә генә түгел, базарларда да күзәтелә. Сәүдә үзәкләренә килүчеләр кискен кимеде, диләр. Бердән, матди як кысылы, икенчедән, урамда һәм кеше күп җыелган урыннарда хәрби комиссариат вәкилләре тотып алып, повестка өләшә, дигән курку яши. Патриотизм дәрәҗәсе никадәр генә югары булмасын, кешеләр үзләрен яисә якыннарын мобилизацияләнүчеләр сафында күрергә теләми. Мобилизациядән азат ителүчеләр темасы матбугатта да еш күтәрелә, чөнки кызыксыну зур, укучылар санын күп җыя. Газета хәбәрчесе Смоленск өлкәсендә хәрби сәнәгать комплексы предприятиеләрендә вакансияләр калмау турында хәбәр алды. Хезмәт хакы зур булганга түгел, бронь алу өмете белән шунда омтыла ирләр. ТАСС, хәтта онлайн сәүдә әйләнеше дә 94 процентка түбәнәйде, кешеләр деликатеслар сатып алудан туктадылар, ди. Бу инде – җәмгыятьнең тоталь депрессиягә бирелү нәтиҗәсе.

Күңелсез һәм шомлы хәбәрләр исемлеген дәвам иттерергә була, билгеле. Әмма безнең максат бүтән. Куркыту түгел, ә «Куркудан ничек арынырга?» дигән сорауга җавап эзләү өчен тоттык кулга каләмне. Глициннар, корвалоллар озак сроклы стресслар вакытында булышмый диярлек. Беренчесе, гомумән, антидепрессант түгел. Кешеләр никтер аны тынычлану өчен куллана. Хисләр һәм уйларны идарә итәргә өйрәнмәсәк, без бөтенләй сәламәтлегебезне эштән чыгарып ташлаячакбыз. Иммунитет бетәчәк, йогышлы чирләргә тиз бирешәчәкбез, нерв авырулары да озак көттермәячәк. Организмның бөтен системасы безнең рухи халәтебезгә тыгыз бәйләнгән. Тынычсызлык һәм төшенкелек озак дәвам итсә, чирләрнең тулы бер бәйләме гарантияләнгән. Шуңа күрә, әйдәгез, үзебезне кулга алабыз.

Куркудан арыну өчен, аның анатомиясен карыйк. Нәрсәнеңдер төзелешен белдеңме, аның зыянлы тәэсирен туктату өчен, мөһим бер өлешен алып ташлау да җитә. «Куркынычны көтү инде килеп җиткән куркынычка караганда дәһшәтлерәк, золым көтү золымның үзенә караганда ун мең тапкыр начаррак», – ди Даниель Дефо. Бу хакта рус әйтеме дә бар: «Лучше ужасный конец, чем бесконечный ужас». Нәтиҗә ясыйк: кешене бәхетсезлек үзе түгел, аны хәвефләнеп көтү ныграк газаплый. Димәк, шомланудан туктау мөһим. Юк, сүз ваемсызланып йөрү турында түгел. Бәхетсезлектән коткара торган нииндидер адымнар ясау мөмкинлеге бар икән, аларны һичшиксез ясарга кирәк. Гамәлне кылабыз һәм нәтиҗәсен Аллаһка тапшырабыз. Аллаһ ихтыярыннан башка һичбер нәрсә булмый. Сиңа нииндидер хәсрәт ирешкән икән, бу – сынауның бер төре. Сынау дөньясында яшибез һәм авырлыклар белән сыналып тору – бу дөнья өчен гадәти күренеш. Әмма Аллаһ адәм баласына аның көче җитми торган сынауны бирми. Авырлык белән сыналганда иң файдалысы – сабырлык. «Сабырлык һәм җиңү – игезәк туганнар. Җиңү сабырлык белән килә, җиңү белән котылу килә, авырлыктан соң – җиңеллек», – ди изгеләрнең берсе булган ислам галиме. Авырлыктан соң җиңеллек килү ул – Аллаһның мөэминнәргә (бу сүзне ассызыклыйм) биргән вәгъдәсе. Аллаһ вәгъдәсен һәрвакытта да үти.

Беләм инде: бу юлларны укыганда, күңелегездә «Ә ни өчен соң кешеләр һәлакәткә юлыгалар?» дигән сорау

vk.com

туа. Бу сорауның җавабы бик киң һәм катлаулы, әлбәттә. Без аның кечкенә бер тармагын гына алып карарбыз, чөнки, бердән, урын тар, икенчедән, тулы җавап бирерлек галим түгелбез. Коръәндә кешеләрнең бәхетсезлеккә юлыгуларының сәбәпләрен аңлаткан аятьләр күп. Аллаһ илчесенең (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) хәдисләре дә шактый. Әбү Хөрәйрәдән килгән бер хәдистә: «Аллаһы Тәгалә әйтә: «Колым Минем турыда ничек уйласа, мин шундый булам», – дигән сүзләр укыйбыз. Икенче бер хәдистә: «...Колым минем турыда яхшы уйласа, аңа яхшылык булачак, начар уйласа, аңа шул ирешәчәк», – дигән сүзләр дә табабыз. Бу хәдисләрнең мәгънәсе шулай ук бик киң. Без бу очракта үзебезгә туры килгәнен генә алыйк. Гел шомланып, хәвефләнеп йөрү, өметсезлеккә һәм төшенкелеккә бирелү – адәм баласының Аллаһ турында начар уйлавы ул. Галәмнәрнең Хуҗасы турында яхшы уйлаган кеше аның рәхмәтенә өметләнә, үзен коткарачагына нык ышана, авырлыкларның сынау икәнен яхшы белә, үзенә килгән сынауга ризасызлык белдерми, зарланмый. Авырлыклар һәм һәлакәт җәза булып та килә кайвакыт. Болардан котылуның юлы бер генә: гөнаһлардан изгелек кылуга күчү, булган кадәресе өчен тәүбә итү һәм кичерүне сорау. Менә шулардан соң без Аллаһның коткаруына өметләнә алабыз, Аллаһ өметләрне һәрвакытта аклый. Күңелебездә моңа шик бар икән, димәк, без Аллаһ турында начар уйлыйбыз. Андый фикерләр начар нәтиҗәгә китерсә, гаҗәпмени?

Моннан бер атна элек кенә бу юлларның авторы мобилизацияләнгән ирен озаткан яшь хатын белән бер машинада кайтты. Ир яшь, әле утызларда гына, армиядә хезмәт иткән, карап торышка бик таза-сау да. Кире кайтуына һичбер өмет юк төсле. Берсеннән-берсе кечкенә өч бала исә (берсе – күкрәк баласы әле) әни белән калалар. Хатынның хәсрәте йөзендә ярылып ята иде, карарга авыр. Түзмәдем: «Сеңлем, кайгырма, кайгыру булышмый бу очракта. Иң яхшысы: өеңә кайткач та бөтен йөрәгең белән Аллаһтан сорап дога кыл, ярдәм озак көттермәс, Аллаһ теләсә. Синең догаңнан да көчлерәк дога юк бу очракта», – дидем һәм үз тормышымдагы әскә ишелеп төшеп баручы бәладән дога кылып котылуым турындагы бер очракны сөйләдем. Икенче көнне авыл мәчетендә иртәнге намазга килгәч: «Ирен кайтардылар», – диделәр. Аллаһның илчесе (салләллаһу галәйһи вә сәлләм): «Тәкъдирне догадан башка һичнәрсә үзгәртми», – дигән. Аның сүзләреннән тагын без шуны беләбез: бәла күктән төшә, дога күккә күтәрелә, юлда икесе очрашалар. Дога көчле булса, бәла юкка чыга, дога зәгыйфьрәк булса, бәланең зурлыгы кими.

Тагын бер мөһим нәрсәне искәртеп төгәллим язманы. Аллаһ үзенең авыр хәлдә калган дин кардәшенә булышкан колына булыша. Глициннар һәм корвалоллар вакытлыча тынычлык өчен генә алар. Димәк, авырлыклар килгәндә, Бөек Затның ярдәмен алу өчен, аның бәлагә тарыган колларына булышу мөһим. Әйдәгез, бу авыр чорда бер-беребезгә игътибарлы булыйк.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Зөһрә
САДЫЙКОВА

# ҺӘРБЕРСЕ – АЛТЫН БӘЯСЕ

## АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ТАРМАГЫНДА МОБИЛИЗАЦИЯ НИЧЕК БАРА?

**«Алдан уйлыйсы, хәстәрен иртәрәк күрәсе булган». Хезмәткәрләренә бронь алырга өлгермәгән җитәкчеләр әнә шулай дип көенә бүген. Икмәк пешерү заводлары, ит комбинатлары, консерв заводлары, сөт комбинатлары хезмәткәрләре бронь белән якланган булса да, фермерлар, терлекчеләр, механизаторлар, мал табиблары гадәти тәртиптә чакырылачак. Дөрес, кайбер хуҗалыклар үз хезмәткәрләренә бронь алырга өлгергән. Җаваплы органнарга исемлек җибәреп, әлеге вакытта җавап көтүчеләр дә шактый. Аларның язмышы ничек хәл ителер? Гомумән, авыл хуҗалыгы тармагында мобилизация ничек бара? Оешма җитәкчеләре вазгыятьтән ничек чыгарга җыена? Без шул хакта белештек.**

### 139 кеше чакырулы

Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәгълүматлары буенча, Татарстанда 600 предприятие азык-төлек белән тәэмин итүгә үз өлешен кертә. Аларда 49 мең кеше эшли. Шуларның 12 меңе запаста булып исәпләнә. Шул ук вакытта өлешчә мобилизациягә эләккән очракта, якынча 10 мең хезмәткәр бронь алуга хокуклы. Әлегә аларның 38 проценты гына бронь алган.

1 октябрьгә булган мәгълүматлар буенча, өлешчә мобилизация кысасында хәрби комиссариатлардан авыл хуҗалыгы тармагында эшләүче 399 кеше чакыру (повестка) алган. Бу – тармакта эшләүчеләрнең якынча 0,56 проценты дигән сүз. Шуларның 139ы чакыру пунктларына килгән.

Министр Марат Җәббаров журналистлар белән очрашуда хуҗалыклар мобилизацияләнгән эшчеләргә алмашка яңа белгечләр табарга тырышуларын әйтте. Шунлыктан тиз арада кешеләр эзлиләр. Шул ук вакытта, министр әйтүенчә, тармакта вазгыять катлаулы түгел.

Шунысын да әйтеп узарга кирәк: бүгенгә, Россия законнары нигезендә, бронь алу буенча эшләр туктатылган. Бу бары тик дәүләт хаҗәте өчен азык-төлек товарларын әзерли торган оешмаларга гына кагылмый.

– Бүген күп кенә оешмалардан, авыл хуҗалыгы җитештерүчеләреннән мөрәҗәгатьләр кабул итәбез, ләкин без билгеле бер таләпләр буенча гына эш алып барабыз, – диде министр.

### Кыл өстендә

Язманы алга таба дәвам итәр өчен, бронь турында тулырак мәгълүмат бирергә булдык. Редакция юристы Булат Закиров аңлатуынча, бронь төшенчәсе эшкә бәйле. Бу – предприятиедәге эшне өзлексез дәвам итү өчен кирәк булган эшчене мобилизациядән азат итү дигән сүз. Мәсәлән, ул баш технолог яки баш инженер булырга мөмкин. Бу очракларда сүз беренче чиратта икмәк пешерү заводлары, ит комбинатлары, консерв заводлары, сөт комбинатлары турында бара. Бронь алган эшче мобилизациядән 12 айга кадәр азат ителергә мөмкин. Кирәк булган очракта, озайтылырга да мөмкин. Ә инде вазыйфасын үзгәрткән яисә эшне алыштырган чакта бронь сакланмый. Оборона министрлыгы мәгълүматлары буенча, броньны дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары, хәрби сәнәгать комплексы, хәрби техника җитештерә торган саклану предприятиеләре, аккредитация узган IT компанияләр, массакүләм мәгълүмат чаралары, мәгълүмат һәм элемтә өлкәсе, финанс компанияләре һәм банклар ала ала.

Мәсәлән, Казанның 3 нче икмәк пешерү заводының бүлек мөдире Инзар Җиһангиров әйтүенчә, биредә эшләүче һәр ир-атка бронь бирелгән.

– Бездә әлегә барысы да тыныч. Һәркем – үз эшендә. Икмәк белән тәэмин итү буенча план төзелде, эшләп чыкмас өчен бер генә сәбәп тә юк, – диде ул.

Авылларда да бронь алучылар бар. Мәсәлән, Актаныш районының «Нигез» җәмгыятендә 68 кеше эшли. Оешмада эшләүче 27 ир-атның 19ына бронь бар.

– Әлегә безнең җәмгыятьтәге бер кеше дә өлешчә мобилизациягә эләкмәде. Алда нәрсә буласын беребез дә белми, – диде хуҗалык җитәкчесе Дамир Җәлилов. – Бүгенгә кадәр районда авыл хуҗалыгы тармагында эшләүчеләр арасында китүчеләр күп түгел иде. Һәр хуҗалыктан бер-ике кешене генә озаттылар.

Хуҗалык җитәкчесе, авыллардан җаваплы эшчеләр китү хәлне катлауландырса да, вазгыять ул дәрәҗәдә киеренке булмас, дип өметләнә.

– Беребезгә дә җиңел булмас анысы. Авырлык тынычы вакытта да килә торды. Ләкин алар хәл ителде. Шуңа күрә алга таба да исәнлек булсын да, дөньялар тынычланып, бу мәсьәлә уңай якка хәл ителсен иде, дип телибез, – диде Дамир Җәлилов.

Халык кыл өстендә яшәгән кебек. Чүпрәле районының Шланга авылында яшәүче Шәмсия Алимова әнә шулай ди. Әлеге вакытта авылдан дүрт егет өлешчә мобилизациягә эләккән.

– Үзләре шәһәрдә торсалар да, авылда теркәлгәннәр иде. Шуңа күрә повестка да авылга килде. Егетләрнең берсе – Казанда «Оргсинтез»да, икенчесе – кибеттә, икесе төрле җирдә эшли иде. Бер егетебезнең ике баласы бар, калганнары гаилә кормаган әле. Гомумән алганда, 17 егетебезгә повестка килде. Кайсының эшләгән урыныннан бронь булган, кайсы студент кына әле. Хуҗалыкта эшләүче кешеләр арасында яшьләр юк. Барысы да – 40 яшьтән өлкәннәр, – диде ул.

«ВТ» архивыннан

Шәмсия Алимова әйтүенчә, соңгы вакыйгалар халыкның тынычлыгын алган. Һәркайсы көн дә хәбәр көтә, ди ул.

– Бу хәлләр кагылмаган бер генә нәсел дә юк. Барысы да, бүген ни булыр икән, дип көтә. Дөрес, соңгы көннәрдә хәбәрләр тынып тора әле. Бераз гына булса да тын алып торабыз. Барыбызда да бер теләк: алынган егетләребез хәрби хәрәкәтләр бара торган нокталарга барып җитмәсен иде. Катнашырга туры килгән очракта да, исән-имин әйләнеп кайтсыннар иде, – диде Шәмсия Алимова.

### Алып калып булырмы?

Әгәр азык-төлек җитештерүдә катнаша торган икмәк пешерү заводлары, ит комбинатлары, сөт заводлары бронь белән якланган булса, фермерлар гадәти тәртиптә чакырыла. Алар арасында инде мобилизацияләнүчеләр дә бар.

Буа районында авыл хуҗалыгы тармагында эшләүче 9 кеше мобилизацияләнгән. Алар арасында механизаторлар да, терлекчеләр дә, фермер да бар. Соңгысының улын эшен әтисе алып барачак.

– Авылда эшләргә болай да кеше аз. Шунлыктан ул барыбер үзен сиздерер дип уйлыйм, чөнки мобилизацияләнгәннәрнең һәркайсы ныклап торып эшли торганнар иде, – диде районның авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы Ранис Габитов. – Бронь мәсьәләсе дә ачык булып кала әле. Идарәдә ничек тиеш, шулай эшләнгән ул. Тик хуҗалыкларның күпчелегендә юк иде. 21 сентябрьдән соң барысы да кузгалдылар кузгалуын, ләкин алар закон көченә ия булырмы – әлегә билгесез.

Бронь – Балтач районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Фирдәвес Нәбиуллинның да иң нык борчыган мәсьәләләрнең берсе бүген.

– Кызганыч, үз вакытында бронь буенча дөрес эшләмәгәнбез. Булмас әле, килмәс әле, дип яшәгәнбез. Хуҗалыклардан таләп тә итә белмәгәнбез. Бу – безнең эшләп бетермәгәнлек. Мин моның өчен үземне бик гаепле хис итәм. Хәзер авыл хуҗалыгы тармагында эшләп, бронь бирелмәгән егетләрнең барысы да китәчәк. Кызганыч, без күпме генә тырышсак та, повестка килеп төшә икән, берни дә эшли алмыйбыз, – диде ул, ачынып.

Идарә башлыгы әйтүенчә, әлегә райондагы егерме хуҗалыктан 22 кеше мобилизацияләнгән. Шуның берсе контракт буенча хезмәт итәчәк. Алар арасында механизатор да, осеменатор да, терлекче дә, сөт җыючы да, мал караучы да, фельдшер да бар.

– Егетләрнең эш урыннары сакланачак. Бу турыда алар белән сөйләшү булды. Моннан тыш, хезмәт хакларын биреп бетергәндә, колхозчыларның гаиләләренә бер тапкыр өстәмә 20 мең сум күчереләчәк. Үзләре юкта гаиләләренә нинди дә булса ярдәм кирәк була икән, шулай ук булышырга әзербез, – диде ул.

Фирдәвес Нәбиуллин әйтүенчә, колхозлар булгач, эшне уртак итеп эшлиләр, шунлыктан бу мәсьәләдә әлегә авырлыклар юк.

Үзгәрешләр Балык Бистәсе районы фермеры, сөт заводы хуҗасы Миңзәфәр Исмәгыйлевнең хуҗалыгына да кагылырга мөмкин, чөнки эшләүчеләрнең 70 проценты – ир-атлар. Алар арасында повестка килергә мөмкин булучылар да шактый, диде фермер. Инде беренче китүче дә бар. Шушы көннәрдә машина йөртүче мобилизацияләнгән.

– Бездә төп эшләрнең берсен машина йөртүче башкара. Кайсы вакытларда аларның бер эш көне бер елга тора. Егетебез өч ел эшләде бездә. 26 яшь. Менә аның урынына хәзер кеше эзлибез. Әлегә җаваплы, намуслы эшчеләрне табу бик кыен. Хезмәт хакы да яхшы югыйсә. Бездә машина йөртүче 45 мең сум акча ала. Хәтта шундый хакка да кеше таба алмый тилмерәм. Авылда эшләргә кеше табу минем өчен болай да иң авыр проблема иде. Хәзер белмим, ничек эшләрбез, дип борчылам, – диде Миңзәфәр Исмәгыйлев.

Министрлык хуҗалыкны кемгә калдыруны алдан уйларга киңәш итте. Мәсәлән, грант алу буенча килешү вакыты чыкмаган кешеләргә (шул исәптән фермерлар да) милкен алып каласа затка ышаныч кәгазен рәсмиләштерергә кирәк булачак. Грант алып, өлешчә мобилизациягә эләккән, ышаныч кәгазе булмаган һәм фермер хуҗалыгын башка кеше исеменә рәсмиләштермәгән кешегә, терлекләрен калдырырдай затны тапмаган очракта, 8(495)6078107, 8(495)6087223 телефон номерлары буенча Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгының авыл территорияләрен үстерү департаментына шалтыратырга кирәк булачак. Алга таба терлекләр зур предприятие карамагына күчәчәк.

Чулпан
ГАРИФУЛЛИНА

# ДӘҮЛӘТТӘН КЕШБЭК

## САЛЫМ «ВЫЧЕТЫ»: КЕМГӘ, НИЧЕК, КҮЛӘМЕ?

**«Кешбэк» дигән сүз хәзер берәүгә дә ят тоелмый. Гади итеп әйткәндә, нәрсәдән дә булса файдаланган өчен түләнгән акчаның берникадәр өлешенең кире кайтуы инде бу. Соңгы елларда туристик кешбэк дигәне аеруча популярлашты. Күпләр бу хакта белеп кенә бетерми: баксаң, дәүләт безгә күптәннән башка төрле кешбэк вәгъдә итә икән бит инде. Моның өчен кешенең рәсми төстә эшләве һәм аның хезмәт хакыннан башлап барлык төр керемнәреннән салым тотып калынуы кирәк. Бу кешбэк салым «вычеты» дип атала. Ул кемнәргә тиеш? Акчаны кире кайтару тәртибе нидән гыйбарәт? «Вычет»ның нинди төрләре бар? Бу һәм башка сорауларга ачыклык кертәбез.**

### Төрләре

Барыбыз да физик затлар кеременә салым (НДФЛ) түли. Фатир сатып алсагыз да, уку өчен түләсәгез дә, сәламәтлегегез өчен акча сарыф итсәгез дә, шәхси инвестицион счетыгызны (ИИС) тутырсагыз да, түләнгән НДФЛ күләменең бер өлешен кайтарырга тулы хокукыгыз бар дигән сүз.

Салым «вычеты»ның берничә төп төре билгеле. Болар – милек (күчемсез торакка кагыла, апартамент һәм коммерциячел биналар моңа керми), социаль (дәвалау, хәйрия, спорт, белем алуга кагыла), инвестицион (физик затның кимендә өч ел кулланышта булган кыйммәтле кәгазьләрне сатудан кергән табышы; ИИСта урнаштырган керем), һөнәри «вычет» дигән төрләре.

### Ничек санарга?

Бу бик гади: тотылган акча күләмен 0,13кә тапкырлыйсы. Шунысы да бар: «вычет» күләме бюджетка түләгән салым суммасыннан күбрәк була алмый! Салым «вычеты» физик затның билгеле бер чорда түләнгән НДФЛ суммасыннан гына түләнә. Әйтик, инвестицион «вычет»ның максималь күләме – 52 мең, социаль – 120 мең, мөлкәт өчен 260 мең сумны тәшкил итә. Милек сатып алу яисә йорт салу өчен ипотека рәсмиләштерелгән икән, кеше түләгән процентлардан 390 мең сумга кадәр акчасын кире кайтарырга хокуклы.

Аңлаешлырак булсын өчен, мисалда карыйк.

*Фатирга тотылган чыгымнар суммасына (2 миллион) «вычет» ясау мөмкин. Әйтик, фатир 3 миллион сум тора, ди. «Вычет»ны 2 миллион сум өчен кайтару мөмкин булачак. Сан теле белән әйткәндә, алдарак язып үткән 260 мең сум дигән сүз инде бу.*

> **САН**
>
> Салым федераль хезмәтенең 1 гыйнварына караган мәгълүматларына күз салсак, салым «вычеты»н сорап мөрәҗәгать итүчеләр саны **4,9 миллионнан** артып киткән. Барлыгы **1,8 миллиард** сумнан артык акча кире кайтарылган. Уртача сумма **376,4 мең** сумны тәшкил иткән.
>
> Сораштырулар күрсәткәнчә, Россиядә яшәүче **һәр дүртенче** кеше салым «вычеты»н кайтару мөмкинлеге барлыгы хакында бөтенләй белми. Шул ук вакытта хезмәт хакы **80 мең** сумнан арткан гражданнар әлеге мөмкинлектән ешрак файдалана икән.

Тагын бер искәрмә: әйтик, кеше тулысынча 260 мең сумга кадәр рөхсәт ителгән күләмдә сумманы алмаган икән, ул аны башка күчемсез милек объектлары өчен куллана ала.

### Ничек файдаланырга?

«Вычет» кайтаруның ике төрле юлы бар. Берсе – салым инспекциясе аша, икенче юлы – эш бирүче аркылы.

**Беренче юлны** сайлыйсыз икән, сезгә түбәндәге документлар кирәк булыр:

*– 3-НДФЛ үрнәгендә декларация;*

*– 2-НДФЛ үрнәгендә эш урыны буенча белешмә (ел дәвамында тотып калынган һәм күчкән салым суммасы турында мәгълүмат);*

*– «вычет» алырга хокуклы булуыгызны раслаучы дәлилләр (чек, килешүләр һ.б.).*

Салым бүлекчәсенә барып тору кирәкми дә. Моның өчен махсус «шәхси кабинет»тан гына да файдаланырга мөмкин. Гаризаны шунда күрсәтелгән тәртип буенча дөрес итеп тутырып кына барасы.

Әгәр инде «вычет»ны **эш бирүче аркылы** соратырга теләсәгез, түбәндәге кагыйдәләрне истә тотарга туры килер:

*– иң элек салым органыннан милек өчен тотып калынган акчага хокук турында ирекле рәвештә гариза язарга;*

*– моны раслый алырлык документларны тупларга (күчермәләрен);*

*– яшәү урыны буенча салым органына бу хокукны раслаучы документларның күчермәләре белән милек өчен тотып калыну хокукы турында гаризаны тапшырырга;*

*– 30 көн узгач салым органыннан җавап алырга;*

*– салым органыннан килгән рәсми җавапны эш бирүчегә тапшырырга. Бу инде ел азагына кадәр НДФЛ тотып калмас өчен нигез булып торачак.*

Шунысы да бар: стандарт, социаль, инвестицион, һөнәри «вычет»ларны кеше үз гомерендә берничә мәртәбә кайтарырга мөмкин. Кеше бары тик милек өчен «вычет»ны гына үз гомерендә бер тапкыр кына кайтарырга хокуклы.

Шуны да онытмагыз: санап үтелгән рәсми кәгазьләрдән кала һәр төр хезмәткә бәйле башка документлар да өстәлә!

### Ә кайсы отышлырак?

Салым инспекциясе аша эш иткәндә, «вычет» алганчы бер ел узганын көтәргә кирәк. Бу вакыт аралыгында салым түләргә дә онытмыйсы, билгеле. Әгәр дә инде бу мәсьәләне эш бирүче аша хәл итәсез икән, акчаны шул ук елны алырга мөмкинлек бар. Акчаны кулга тизрәк төшерү ягын кайгыртып әйткәндә, икенче очрак отышлырак, әлбәттә. Әмма салым түләүче берничә сәбәп буенча акча алырга хокуклы булса, аны салым органы аша алу хәерлерәк. Монда барысы да сезнең теләк һәм нияттән тора инде.

Эш шунда ки, кайбер салым чигерүләре алу сроклары буенча чикләнгән (мәсәлән, дәвалануга), агымдагы елда хезмәткәр аны эш бирүче аша кулга төшерергә өлгермәскә дә мөмкин. Салым органына мөрәҗәгать иткәндә исә, барлык очраклар да исәпкә алыначак, барысы өчен дә акча кучәчәк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

> ## 4 сорауга җавап
>
> Һәр салым түләүчене кызыксындырган төп сорауларга вернемналог.рф һәм Салым федераль хезмәте белгечләре ачыклык кертте.
>
> **1. Сәламәтлек һәм уку өчен салым «вычеты»н ничек кайтарырга?**
>
> – Түләүле медицина оешмаларында тикшерү узган, дәваланган өчен салым кайтару мөмкин. Үзегез өчен генә түгел, хәтта ир йә хатын, әти-әнисе, 18 яше тулмаган бала өчен дә. Табиб кушуы буенча сатып алынган дарулар өчен дә 13 процент акчаны киреп кайтарырга мөмкин. Шулай ук барлык гаилә әгъзалары өчен дә.
>
> Дәвалану гадәти һәм кыйбатлы булырга мөмкин. Әйтик, пластик операция, ЭКО ясату. Гадәти дәвалану вакытында 120 мең сумга кадәр хезмәтләрдән файдаланырга һәм 15600 сум «вычет» алырга мөмкин. Әгәр дә дәвалану кыйбатлы процедуралар исемлегенә керә икән, димәк, тулы бәядән 13 процентны кайтартырга хокукыгыз бар. Шундый ук кагыйдә буенча уку өчен түләүдән дә матди өлеш кайтартырга мөмкин (24 яшькә кадәр). Уку йортының лицензиясе булу шарт. Аны салым органнарында сорыйлар. Уку өчен түләү «вычеты»ның күләме елына 50 мең сумнан исәпләнә. Иң күбе – 120 мең сум.
>
> **2. Быел салым «вычет»ына бәйле нинди үзгәрешләр гамәлгә керде?**
>
> – Беренчедән, 3-НДФЛ декларациясен һәм раслаучы документларны тапшырмыйча гына салым «вычеты»н алуның гадиләштерелгән тәртибе барлыкка килде. Әлегә гадиләштерелгән тәртип бары тик ике төргә генә каралган: инвестицион һәм милек «вычет»лары. Акчаны кайтару өчен кирәкле белешмәләр банклардан, брокерлардан һәм башка салым агентларыннан мәгълүмат алмашу өчен махсус программа аша салым агентларына керәчәк. Шунысы да бар: болай итеп салым кайтару 2020 елдан башланган килешүләргә генә кагыла.
>
> Икенчедән, спорт белән шөгыльләнү өчен дә салым кайтару мөмкин.
>
> Өченчедән, салым инспекциясе хәзер эш бирүчегә физик затның «вычет»ка хокукы булуын раслый торган хәбәрне үзе җибәрә.
>
> Дүртенчедән, 3-НДФЛ декларациясендә 3 һәм 5 елдан да ким булмаган күчемсез милекне сатудан кергән керемнәрне күрсәтмәскә мөмкин (объектны сату бәясе милек «вычеты» суммасыннан артмаган очракта).
>
> **3. Быел кайсы еллар өчен салымны кайтарырга мөмкин?**
>
> – 2019, 2020, 2021 еллар өчен. Ягъни соңгы 3 салым чоры өчен кайтартыла.
>
> **4. Пенсионерның салым «вычет»ына хокукы бармы?**
>
> – Пенсионерлар салым «вычеты»ннан фадалана алмый, чөнки алар НДФЛ түләми. Пенсияләргә НДФЛ салынмый (Россия Салым кодексының 217 маддәсенең 2 пункты).

# КЕМГӘ – НӘРСӘ?

## КҮПМЕ АКЧА ТҮЛИЛӘР?

➤Мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган кешеләргә өйрәнүләр вакытында акчаны званиесе һәм вазыйфасына карап түлиләр. Рядовой һәм сержантлар – **25–30 мең**, офицерлар исә **35–40 мең** сум акчага өметләнә ала.

➤Акчаны кешенең үзенә яки аның теләге буенча туганнарының счетына күчерәләр.

➤Махсус хәрби операция зонасына юллангач, звание буенча окладка вазыйфа буенча ике оклад, тәүлегенә **4222 сум** өстәлә. Хезмәтенә карап, премияләр дә булырга мөмкин. Хәрби хәрәкәттә катнашкан өчен дә өстәмә акча каралган. Шулай итеп, рядовой һәм сержантлар **200 мең** сумнан күбрәк, офицерлар исә **250 мең** сумнан күбрәк акчага өметләнә ала.

➤Махсус хәрби операциядә катнашкан кешеләр хәрби хәрәкәтләр ветераны булып санала. Андыйларга аерым социаль гарантияләр, ташламалар каралган.

➤Махсус операциядә һәлак булган хәрбинең гаиләсенә бер тапкыр бирелүче **4452696,06** сум күләмендә пособие, бер тапкыр **5000000** сум акча, **2968464,04** сум күләмендә иминият буенча тәэмин итү акчасы түләнә, туендыручысын югалту буенча айлык пенсия билгеләнә. Моннан тыш, гаиләләрнең (хәрбинең һәм аның хатынының) кредит бурычларын каплау гарантияләнә. Хәрби ипотеканы тулысынча каплау һәм Россия субъектларыннан өстәмә социаль гарантияләр дә каралган. Һәлак булган хәрбиләрнең балаларына махсуслашкан хәрби белем бирү учреждениеләренә, шулай ук вузларда бушлай уку мөмкинлеге бирелә.

## ӨЛЕШЧӘ МОБИЛИЗАЦИЯГӘ КЕМНӘР ЭЛӘКМИ?

✓Бронь алган кешеләр.

✓Сәламәтлеге аркасында хәрби хезмәткә яраксыз һәм вакытлыча яраксыз булганнар («Г» һәм «Д» категорияләре).

✓Гаиләдә тәрбиягә мохтаҗ яки I группа инвалидны даими караучылар.

✓Үзенең энесе яки сеңлесенә опекун яки попечитель булганнар, әмма гаиләдә бу эшне башкара алырлык башка кеше булмаганда.

✓16 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан күбрәк баласы булганнар.

✓Хатынының йөклелеге 22 атнадан арткан, моннан тыш, 16 яше тулмаган өч баласы булганнар.

✓Ир-егетнең энисе аннан кала 8 яше тулмаган тагын дүрт һәм күбрәк баланы ялгызы гына тәрбияли икән, мондый кеше дә хәрби хезмәткә чакырылмый.

✓«Мобилизация буенча хатын-кызларны чакырырга җыенмыйбыз», – диде оборона министры Сергей Шойгу.

✓Студентлар. Мондый мөмкинлек дәүләт аккредитациясенә ия булган урта һәм югары уку йортларында, инновацияле фәнни-технология үзәкләрендә урнашкан оешмаларда, дини уку йортларында көндезге бүлектә белем алучыларга бирелә.

## ЗАПАСТАГЫ КЕШЕЛӘРГӘ БРОНЬ НИЧЕК БИРЕЛӘ?

✓Бу эш әлеге кешеләр эшләгән оешмаларда Вазыйфалар һәм һөнәрләр исемлеге (Перечень должностей и профессий) нигезендә башкара. Исемлек Бронь бирү буенча ведомствоара комиссия тарафыннан раслана.

✓Мондый мөмкинлек яше 27дән арткан һәм мобилизация заданиесен үтәүдә мөһим эш башкарган вазыйфаи затларга һәм һөнәр ияләренә бирелә.

✓Бронь аерым кешегә түгел, ә ул башкарган вазыйфага бирелә.

✓Хәрби шартларда дәүләт иминлеге һәм халык тормышын тәэмин иткән, гражданнарны хәрби-учет белгечлекләренә әзерләгән оешмалар да бронь бирә ала.

✓Беренче чиратта бу оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләренә кагыла. Соңрак әлеге исемлеккә IT-тармак, элемтә һәм мәгълүмат, матбугат, түләү системасы һәм финанс базары оешмалары да өстәлде.

✓Оешма мондый хезмәткәрләрне чакыруны кичектереп тору хокукы турында белешмә әзерли һәм аны имзалау өчен хәрби комиссариатка юллый. Имзаланган белешмә оешмада саклана һәм бронь алган кешегә мобилизация игълан ителгән очракта тапшырыла.

✓Үз хезмәткәрләренә карата федераль башкарма хакимият органнары (мобилизация органнары аша), РФ субъектларының башкарма хакимият органнарында һәм җирле үзидарә органнарында (территориаль һәм муниципаль комиссияләр аша) да хәрби комиссариатлар белән берлектә шундый ук эшне башкара.

✓Аерым очракларда вазыйфалары һәм һөнәрләре расланган исемлеккә кермәгән гражданнарны да броньлау мөмкинлеге бар. Болары башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, хәрби шартларда әһәмиятле вазыйфа башкаручы оешмаларның җитәкчеләре һәм белгечләренә кагыла. Мондый карарны Федераль башкарма хакимият органнары, җирле комиссияләрдән килгән тәкъдимгә нигезләнеп, Бронь бирү буенча ведомствоара комиссия чыгара.

✓Бронь алу өчен кеше аны бирергә хокукы булган оешмада эшләргә, мөһим вазыйфа башкарырга, эшкә хезмәт килешүе буенча урнашкан булырга тиеш. IT тармакта эшләүчеләрнең профильле югары белеме булуы таләп ителә.

**Кием-салым һәм медикаментлар алуга тотылган акчаны кайтаралармы?**

Өлешчә мобилизациягә эләккән кешеләр хезмәт үтәгәндә кирәк булган барлык әйберләр белән дә тәэмин ителә. Өстәмә кием, дару һәм медицина кирәк-яраклары алу аның шәхси гамәле булып санала һәм моның өчен киткән акчаны кайтару каралмаган, дип аңлатма бирәләр «Объясняем.РФ» порталында. Кешедән үз хисабына нәрсәнедер сатып алуны таләп итү законга каршы килә. Мондый хәл килеп чыга икән, хезмәткә чакырылган урында хәрби комиссарга яки хәрби часть командирына мөрәҗәгать итәргә кирәк. Теләге булган кешегә үзе белән шәхси гигиена әйберләре, термокием, батарейкалар, яктырткыч, поход утыргычы, шлем эченнән кию өчен спорт баш киеме, тактик бияләйләр, теплоид (химик җылыткыч), мультититул (күпфункцияле җыйнак инструмент) алырга ярый.

## САГЫШТАН ТАБЫШ

Россиядә өлешчә мобилизация игълан ителүгә күрәзәчеләр, сихерчеләр, фал ачучылар һәм шул өммәттәге сәләтле кешеләр баш калкытты. Элек гыйшык-мыйшык эшендә ярдәм вәгъдә итүчеләр хәзер егетләрне хәрби хезмәттән алып калырга, ә киткәннәрнең гомерен саклап калырга әзер. Интернет һәм социаль челтәрләр әнә шундый игъланнар белән тулды. Әйтик, берничә мең сум акча түләсәң, хәрби комиссариаттагылар ир-егетне чакыру түгел, аның исемен үк онытачак икән. Дөрес, нәтиҗәсе тиз генә күренмәячәк. Аны көткән арада повестка килмәсен дисәң, сихерне тизләтергә мөмкин. Әлбәттә, өстәмә акча түләп. Белдерүләр сайтында хәрби хезмәттән алып кала торган шәмнәр, гомерне саклый торган бөтиләр дә пәйда булды. Ватанны кем ничек саклый бит…



Илдар Мөхәммәтҗанов

## КРЕДИТ КАНИКУЛЫННАН КЕМНӘР ФАЙДАЛАНА АЛА?

Кредит каникулы кредит яки заем алган хәрби хезмәткәргә түләүләрне вакытлыча туктатып торырга мөмкинлек бирә. Әлеге кагыйдә кулланучылар кредитлары һәм заемнарына, шул исәптән, ипотека һәм кредит карталары буенча түләүләргә кагыла. Бу очракта бурычның күләме һәм заемнарның саны мөһим түгел. Мондый мөмкинлектән мобилизациягә эләккән кешеләр генә түгел, аларның гаилә әгъзалары да файдалана ала.

**Шартлары**

Кредит каникулы турындагы закон Дәүләт Думасында 28 сентябрьдә кабул ителде һәм 4 октябрьдә Федерация Советында расланды. Төп шарт – кредит мобилизациягә кадәр яки махсус хәрби операциядә катнаша башлаганчы алынган булырга тиеш. Кредит каникулы мобилизация башлану датасы, ягъни 2022 елның 21 сентябреннән алдан башлана алмый. Ә кредит карталары буенча ташламалар кеше мөрәҗәгать иткәннән соң гына гамәлгә керә. Каникул мобилизация, контракт яки махсус хәрби операциядә катнашу буенча хезмәт итү вакытында һәм тагын өстәмә 30 көн дәвамында гамәлдә. Дөрес, хезмәт иткәндә алган яралардан дәваланганда, җәрәхәтләрне төзәткән вакытта озайтылырга да мөмкин. Мобилизациягә эләккән яки махсус операциядә үзе теләп катнашучы шәхси эшмәкәр дә каникулдан файдалана ала. Банклар һәм ломбардлар кредит каникулы бирүдән баш тарта алмый.

**Кая һәм ничек мөрәҗәгать итәргә?**

Кредит каникулыннан файдалану өчен кредит алган урынга – банкка, микрофинанс оешмасына һ.б.ларга мөрәҗәгать итәргә кирәк. Телефоннан шалтыратырга яки килешүдә күрсәтелгән башка ысулдан файдаланырга, әйтик, гадәти яки электрон почта аша язарга мөмкин. Мөрәҗәгать итү вакыты 2023 елның 31 декабренә кадәр. Гариза белән бергә махсус операциядә катнашуны раслаган документны да тапшырырга кирәк. Андый мөмкинлек юк икән, банк мондый мәгълүматны Оборона министрлыгыннан үзе дә соратып алырга хокуклы. Инде банк мондый документны бурычлы кешенең үзеннән таләп итсә, аны ташламалы вакыт тәмамланганчы тапшырырга кирәк. Кредит каникулыннан теләсә кайчан баш тартырга мөмкин. Моның өчен кредитор, ягъни банкка хәбәр салу да җитә. Туктатмыйча акча салып баруның да зыяны юк. Процентлар кими торыр.

Банк кредит каникулы алу турындагы таләпне 10 көн дәвамында карап, андый мөмкинлек бирү яки бирмәве турында җавабын җиткерәчәк. Бурычлы кеше 15 көн дәвамында җавап алмаган икән, кредит каникулы ул мөрәҗәгать иткән көннән гамәлдә булып санала. Банк яки башка кредитор каникул тәмамланганчы түләүнең яңа графигын җибәрергә тиеш. Ташламалы вакыт тәмамлангач, бурычны түләү элеккечә дәвам итә.

**Әҗәт булса, нишләргә?**

Вакытында түләнмәгән кредит өчен штраф яки пеня язылган булса, каникул вакытында аларның күләме артмаячак. Дөрес, соңыннан барыбер түләргә кирәк булачак. Игътибар: 2022 елның 24 февраленнән башлап кредит каникулы турындагы закон үз көченә кергәнче булган аралыкта язылган штраф яки пеняларны түләтмәячәкләр. Банкның хәрби хезмәткәрнең залогта булган фатир яки машинасын сатарга да хокукы юк. Каникул вакытында бурыч буенча процентларны исәпләүнең үз шартлары бар. Ипотека кредитлары һәм заемнар буенча килешүдә күрсәтелгән ставкага бәйле. Әмма кеше бурычын вакытында каплап барган кебек исәпләнә. Шулай итеп, артык процентлар исәпләнми. Кулланучы кредитлары һәм заемнары, кредит карталары буенча бурычларга килгәндә, процентлар исәпләүнең законда билгеләнгән үз ысулы бар.

Кредит әҗәте нинди шартларда бетерелә?

Хәрби хезмәткәр һәлак булса яки I группа инвалидлык алса, аның бурычы юкка чыгарыла. Мондый очракларда аның гаилә әгъзаларының өстендә булган кредитлары һәм заемнары да юкка чыгарыла.

**МОБИЛИЗАЦИЯ БУЕНЧА СОРАУЛАР БУЛСА...**

★Россия Оборона министрлыгының «кайнар линия»се: 8 (800) 100-77-07; 8 (495) 498-43-54; 8 (495) 498-34-46.

★122 номеры буенча «кайнар линия».

★«Объясняем.РФ» сайты.

## 10 октябрь | Дүшәмбе

### ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

### ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.00 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
10.00, 23.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «ШУЛЕР». (Татар телендә) 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45, 05.35 «Татар халык җырлары» 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
16.30 «Татарлар» 12+
18.00, 03.30 «Әдәби хәзинә» 6+
19.00, 20.00, 00.15 «Таяну ноктасы» 16+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Соотечественники» 12+
01.05 «Ватандашлар» 12+
01.30 «Здоровая семья: мама, папа и я» 6+
01.45 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
02.00 «Манзара» 6+

### ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
15.30 «Заман көзгесе» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
18.20, 21.25 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
19.10, 22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
02.50 «Караоке татарча» 6+

### 1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 В честь 350-летия Петра Великого. Премьера. Большое кино: «СОБОР» (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости

### РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?». Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «ЧАЙКИ» 16+
22.20 «Вечер» 12+
01.00 «МОРОЗОВА» 16+
02.55 «СРОЧНО В НОМЕР! НА СЛУЖБЕ ЗАКОНА»

### МАТЧ ТВ

06.00 Смешанные единоборства. Open FC. Данила Приказа против Жонаса Боэно. Трансляция из Барнаула 16+
07.00, 10.00, 13.00, 14.50 Новости
07.05, 19.15, 21.30, 00.15 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 13.05 Специальный репортаж 12+
10.25, 03.00 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.25 «Записки тренера. Андрей Разин» 12+
13.45 «Громко». Прямой эфир
14.55 Футбол. Товарищеский матч. Женщины. Россия – Белоруссия. Прямая трансляция из Белоруссии
16.55 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Металлург» (Магнитогорск) – «Динамо» (Москва). Прямая трансляция
19.25 Футбол. МЕЛБЕТ-Первая Лига. «Арсенал» (Тула) – «Алания Владикавказ». Прямая трансляция.
21.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Фиорентина» – «Лацио». Прямая трансляция
23.45 Тотальный футбол 12+
00.55 Регби. PARI Чемпионат России. «Слава» (Москва) – «Химик» (Дзержинск) 0+
02.55 Новости 0+
04.05 «Спартакиада сильнейших. Вызов принят». Док. фильм 12+
05.05 «Громко» 12+

### НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
10.35 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 «ЛИХАЧ» (S) 16+
22.00, 00.00 «БАЛАБОЛ» (S) 16+
00.20 «ОТСТЕГНИТЕ РЕМНИ» (S) 16+
02.50 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» (S) 16+
03.20 «МЕНТ В ЗАКОНЕ» (S) 16+

### ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.35 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.05 «Давай разведёмся!» 16+
10.05 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.20 «Порча». «Дыра» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.25 «Верну любимого» 16+
15.00 «ПЛЕННИЦА». 1-я – 4-я серии 16+
19.00 «ЦЫГАНКА». 1-я – 3-я серии 16+
22.10 «Порча» 16+
23.15 «Знахарка» 16+
23.45 «Верну любимого» 16+
00.20 «Понять. Простить» 16+
01.15 «Тест на отцовство» 16+
02.55 «Давай разведёмся!» 16+
03.45 «ЖЕНСКАЯ КОНСУЛЬТАЦИЯ» 16+
05.25 «По делам несовершеннолетних» 16+

### ЗВЕЗДА

04.40 «РУССКИЕ АМАЗОНКИ-2». 10-я – 12-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 23.20 «ГОСУДАРСТВЕННАЯ ГРАНИЦА». «ВОСТОЧНЫЙ РУБЕЖ». 1-я серия 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «ПОСЛЕДНИЙ БРОНЕПОЕЗД». 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.15 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Неизвестные сражения Великой Отечественной». Док. сериал. «На Южном фланге. 1941 год» 16+
19.40 «Загадки века». Док. сериал. «Капкан для Скифа» 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
00.55 «ЗДЕСЬ ТВОЙ ФРОНТ» 16+
02.10 «НЕБЕСНЫЙ ТИХОХОД» 12+
03.25 «ПОСЛЕДНИЙ БРОНЕПОЕЗД». 1-я и 2-я серии 16+

## 11 октябрь | Сишәмбе

### ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

### ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
10.00, 23.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ШУЛЕР». (Татар телендә) 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
21.00 «Соотечественники» 12+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». Молитва в бессонную ночь. Каюм Насыри 12+
00.45 «Здоровая семья: мама, папа и я» 6+
01.00 «Если хочешь быть здоровым» 12+
01.15 «Татар әдәбияты дәресләре» 6+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+

### ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Туган җир» 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
15.30 «Ватандашлар» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
18.20, 21.25 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
19.15, 22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+

### 1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. Большое кино: «СОБОР» (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

### РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?». Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Михаил Пореченков, Александра Богданова, Равшана Куркова, Юрий Чурсин, Николай Добрынин, Юлия Галкина, Юлия Мельникова. «ЧАЙКИ» 12+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.00 Детективный телесериал «МОРОЗОВА» 16+
02.55 Ярослав Бойко, Ольга Погодина. «СРОЧНО В НОМЕР! НА СЛУЖБЕ ЗАКОНА»

### МАТЧ ТВ

06.00 «Есть тема!» 16+
07.00, 10.00, 13.00, 15.15, 19.00 Новости
07.05, 14.40, 15.20, 19.05, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 13.05 Специальный репортаж 12+
10.25, 03.00 Еврофутбол. Обзор 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.25 Смешанные единоборства. UFC. Аманда Нуньес против Фелисии Спенсер. Трансляция из США 16+
15.55 Бадминтон. Чемпионат России. Прямая трансляция
19.30 Футбол. Лига чемпионов. «Копенгаген» (Дания) – «Манчестер Сити» (Англия). Прямая трансляция
21.45 Футбол. Лига чемпионов. «Милан» (Италия) – «Челси» (Англия). Прямая трансляция
00.55 Футбол. Лига чемпионов. ПСЖ (Франция) – «Бенфика» (Португалия) 0+
02.55 Новости 0+
04.05 «Больше, чем футбол». Док. фильм 12+
05.05 «Правила игры» 12+
05.30 «Наши иностранцы» 12+

### НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный сериал «ЛИХАЧ» (S) 16+
22.00, 00.00 Детективный сериал «БАЛАБОЛ» (S) 16+
00.20 Премьера. Сериал «ОТСТЕГНИТЕ РЕМНИ» (S) 16+
02.50 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» (S) 16+
03.20 «МЕНТ В ЗАКОНЕ» (S) 16+

### ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.15 «Давай разведёмся!» 16+
10.15 «Тест на отцовство» 16+
12.20 «Понять. Простить» 16+
13.25 «Порча». «Мёртвая подруга» 16+
13.55 «Знахарка» 16+
14.30 «Верну любимого» 16+
15.05 «ПЛЕННИЦА». 5-я – 8-я серии 16+
19.00 «ЦЫГАНКА». 4-я – 6-я серии 16+
22.10 «Порча». «Затхлая вода» 16+
23.15 «Знахарка» 16+
23.45 «Верну любимого» 16+
00.20 «Понять. Простить» 16+
01.15 «Тест на отцовство» 16+
02.55 «Давай разведёмся!» 16+
03.45 «ЖЕНСКАЯ КОНСУЛЬТАЦИЯ» 16+
05.25 «По делам несовершеннолетних» 16+

### ЗВЕЗДА

05.05 «ПОСЛЕДНИЙ БРОНЕПОЕЗД». 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 23.20 «ГОСУДАРСТВЕННАЯ ГРАНИЦА». «ВОСТОЧНЫЙ РУБЕЖ». 2-я серия 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «НА РУБЕЖЕ. ОТВЕТНЫЙ УДАР». 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
17.10 «Легенды разведки. Николай Кузнецов». Док. фильм 16+
18.15 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Неизвестные сражения Великой Отечественной». Док. сериал. «Битва за Великие Луки». Премьера! 16+
19.40 «Улика из прошлого». «Укол ненависти. Тайна наркотиков ВСУ» 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
00.50 «СЫЩИК» 12+
03.05 «Оружие Победы». Док. сериал 12+
03.15 «КАДЕТЫ». 1-я и 2-я серии 12+

# КОТЛЫЙБЫЗ!

Илебез спортын үстерүгә һәм 2022 ел сезоны суперлигасы чирәмдә хоккей буенча ир-ат командалары арасында Россия чемпионатында спортчыларның югары күрсәткечләргә ирешүенә зур өлеш кертүе өчен «Динамо-Казан» чирәмдә хоккей клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы баш тренеры **Маргарян** Араик Арташович; 2022 ел сезоны суперлигасы чирәмдә хоккей буенча ир-ат командалары арасында Россия чемпионатында спортчыларның югары күрсәткечләргә ирешүенә мөһим өлеш кертүләре өчен «Динамо-Казан» чирәмдә хоккей клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы директоры **Әхәтов** Ринат Рәфхәт улы, «Динамо-Казан» чирәмдә хоккей клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы өлкән тренеры **Маргарян** Артур Араикович; 2022 ел сезоны суперлигасы чирәмдә хоккей буенча ир-ат командалары арасында Россия чемпионатында җиңү яулаулары өчен «Динамо-Казан» чирәмдә хоккей клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы спортчы-инструкторлары: капкачы **Гафаров** Марат Илдар улын; арадаш-сакчы **Майоров** Алексей Александрович **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены** белән бүләкләнде.

***

2022 ел сезоны суперлигасы чирәмдә хоккей буенча ир-ат командалары арасында Россия чемпионатында спортчыларның югары күрсәткечләргә ирешүенә зур өлеш кертүе өчен «Динамо-Казан» чирәмдә хоккей клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы президенты **Корольков** Евгений Александрович **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

2022 ел сезоны суперлигасы чирәмдә хоккей буенча ир-ат командалары арасында Россия чемпионатында җиңү яулаганы өчен «Динамо-Казан» чирәмдә хоккей клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы саксычы **Исаев** Андрей Андреевич; Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен хезмәт ветераны **Иштирякова** Гөндизә Дәүләт кызы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

2022 ел сезоны суперлигасы чирәмдә хоккей буенча ир-ат командалары арасында Россия чемпионатында спортчыларның югары күрсәткечләргә ирешүенә зур өлеш кертүләре өчен «Динамо-Казан» чирәмдә хоккей клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы хезмәткәрләре: администратор **Акчурин** Айрат Ирек улы, видеооператор **Маргарян** Жак Гамлетович, тренер-аналитик **Тимашков** Тимур Игоревич, команда башлыгы **Шацкий** Тимур Эдуардович; 2022 ел сезоны суперлигасы чирәмдә хоккей буенча ир-ат командалары арасында Россия чемпионатында җиңү яулавы өчен «Динамо-Казан» чирәмдә хоккей клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы спортчы-инструкторы **Янкун** Николай Александрович; Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Мәктәпкәчә белем бирү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенең тәрбия-белем бирү бүлеге әйдәүче белгече **Николаева** Галина Николаевна; Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле эшчәнлекләре өчен хезмәт ветераннары: **Галләмов** Габделбәр Галләм улы; **Фәйзуллина** Лузия Заһретдин кызы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

«Республика Татарстан» газетасы редакциясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе баш мөхәррире урынбасары **Воскресенский** Павел Георгиевичка, «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе баш мөхәрриренең беренче урынбасары **Хөснуллин** Илнар Хәлил улына **«Татарстан Республикасының атказанган матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Динамо-Казан» чирәмдә хоккей клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы табибы **Салиева** Диларә Вакыйф кызына **«Татарстан Республикасының атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Динамо-Казан» чирәмдә хоккей клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы спортчы-инструкторлары: һөҗүмче **Атаев** Артур Рөстәм улына, һөҗүмче **Голубев** Павел Игоревичка, һөҗүмче **Җамалетдинов** Илфат Фәрит улына, сакчы **Корбанов** Алмаз Илгизәр улына, арадаш-сакчы **Луцевич** Иван Дмитриевичка, капитан **Матковский** Семён Андреевичка **«Татарстан Республикасының атказанган физик культура хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Казан шәһәре Идел буе районының «Мәктәптән тыш эш үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең методик һәм оештыру-массакүләм эш бүлеге методисты **Гатина** Наилә Гайса кызына, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Укучылар сарае» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең социаль-педагогик юнәлеш методисты **Зарипова** Зөлфирә Мәннаф кызына **«Татарстан Республикасының атказанган яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«ТАТАР БИСТӘСЕ ПЛЮС» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Шагиахметова** Венера Габдулхак кызына **«Татарстан Республикасының атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

# УЙНАП ТҮГЕЛ, УЙЛАП ЭЧӘСЕ

pinterest.com

**Антибиотик – иң катлаулы чирне дә җиңәргә ярдәм итә торган көчле дарудларның берсе. Коронавирус котырган чорда ул аеруча популярлашты. Белгечләр чаң суга: соңгы арада хәтта аз гына авырый башлауга, коронавирус булмагае дип куркып, шундук антибиотикка үрелүчеләр саны арткан. Бу ни дәрәҗәдә куркыныч?**

**Республика клиник хастаханәсенең клиник фармакологы Альбина ЗВЕГИНЦЕВА антибиотик һәм аны куллану нечкәлекләре турында сөйләде.**

➤Антибиотик – бактерияләрне юкка чыгаручы яки аларның үрчүен туктатучы синтетик матдә. Иң беренче антибиотик 1928 елда уйлап табылган.

➤Антибиотикларны теләсә ничек куллансаң, бактерияләр аның составындагы компонентларга иярәнә, аларга бирешми башлый. Шул рәвешле иң көчле бактерияләрне дә юк итәргә тиешле антибиотик аларга каршы тора алмый башлый, аның организмга бер файдасы да калмый.

➤Антибиотик фәкать бактерияле чирләрдән генә коткара. Шуңа күрә вируслы авырулар вакытында аларның бер файдасы да юк. Исегездә калдырыгыз: антибиотиклар температураны төшерми, тамак авыртуны да басмый, борынга томау төшүдән дә коткармый. Аларны ОРВИ, грипп кебек вируслы авырулар вакытында да эчәргә ярамый. Антибиотик коронавирустан да дәвалемый. Болар барысы да – вируслы авырулар.

➤Антибиотикларны, гадәттә, биш көн дәвамында эчәргә кирәк. Чирнең катлаулыгына карап, табиб аны бер-ике атна дәвамында эчәргә дә кушарга мөмкин. Әмма күпләр өченче көнгә инде үзен яхшы хис итә башлый һәм антибиотиклар эчүне туктата. Бу – зур хата. Болай эшләгәндә бактерияләр аңа бирешмәскә әйләнәчәк. Шуңа күрә антибиотикларны ничә көн эчәргә кушылган булса, шулай эшләргә кирәк. Антибиотиклар эчә башлауга хәл яхшыру – аларның файдасы тия, табиб дөрес дәвалау курсы билгеләгән дигән сүз.

➤Үз белдегең белән антибиотикның дозасын да азайтырга ярамый. Бу шулай ук бактерияләрнең антибиотикларга бирешмәвенә китерәчәк. Аларның дозасын арттырган очракта организмга тискәре йогынтысы башланырга, кеше агуланырга мөмкин.

### Антибиотик турында 3 уйдырма

**1 УЙДЫРМА**
«Антибиотикны башка дарулар файда китерми башлагач, соң чиккә җиткәч кенә эчәргә кирәк. Бер яктан ярдәм итсә, икенче яктан организмны җимерә ул».

**ЧЫНБАРЛЫК**
Теләсә кайсы дару кебек үк антибиотикларның да тискәре йогынтысы булырга мөмкин. Андый чакта аллергия чыгарга, бавыр, бөерләргә, эчәклеккә хилафлык килергә мөмкин. Әмма болар бик сирәк күзәтелә. Шуңа күрә антибиотик организмны җимерә дигән сүзләр дөреслеккә туры килми.

**2 УЙДЫРМА**
«Антибиотикны профилактика өчен дә эчәргә була».

**ЧЫНБАРЛЫК**
Еш кына кеше, фәлән авыру килеп чыкмасын, аны кисәтәм, дип антибиотик эчә дә, күп тә үтми, шуның белән үк авырый да башлый. Моңа гаҗәпләнәсе юк: антибиотикны сау-сәламәт килеш эчкән очракта ул иммунитетны җимерә, организм теләсә кайсы чиргә бирешүчәнгә әйләнә. Дөрес, бу очракта берничә искәрмә бар. Гаиләдә бер кешедә сифилис, гонорея яки туберкулез табылса, табиб башка гаилә әгъзаларына, бу чирләрне кисәтү өчен, антибиотик эчәргә кушачак.

**3 УЙДЫРМА**
«Укол рәвешендә кабул ителгән антибиотик күпкә файдалырак һәм нәтиҗәлерәк».

**ЧЫНБАРЛЫК**
Укол аша организм антибиотикның – 90, төймә рәвешендә эчкәндә 60 процентын үзләштерә. Әмма соңгысы куллану өчен күпкә уңайлы һәм куркынычсызрак. Ник дигәндә, укол ярдәмендә антибиотик кадаганда, бердән, чит кеше ярдәме кирәк. Бу – өстәмә мәшәкать. Икенчедән, энә аша организмга инфекция дә эләгергә мөмкин.

➤Антибиотикларны табиб кушкан очракта гына эчәргә кирәк. Организмның антибиотикларга сизгерлеген тикшерү өчен, алдан бәвел анализы тапшырсаң да яхшы.

➤Табиб антибиотикларны көнгә ике тапкыр эчәргә кушкан икән, бу аларны иртәкич кулланырга кирәк дигән сүз түгел. Бер антибиотик эчү белән икенчесе арасында 12 сәгать вакыт узарга тиеш. Көнгә өч тапкыр эчәргә кушылган икән, димәк, аны һәр 8 сәгать саен эчәргә кирәк.

➤Антибиотикларны чиста су белән эчәргә киңәш ителә. Ашар алдыннанмы, ашаганнан соңмы икәнен инструкциясеннән укырга кирәк. Антибиотиклар эчә башлагач, өч көн эчендә хәлегез яхшырмый, организмда уңай үзгәрешләр күзәтелми икән, кабат табибка мөрәҗәгать итегез.

## *Баш авыртудан котылу өчен*

**«Баллы» әстерхан чикләвеге**

Әстерхан чикләвеген иттарткычтан чыгарып, куе ботка хәленә килерлек күләмдә бал кушып болгатабыз. Теләгән кеше берәр чеметем дарчин һәм имбир оны да өсти ала. Шифалы һәм бик тәмле катнашманы суыткычта саклыйбыз. Аны көнгә 3 мәртәбә ашар алдыннан берәр аш кашыгы кабып куярга киңәш ителә.

**Бал белән суган согы**

1 стакан сыек балга стаканның өчтән бер өлеше күләмендә яңа сыгылган суган согы салып болгатабыз һәм суыткычка куябыз. Бу катнашма бик үк тәмле түгел, әмма файдалы үзлекләре искиткеч. Аны көнгә 3 мәртәбә ашар алдыннан берәр чәй кашыгы кабул итәргә кирәк. Кан тамырларын чистартудан тыш, ул организмның авыруларга каршы торучанлыгын да арттыра.

**Гранат, алма, кишер соклары**

Бу сокларның кибеттән сатып алынганнарын түгел, ә җимешләрдән һәм яшелчәдән яңа гына сыгылганын куллану зарур. Көнгә ике-өч мәртәбә ашар алдыннан яртышар стакан эчәргә киңәш ителә. Берничә төрлесен бергә катнаштырып эчү дә файдалы.

**Әрекмән тамыры төнәтмәсе**

Дәвалану курсы бер ай дәвам итә. Көздән җыеп киптергән тамырларны файдаланабыз. Кичтән 10 г коры әрекмән тамырын термоска салып, өстенә бер стакан кайнап торган су коеп, иртәнгә чаклы шунда төнәтәбез. Сөзеп алгач, суыткычта саклыйбыз. Иртән, ашарга ярты сәгать кала, 4 аш кашыгы төнәтмә эчәбез. Әрекмән тамыры төнәтмәсе – баш миенең кан тамырларын чистартудан тыш, ашкайнату системасы өчен дә бик файдалы эчемлек.

**Киптерелгән җимешләр һәм мандарин**

Әлеге нигъмәтләр, тәмле булудан тыш, сәламәтлекне яхшырту, кан тамырларын ныгыту сыйфатына ия. Һәр көнне, иртәнге ашка ярты сәгать кала, 1 мандарин, бер-ике аш кашыгы йөзем, ике әстерхан чикләвеге ашарга мөмкинлек тапсак, башыбыз сызлап интектермәс. 15 минуттан лимон салынган яки аның согы сыгылган 1 стакан кайнаган су эчеп җибәрергә кирәк. Тагын 15 минут вакыт үткәч, иртәнге ашка рәхим итәргә дә була.

Дина ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

**Белеп тор!**

## АВЫЗДАН НАЧАР ИС КИЛСӘ...

**Әгәр авыздан ис килә икән, табибка күренергә кирәк. Бу җитди авыру билгесе булырга мөмкин.**

**Склероз.** Бу – куркыныч аутоиммун авыру. Ул организмның нерв системасын какшата, кешенең сулышына да тәэсир итә. Тикшеренү нәтиҗәләре күрсәткәнчә, чирнең башлангыч стадиясендә үк склерозлы пациентларның авызыннан начар ис килергә мөмкин.

**Бавыр эшчәнлеге бозылу.** Сулыштан чи балык исе килгәндә, бавыр начар эшли һәм токсиннарны эшкәртә алмый дигән сүз. Зарарлы матдәләр бәвелдә һәм сулыш юлында тупланып, үзенә бер ис бирә.

**Бөер эшчәнлеге бозылу.** Бу авыруның бер билгесе – сулыштан аммиак исе килү. Иллинойс университеты галимнәре уйлап чыгарган бер тапкыр куллана торган җайланма сулыштагы аммиак исен тоя һәм диагнозны иртәрәк куярга мөмкинлек бирә.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

**Белеп тор!**

# *Кәстрүлнең кайсы әйбәт?*

Хәзер кибетләрдә кәстрүлнең ниндие генә юк! Ләкин кайсы яхшырак соң? **Алюминий** кәстрүлнең бик үк кулай түгеллеген барыбыз да белә. Ләкин нигә сатыла соң алайса? Әйе, алюминий кислород белән реакциягә кереп, металл өслеге оксид пленкасы белән каплана. Әмма мондый савыт аш-су әзерләү өчен яраксыз дигәнне аңлатмый бу. Һич шикләнмичә, су кайнатырга, суда ботка, бәрәңге, башка ризыклар пешерергә мөмкин. Ләкин әзер ризыкны анда сакларга ярамый.

**Чуен**, алюминийдан аермалы буларак, кислота, селте һәм тоз тәэсиренә бирешми. Чуен кәстрүлдә ризык аеруча тәмле булып пешә, тиз суынмый. Әмма беренче карашка нык тоелса да, тиз ватыла. Аны төшереп җибәрергә, кызгач, салкын су тидерергә ярамый.

Савыт-сабадан файдалануның күпләр белмәгән кагыйдәләре дә бар. Мәсәлән, **керамикадан** эшләнгән савытны башта эченә май сылап кыздырып алырга кирәк. Майның материал күзәнәкләренә кереп, тигез пленка хасил итүе мөһим. Болай эшләгәндә, ризык савытка ябышмаячак. Шулай ук чуен савытта да әзер ризыкны саклау киңәш ителми. Күгәрә башлавы бар.

Белгечләр әйтүенчә, иң әйбәте – **тутыкмас корыч**тан эшләнгән кәстрүл. Кислотага да, селтегә дә бирешми, күгәрми дә. Анда әзерләнгән ризык сәламәтлек өчен берничек тә зыян салмый. Шуңа күрә соңгы вакытларда хуҗабикәләр нәкъ менә шуңа өстенлек бирә дә инде.

**Эмаль**ле савыт-саба да әйбәт. Анда бактерияләр үрчеми, ризыкка да берничек тә тәэсир итми. Шулай да аны яратып бетермәүчеләр байтак. Сәбәбе – эмале кубу. Мондый кәстрүл бәрмәгәндә, кулдан төшереп җибәрмәгәндә, тимер мунчала белән ышкып юмаганда гына озакка чыдый.

**Исеңдә тот!**

## Туфракны – көздән

Киләсе язда утырту өчен бакча туфрагын әзерләп куйдыгызмы әле? Юк икән, ашыгыгыз! Көннәре бетеп бара чөнки. Туфракны иләк аша үткәрү әйбәт. Юкса суалчаннар кереп калырга мөмкин, ә алар үсентеләргә комачаулаячак. Туфракны, зуррак целлофан капчыкларга тутырып, идән астында, базда яки балконда саклыйлар.

Моннан тыш бераз гына елга комын һәм агач көлен әзерләп кую да зыян итмәячәк. Боларның барысы да февраль аенда помидор, татлы борыч, баклажан, соңрак инде башка яшелчәләрне чәчү өчен кирәк булачак.

**Җимеш агачларын гына карап, карлыган-крыжовник куакларын игътибарсыз калдыручыларыбыз да бар. Янәсе, алар барыбер күпмедер уңыш бирә. Шулай уйлаучыларга: «Менә бу көздә куакларны дөрес тәрбияләгез әле, киләсе елда бөтенләй башка төрле уңыш җыеп алачаксыз», – ди һәвәскәр бакчачы Әлфинур.**

# КИСКӘНГӘ ҮПКӘЛӘМИ

**Крыжовник.** Җәен җимешләре ашап бетергесез күп булсын өчен октябрь аенда нишләргә? Иң элек аны гөмбәчек авыруларыннан, корткычлардан арындырырга кирәк. Җимешләре ботакта эленеп торганда, фунгицидлар белән эшкәртергә ярамады. Шуннан файдаланып, яшь ботакларын гөмбәчек инфекциясе зарарлаган булырга мөмкин, ди Әлфинур ханым. Озакка сузмыйча, куакка бордо эремәсе (бер куакка бер литр исәбеннән) бөркегез. 1 процентлысы да җитә. Яфракларына игътибар итегез. Крыжовник яфракларын тиз коя: аларны җыеп яндырыгыз. Көзен аларда чирләр һәм корткычлар кыш чыгарга әзерләнә. Туфракка да күчәргә мөмкиннәр, шуңа күрә яфракларны вакытында юкка чыгаруың хәерле.

Яфракларны җыеп яндыргач, куак төбен тамырларына зыян салмыйча гына йомшартыгыз. Болай ике эш эшләнә: туфрак өслегендә тупланган корткычлар тар-мар ителә һәм уңыш җыйганда тапталган җир йомшартыла. Шул ук вакытта бер крыжовник төбенә 1–2 чәй кашыгы «двойной суперфосфат», шул ук күләмдә хлорлы калий сибү дә әйбәт. Берничә көннән су сибеп, бер төпкә 350–400 г исәбеннән агач көле кертергә мөмкин. Ә инде кышын тамырлары өшемәсен өчен төбенә 10–15 см калынлыкта компост яки черемә салыгыз.

Яфракларының 90 проценты коелып беткәч, ботакларын кисегез. Корыган, зарарланган, караланган ботакларын алып ташлагыз. Бер-берсенә уралганнарын икесеннән берсен яки өчесеннән икесен калдырып кисегез. Җиргә ятып үскәннәрен дә кызганып тормагыз, аларның бернинди дә файдасы юк. Гомумән, крыжовникта, быелгы үрентеләре белән, яшьрәк биш ботак калырга тиеш. Калганнарын бөтенләй яки яртылаш кисеп ташларга кирәк.

**Карлыган.** Крыжовник кебек үк, көзге тәрбиядән соң ботакларын кисү шарт. Гадәттә биш «яшь»тән башлап кисә башлыйлар. Бу чорда куак куера, уңышны начар бирә башлый. Кисү эшен нәкъ көзен, октябрь аенда башкаралар. Биш еллык һәм аннан картрак ботакларының барысын да кисәләр. «Картлач»ларын аеру бик җиңел: ботакның өске үрентесе бик кыска һәм кайрысы кап-кара була. Мондый үрентеләрдән котылуың хәерле: алар куак уртасына комачау итә... 

Мондый үрентеләрдән котылуың хәерле: алар куак уртасына кояш төшерми, күп урынны алып тора, уңыш бирми. Шулай ук корыган, сынган, зәгыйфь, бөреләре кабарып торган (бөре талпаны белән зарарланган диган сүз) ботакларны да кисеп ташлагыз. Ә инде әйбәт ботакларын 5–3 сантиметрга кыскартыгыз. Өске өлеше корыса, сәламәт өлешенә кадәр кисеп ташлагыз.

**Укучы киңәше**

## ПЕТУНИЯ ЙОМЫРКА КАБЫГЫ ЯРАТА

**Минем петуниям яз ахырыннан беренче кыраулар төшкәнче шау чәчәктә утыра. Моның бер сере бар.**

Язын чәчәк үсентеләрен бакчага яки савытка күчереп утыртканчы, туфрагына көл яки йомырка кабыгы өстим. Кабыкны тузан рәвешенә килгәнче ваклыйм. Моның өчен иң җайлысы – «кофемолка». Ә көл әзерләү өчен кычыткан кирәк. Яшь кычытканны күләгәдә 7 көн буе киптерәм. Яфраклары уала башлагач, утка бирешми торган савытка тутырып яндырам. Янып беткәч, көл әзер диган сүз.

Бер петуния үсентесенә чама белән 1 аш кашыгы йомырка кабыгы һәм 1,5 аш кашыгы кычыткан көле кирәк. Чәчәкләрне аена бер тапкыр шулар белән ашлыйм. Беренче тапкыр – туфракка утыртканда.

Мин инде бик күптәннән шушы ысулны кулланам. Сезгә дә шуны киңәш итәм.

Зоя МИХАЙЛОВА. Балык Бистәсе

## Оек хикмәтләре

**Иске капрон оекларны ташламагыз, аларны хуҗалыкта кулланырга мөмкин.**

➔Колготкиның эластик «бил»ен бушрак итәк яки чалбар «биле»нең эчке ягына тегеп куярга була. Болай эшләгәндә, кием гәүдәгә сыланып торачак.

➔Капрон оекларны озынрак тасма итеп кисеп, кыяр һәм помидор үсентеләрен бәйләү өчен уңайлы.

➔Капрон күп җыелса, диван мендәрчекләренә, йомшак уенчыкларга тутырып кую әйбәт. Әмма башта оекны вак кисәкләргә турарга кирәк. Мондый мендәр яки уенчык гадәттәгедән күпкә йомшаграк булачак.

**АСПИРИН КЕРНЕ АГАРТА**

Даруның саргаеп киткән ак әйберләрне агартуын беләсезме? Керне ике төрле ысул белән юарга мөмкин.

●Саргайган яки пычранган керне аспирин эремәсенә салыгыз. 5 литр җылы суга 5 сәдәф дару салып, төнгә калдырабыз. Шуннан, сыгып, кер машинасында юып алабыз. Керегез ялт итәчәк!

●10 сәдәфне ваклап, порошок белән бергә машина тартмачыгына салабыз. Керне машинада юабыз. Кием ап-ак булачак.

**Тәмле булсын!**

## МАТУР КӘБЕСТӘ САЛАТЫ

**Кирәк булачак:** 2 кило кәбестә, 400 грамм чөгендер, 300 грамм кишер, 10 тырнак сарымсак, 150 мл 9 процентлы аш серкәсе, 150 грамм шикәр комы, 2 дәфнә яфрагы, 2 аш кашыгы тоз, һәр банкага 1әр аш кашыгы үсемлек мае, 2 чәй кашыгы түгәрәк борыч катнашмасы.

Кәбестәне юып, эрерәк итеп шакмаклап, кишер һәм чөгендерне 0,5 см калынлыкта бөҗралап ясап салам рәвешенә китереп турыйбыз. Яшелчәләрне, катламлап, банкаларга тутырабыз. Яртылаш бүлеп, сарымсак тырнаклары өстибез.

Маринад өчен: кәстрүлгә 1 литр су, шикәр комы, борыч катнашмасы, дәфнә яфрагы салып, кайнатып чыгарабыз. Уттан алабыз һәм кайнар маринадка аш серкәсе өстәп болгатабыз. Маринадны яшелчәле банкаларга агызабыз. Һәр банкага 1әр аш кашыгы үсемлек мае өстәп, тимер капкач белән борып ябабыз. 2–3 көн бүлмә температурасында тотабыз, шуннан соң салкынча урынга алып куябыз.

# БУРЫЧ ҺӘМ ИМАН ЭШЕ

**Аерым кайгы – кайгы түгел, илгә кайгы килмәсен! Әле кайчан гына җырларда гына ишеткән бу юлларның хаклыгына инанып көннәргә аяк бастык. Хәзер һәркайсыбыздан рух һәм иман ныклыгы, сабырлык сорала торган вакыт. Мондый шартларда адәм баласы, бигрәк тә без, мөселманнар, үзебезне ничек тотарга тиеш? Күңел тынычлыгын ничек табарга?**

**Килеп туган вазгыятькә бәйле сорауларыбызга «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт ХӘЙРУЛЛИН җавап бирде.**

**:: Рөстәм хәзрәт, бүгенге иң актуаль сораудан башлыйк әле. Хәзерге вазгыятьтә күңел тынычлыгын ничек сакларга?**

– Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә: «Коръән укыганда җан тынычлык таба», – ди. Шуңа күрә белгән догаларны күбрәк укып, машинада барганда, өйдә торганда сүрәләр тыңлагыз. Алар, һичшиксез, күңелгә тынычлыгы бирәчәк. Без шуны аңларга һәм белергә тиеш: Аллаһы Тәгалә тәкъдир кылган, ягъни язмышыбыз алдан язылган. Киләчәктә нәрсә булачагын да Аллаһы Тәгалә генә хәл итә. Шуңа күрә Коръән, дога укыгач: «Йа Раббым, хәерле тәкъдирләр бир. Балам исән-сау әйләнеп кайтсын. Йа Раббым, сакла», – дип, Аллаһка тапшырыйк.

**:: Ислам дине «Ватан», «Ватан алдындагы бурыч» дигән төшенчәләргә нинди мөнәсәбәттә?**

– Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу галәйһи вәсәлләм бер хәдисендә: «Ватанны ярату – иманнан», – ди. Әлбәттә, без Ватаныбызны якларга, сакларга тиеш. Бер үк вакытта һәркем аны үзенчә саклый. Кемдер бу бурычны дога кылып, кемдер кулына мылтык алып, кемдер балаларга патриотик тәрбия биреп башкара.

**:: Бүген Ватан алдында бурычын үтәүдән куркып, илдән качучылар да шактый. Бу – гөнаһмы?**

– Моның гөнаһмы-юкмы икәнлеген бер Аллаһы Тәгалә генә белә. Әмма расүлебезнең бу уңайдан бер сүзе бар. «Кем дә кем сугыш барганда яу кырыннан кача икән, ул бик зур гөнаһлы», – ди ул. Бу яктан карасаң, Ватан алдында бурычыңны үтәүдән куркып, илдән качу – әлбәттә, гөнаһ. Ник дигәндә, Ватанны саклау ул – фарыз, тиешле гамәл.

**:: Махсус операциягә китмәгән ирләргә нинди бурыч йөкләнә? Монда калган хатын-кызлар өстендә нинди бурыч бар?**

– Махсус операциягә китмәгән ирләр, тырышып эшләп, анда киткән туганының гаиләсен кайгыртып, аларга ярдәм итәргә тиеш. Чөнки ул бу нәселдәге баш ир булып кала. Монда калган хатын-кызларга килгәндә, моңа кадәр ир-ат алып барган бөтен вазыйфалар хәзер аларга төшә. Әмма бу очракта бер нәрсәне онытырга ярамый: хатын-кыз янында һәрчак ир-ат булырга тиеш. Кыз бала әлегә кияүгә чыкмаган икән, аны әтисе тулысынча саклый, яклый, матди һәм рухи яктан ярдәм итә. Кияүгә чыккач, бу бурыч иренә йөкләнә. Әгәр ире Ватанны сакларга киткән икән, бу бурыч яңадан аның әтисенә, ир туганы җилкәсенә күчә. Кызганыч, хәзерге заманда бу – ят күренеш. Туганнар да авыр чакта хәл белеп килү белән генә чикләнә. Нәтиҗәдә хатын-кыз ир-ат вазыйфасын да үз җилкәсендә тарта башлый.

**:: Соңгы арада килеп туган вазгыятьтә күңел ачу чараларын, концертларны тыю-тыймау турында бәхәс купты. Ничек уйлыйсыз, шушы авыр көннәрдә алар безнең тормышыбызда булырга тиешме-юкмы?**

– Күңел ачу чаралары төрле булырга мөмкин. Җыелышып, рәсүлебезгә салават әйтү, Коръән ашлары уздыру рөхсәт ителә. Ярымшәрә килеш чыгып җырлаучы, шамакайланучылардан торган концертлар исә ил-көнебез тыныч булганда да дин ягыннан тыела. Бүгенге вазгыятьтә исә әйткән дә юк. Ватаныбызны саклау бурычы килеп баскан катлаулы шартларда алар, гомумән, тыелырга тиеш. Мондый чорда шул ук телевизор, радиолар аша күбрәк дин әһелләрен сөйләтеп, халыкка вәгазьләр сөйләп, күңел тынычлыгы табарга ярдәм итү, дога кылу тәртибен аңлату-өйрәтү күпкә хәерлерәк булыр.

Илдар Мөхәмматҗанов

## Йәгез, бер дога!

### ВАТАННЫ САКЛАУЧЫЛАР ӨЧЕН

«Әшһәду әлләә иләһә илләллаһу вә әшһәду әннә мухәммәдән гәбдүһү вә расүлүһү».

*Мәгънәсе*: «Шәһадәт бирәм: Аллаһы Тәгаләдән башка гыйбадәт кылырга яраклы илаһ юк. Янә шәһадәт бирәм: Мөхәммәд – Аллаһы Тәгаләнең колы һәм илчесе».

### УЛЛАР ӨЧЕН ДОГА

«Аллаһүммә инни әстауди'укә ибни фәхфәз динәһү вә нәфсаһү вә күн 'әүнән ләһү вә руддүһү салимән мин күлли мәкруһин вә ганимән би күлли хәйр».

*Мәгънәсе*: «Йа Аллаһ, Сиңа үземнең улымны ышанып тапшырам! Аның динен һәм тормышын сакла, аңа ярдәмче бул, аны һәртөрле золымнан исән-сау һәм хәерлесе белән баетып кайтар!»

### ИРЕҢ ӨЧЕН ДОГА

«Аллаһүммә инни әхраҗту зауҗи мин хәүли вә куввәти илә хәүликә вә кувватикә фәхфәзһү аллаһүммә бихифзикә вә әб'ид 'әнһү күллә мә ядурруһү вә юьзиһи вә а'идһү иләйә 'алә хәйр».

*Мәгънәсе*: «Йа Аллаһ, мин үземнең иремне Сиңа ышанып тапшырып җибәрәм! Йа Раббым, аны якла, аңа зыян салырлык һәм авырту китерерлек һәр нәрсәдән сакла, һәм аны миңа исән-имин кире кайтар!»

## Качып булмый

Бер юлы Газраил галәйһиссәлам Сөләйман галәйһиссәлам янына килгән. Күпмедер вакыттан соң ул Сөләйман галәйһиссәлам янында торган кешегә текәлеп карап тора башлаган. Теге кеше аның күз карашын сизеп, Сөләйман галәйһиссәламнән:

– Бу кем? – дип сораган.

Пәйгамбәр:

– Бу – Газраил, – дип җавап биргән.

Бу кеше:

– Мөгаен, ул минем җанымны алырга телидер. Җилгә мине Һиндстанга илтеп куярга әмер ит, – дип әйткән.

Сөләйман галәйһиссәлам аның үтенечен башкарганнан соң, Газраилдән нигә бу кешегә шулай карап торганын сораган. Ул:

– Миңа бу кешенең җанын Һиндстанда вакытта алырга кушылган иде. Әмма аны синең янында күреп гаҗәпләндем, шуңа да текәлеп карап тордым, – дип җавап биргән.

**Нәсыйхәт**

Кеше кайда гына булмасын, үлем аңа киләчәк. Коръәндә: «Һәр җан иясе үлемне татыячак», – дип язылган.

«Дин вә мәгыйшәт» газетасыннан

## *Түш кесәдә – дога*

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте Татарстаннан мобилизацияләнгән солдатлар өчен түш кесәсенә салып йөри торган махсус дога җыентыклары әзерләп чыгарган. Бу хакта нәзарәтнең матбугат хезмәте хәбәр итте.

Китаплар — уч төбенә сыйдырышлы, димәк, солдатлар аларны һәрвакыт үз янында тота һәм махсус хәрби операция үткәрү урыннарында авыр минутларда файдалана ала. Махсус җыентыкта Аллаһыдан ярдәм һәм яклау сорау өчен, шулай ук борчылу һәм куркудан, дошманнардан котылу өчен һ.б. догалар тупланган.

Моннан тыш, солдатларга кече форматтагы тагын бер басма — татар телендә «Авыр вакытларда укыла торган догалар» тапшырылачак.

dumrt.ru

## Хәдис

«Күтәрә алмаслык бәла-казалардан, бәхетсезлеккә юлыгудан, начар тәкъдирдән һәм дошманнарны сөендерә торган хәлгә төшүдән саклавын сорап, Аллаһка сыеныгыз».

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ӘЛЕГЕ БИТТӘ КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ, ДОГАЛАР БУЛУ СӘБӘПЛЕ, КАДЕРСЕЗЛӘМӘВЕГЕЗ СОРАЛА

Лилия ГЫЙМАЗОВА

# Ә син таныйсыңмы?

**Уенның чираттагысын тәкъдим итәбез. Шартлар шул ук: җырчы һәм җырның исемен язып җибәрергә кирәк. Тулы, дөрес һәм беренче җавап бирүчегә бездән бүләк – телефонына 100 сум! Җавапларны +7 (904) 718-14-69 номерына юллагыз.**

*Газетабызның узган санында чыккан «Ә син таныйсыңмы?» уеның җиңүчесен билгеләр чак җитте. Иң төгәл җавапны беренчеләрдән булып Казаннан **Алсу Шәкурова** юллады. Афәрин! Бүләк – хуҗасында. Ә рәсемнәр астына без Булат Нигъмәтуллинның «Торналар», Дилбәр Фәиз башкаруындагы «Ә син үзең», Василә Фәттахова репертуарыннан «Бәхетебез бикле атмасын» җырларын яшергән идек.*

«Еллар үткән, без үзгәргән, ләкин яшьлек калган авыл киче – һаман да шул», – ди җырчы.

Әлеге җырны яшь популяр егет башкара. «Ярым да – син, парым да – син, бәхет-шатлыгым да – син», – ди ул.

Бу җыр салкын кышларда җылытырдай һәм анда җырлап торырдай җан дусларга багышлана.

## ФОТОГРАФ ТАҢСЫЛУ ГАЛИМОВА:

# «КӨНДӘЛЕК ТОРМЫШКА МИЛЛИЛЕК ҮТЕП КЕРӘ БАШЛАДЫ»

**Фотограф һөнәренең нинди кызыклы яклары бар? Фотосурәткә төшергәндә нәрсә мөһим? Милли фотосессияләргә ихтыяҗ зурмы? Бүгенге төрки йөзләр – нинди алар? Сәхифәбезнең кунагы – фотограф, «Төрки йөзләр» проектының авторы Таңсылу ГАЛИМОВА белән әнә шулар турында сөйләштек.**

**:: Ни хәл?**

– Ярап тора. Ил-көндәге хәлләр тотрыклы булмагач, фотосессияләргә ихтыяҗ бөтенләй бетәр инде, дип уйлаган идем. Алай булып чыкмады. Гаилә белән фотога төшәргә теләүчеләр артты. Күрәсең, соңгы вакыйгалар кешеләргә гаилә кыйммәте турында искәрткәндер. Аннан соң, мин «Төрки йөзләр» проекты өчен ел фасылы алышынган саен яңа образ ясарга тырышам. Хәзерге вакытта көзге образ белән мәш киләм.

**:: Гомумән, фотография белән кайчаннан бирле кызыксынасыз? Һәм бу кызыксыну кайчан һөнәрегезгә әверелде?**

– Мәктәптә укыганда ук кызыксына идем инде. Безнең гади генә фотоаппарат бар иде, шуңа нәрсәдер төшереп маташканым хәтердә. Институтта укыганда, абый белән апам профессиональ камера бүләк итте. Фотога төшерү бер мавыгуыма, хоббига әйләнде. Төп һөнәрем буенча икътисадчы мин. Кире банкка эшкә чыгарга теләмәгәнлектән, декрет ялында утырганда фотограф булып карарга уйладым. Менә шулай әкренләп кызыксынуым кәсепкә әйләнде.

**:: Әти-әниегез (Сәрия һәм Энгель Фәттаховлар) каршы булмадымы?**

– Башта аңлап бетермәделәр. Җитди эш кирәк, диделәр. Ләкин мин барыбер үземнекендә тордым. Соңыннан күнделәр, ахры, каршы сүз әйтмәделәр.

**:: Фотографлар – шактый кызыклы һөнәр ияләредер ул, әйеме?**

– Алар әйләнә-тирәдәге дөньяга сизгеррәк, димме соң. Нindидер үзенчәлекле урын, кызыклы күренеш күрдеңме, я булмаса фильмнан берәр кадр ошадымы – күз алдына фотосурәт рәвешендәге образ килә. Һәм тиз генә шул кадрны эләктереп калырга тырышасың.

**:: Һәр сурәт – шәхси тарих, диләр бит. Бу тарихны объектив аша күрсәтү кыенмы?**

– Гади фотосессияләрдә катлаулы түгел. Андый чакта кеше үзен матур итеп кенә күрергә тели. Һәм син аны матур итеп күрсәтергә тырышасың да. Ә инде сюжетлы, тематик фотосессияләрдә, әйтик, шул ук «Төрки йөзләр»дә фотосурәттә модельнең холкын да чагылдырырга кирәк. Ничегрәк чагылдырырга икәнен процесста аңлыйсың.

**:: «Төрки йөзләр» проекты турында сөйләгез әле. Ниләр белән рухланып башладыгыз сез аны?**

– «Төрки йөзләр»не ел ярым тирәсе элек башлап җибәрдем. Дөресен генә әйткәндә, милли стильдә фотосессияләр уздыру турында күптән хыяллана идем. Костюмнарны мәдәният йортларыннан алып торырмын дигән идем. Ләкин, кайсын гына алма, артык чуар тоелды алар миңа, ошамады. Ярар, бер вакыт килеп чыгар әле, дидем дә ул уйны калдырып тордым. Шулай берсендә үземнең икенче бер проектыма реклама ясар өчен, милли стильдә фотосессия уздырырга булдым. Образны үземдә булган киемнәрдән җыйдым, биюче кызлардан толымнар алдым. Матур гына фотосессия килеп чыкты. Социаль челтәрләрдәге аккаунтларыма куеп караган идем, кызлардан бик күп комментарийлар килде. Баксаң, күп кенә туташ-ханымнарның милли стильдә фотога төшәселәре килә икән. Шуны белү җитә калды, образлар уйлап, киемнәрен табып, фотога төшерә башладым.

Мондый милли фотосессияләр башка төрки халыкларында бик популяр бит ул. Хәзер биграк тә. Мин исә Башкортстаннан Илнара исемле фотографка карап рухландым.

**Блиц-сораштыру**

**– Төсле сурәтләрме, аклы-каралымы?**
– Аклы-каралы.
**– Ни өчен?**
– Алар холыкны, атмосфераны яхшырак чагылдыра.
**– Фотограф өчен иң мөһиме нәрсә?**
– Фантазия булу, кадрны күрә белү.
**– Ә бу – сәләтме, әллә өйрәнеп тә буламы?**
– Өйрәнеп була. Эшләргә, шомарырга, тәҗрибә тупларга гына кирәк.
**– Соңгы арада телефон профессиональ камераны кысрыклый башлады кебек. Сезгә алай тоелмыймы?**
– Әйе, чыннан да шулай. Бик уңайлы да бит ул. Телефонга төшерәсең, шунда ук эшкәртәсең. Киләчәктә без дә телефонга күчеп бетәрбез кебек.

**:: Милли фотосессияләргә ихтыяҗ зурмы?**

– Әйе. Кызыгып, кызыксынып киләләр. Аеруча кызлар арасында ихтыяҗ зур.

**:: «Төрки йөзләр» дигәч, иң беренче чиратта, озын кара чәчле, кара күзле кызлар килеп баса. Сезнең модельләрнең барысы да шундыймы?**

– Юк, мин аларны тышкы кыяфәтенә карап сайламыйм. Теләгән кешене төшерәм. Бу проектым турында ишетеп, бер мари кызы да элемтәгә чыккан иде. Аны үзләренең милли киемнәре белән төшердем.

**:: Ә сезнең өчен төрки йөзләр – нинди ул?**

– Озын кара чәчле, йөз чалымнары Азия халыкларына тартым булган, холкы буенча ирекле, үз бәясен үзе белә торган хатын-кыз.

**:: Гомумән, милли стиль модага керерме икән, ничек уйлыйсыз?**

– Әйе. Хәзердән үк миллилек көндәлек тормышыбызга үтеп керә башлады. Милли брендлар арта, көндәлек тормышта милли орнаментлар ешрак күренә. Элеккеге кебек читекләр, катлы-катлы күлмәкләр үк киеп йөрмәбез инде. Кеше тизлеккә ияләнде, шунлыктан киеменең уңайлысы кирәк. Менә шул көндәлек киемнәргә, көндәлек тормышка кереп китәр дип уйлыйм.

ӘҢГӘМӘНЕҢ ТУЛЫ ВАРИАНТЫ – VATANTAT.RU САЙТЫНДА

## 12 октябрь | Чәршәмбе

### ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хаерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан

### ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 16.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
10.00, 23.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ШУЛЕР». (Татар телендә) 16+
13.00, 01.05 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Туган авылым» 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
14.45, 05.35 «Татар халык җырлары» 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Бергәләп әйрәник» 0+
17.00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Металлург» – «Ак барс». Прямая трансляция 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 Док. фильм 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Соотечественники». А. Арбузов. Волшебник органической химии 12+
00.15 «Здоровая семья: мама, папа и я» 6+
00.30 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
00.40 «Халкым минем» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+

### ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+
09.40 «Ачыктан-ачык» 12+
10.40 «Туган авылым» 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 20.00, 04.15 «Таяну ноктасы» 16+
12.35 «Ватандашлар» 6+
15.30, 00.15 «Яшьләр тукталышы» 12+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
18.20, 21.25 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
19.15, 22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.30 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
23.05, 05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

### 1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. Большое кино: «СОБОР» (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

### РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Михаил Пореченков, Александра Богданова, Равшана Куркова, Юрий Чурсин, Николай Добрынин, Юлия Галкина, Юлия Мельникова, Илья Любимов. «ЧАЙКИ» 12+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.00 Детективный телесериал «МОРОЗОВА» 12+
02.55 Ярослав Бойко, Ольга Погодина. «СРОЧНО В НОМЕР! НА СЛУЖБЕ ЗАКОНА»

### МАТЧ ТВ

06.00 «Есть тема!» 16+
07.00, 10.00, 13.00, 15.15 Новости
07.05, 14.40, 19.15, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 13.05 Специальный репортаж 12+
10.25, 15.20, 03.00 Футбол. Лига чемпионов. Обзор 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир.
13.25 Смешанные единоборства. AMC Fight Nights. Владимир Минеев против Магомеда Исмаилова. Трансляция из Сочи 16+
16.25 «Вид сверху» 12+
16.55 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Металлург» (Магнитогорск) – «Ак барс» (Казань). Прямая трансляция.
19.30 Футбол. Лига чемпионов. «Наполи» (Италия) – «Аякс» (Нидерланды). Прямая трансляция
21.45 Футбол. Лига чемпионов. «Барселона» (Испания) – «Интер» (Италия). Прямая трансляция
00.55 Футбол. Лига чемпионов. «Рейнджерс» (Шотландия) – «Ливерпуль» (Англия) 0+
02.55 Новости 0+
04.05 «Больше, чем футбол». Док. фильм 12+
05.05 «Третий тайм» 12+
05.30 Футбол. МЕЛБЕТ-Первая Лига. Обзор тура 0+

### НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный сериал «ЛИХАЧ» (S) 16+
22.00, 00.00 Детективный сериал «БАЛАБОЛ» (S) 16+
00.20 Премьера. Сериал «ОТСТЕГНИТЕ РЕМНИ» (S) 16+
02.05 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» (S) 16+
03.05 «Их нравы» 0+
03.20 Остросюжетный сериал «МЕНТ В ЗАКОНЕ» (S) 16+

### ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.00 «Давай разведёмся!» 16+
10.00 «Тест на отцовство» 16+
12.10 «Понять. Простить» 16+
13.20 «Порча». «Укусы» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.25 «Верну любимого» 16+
15.00 «ПЯТЬ ЛЕТ СПУСТЯ» 16+
19.00 «ЦЫГАНКА». 7-я – 9-я серии 16+
22.10 «Порча». «Наказать обидчика» 16+
23.15 «Знахарка» 16+
23.45 «Верну любимого» 16+
00.20 «Понять. Простить» 16+
01.15 «Тест на отцовство» 16+
02.55 «Давай разведёмся!» 16+
03.45 «ЖЕНСКАЯ КОНСУЛЬТАЦИЯ» 16+
05.25 «По делам несовершеннолетних» 16+

### ЗВЕЗДА

05.00 «КАДЕТЫ». 3-я и 4-я серии 12+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 23.20 «ГОСУДАРСТВЕННАЯ ГРАНИЦА». «КРАСНЫЙ ПЕСОК». 1-я серия 12+
10.55 «Москва фронту». Док. сериал 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «ЛЕТУЧИЙ ОТРЯД». Фильмы 1-й и 2-й 16+
15.00 Военные новости 16+
18.15 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Неизвестные сражения Великой Отечественной». Док. сериал. «Под натиском финнов. 1941 год». Премьера! 16+
19.40 «Секретные материалы». Док. сериал 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
00.50 «НЕПОДСУДЕН» 12+
02.15 «ДЕВУШКА С ХАРАКТЕРОМ» 12+
03.40 «Оружие Победы». Док. сериал 12+
03.50 «ЛЕТУЧИЙ ОТРЯД». Фильм 1-й 16+

## 13 октябрь | Пәнҗешәмбе

### ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хаерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

### ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
10.00, 23.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ШУЛЕР». (Татар телендә) 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
14.00 «Туган авылым» 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
14.45, 01.10, 05.35 «Татар халык җырлары» 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Шома бас» һәм «Алты хәреф» 0+
16.00 «Казаннан – казанга» 12+
18.00 «Юлчы» 6+
19.00, 20.00 «Точка опоры» 16+
21.00 «Ватандашлар» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». Галиаскар из деревни Сикертан 12+
00.40 «Здоровая семья: мама, папа и я» 6+
00.55 «Если хочешь быть здоровым» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+

### ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.30, 23.05, 04.15 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
09.30 «Кунак БиТ шоу» 12+
10.40 «Туган авылым» 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «Таяну ноктасы» 16+
12.35 «Ватандашлар» 6+
15.30, 00.15 «Халкым минем» 12+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
18.20, 21.25 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
19.15, 22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Йөрәктән – йөрәккә». Татарстанның халык артисты И.Биктаһиров турында телеочерк 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

### 1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. Большое кино: «СОБОР» (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

### РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Михаил Пореченков, Александра Богданова, Равшана Куркова, Юрий Чурсин, Николай Добрынин, Юлия Галкина, Юлия Мельникова, Илья Любимов. «ЧАЙКИ» 12+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.00 Детективный телесериал «МОРОЗОВА» 12+
02.55 Ярослав Бойко, Ольга Погодина. «СРОЧНО В НОМЕР! НА СЛУЖБЕ ЗАКОНА»

### МАТЧ ТВ

06.00 «Есть тема!» 16+
07.00, 10.00, 13.00, 15.15 Новости
07.05, 14.40, 19.05, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 13.05 Специальный репортаж 12+
10.25, 15.20, 03.00 Футбол. Лига чемпионов. Обзор 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.25 Пляжный футбол. Московский международный кубок. Прямая трансляция
16.25 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Авангард» (Омск) – «Амур» (Хабаровск). Прямая трансляция.
18.45 «Записки тренера. Андрей Разин» 12+
19.30 Футбол. Лига Европы. «Бетис» (Испания) – «Рома» (Италия). Прямая трансляция
21.45 Футбол. Лига Европы. «Трабзонспор» (Турция) – «Монако» (Франция). Прямая трансляция.
00.55 Футбол. Лига Европы. «Ференцварош» (Венгрия) – «Црвена Звезда» (Сербия) 0+
02.55 Новости 0+
04.05 «Династия». Док. фильм 12+
05.05 «Катар-2022». Тележурнал 12+
05.30 «Одержимые. Дмитрий Саутин» 12+

### НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный сериал «ЛИХАЧ» (S) 16+
22.00, 00.00 Детективный сериал «БАЛАБОЛ» (S) 16+
00.20 «Мы и наука. Наука и мы» (S) 12+
01.10 Боевик «ПРАВИЛА МЕХАНИКА ЗАМКОВ» (S) 16+
02.50 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» (S) 16+
03.20 Остросюжетный сериал «МЕНТ В ЗАКОНЕ» (S) 16+

### ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.55 «Давай разведёмся!» 16+
09.55 «Тест на отцовство» 16+
12.05 «Понять. Простить» 16+
13.10 «Порча». «Дымовая завеса» 16+
13.40 «Знахарка» 16+
14.15 «Верну любимого» 16+
14.45 «БАБОЧКИ И ПТИЦЫ» 16+
18.45 «Спасите мою кухню» 16+
19.00 «ЦЫГАНКА». 10-я – 12-я серии 16+
22.10 «Порча». «Игромания» 16+
23.15 «Знахарка» 16+
23.45 «Верну любимого» 16+
00.20 «Понять. Простить» 16+
01.15 «Тест на отцовство» 16+
02.55 «Давай разведёмся!» 16+
03.45 «Не отрекаются любя» 16+
05.15 «6 кадров» 16+
05.20 «По делам несовершеннолетних» 16+

### ЗВЕЗДА

05.20 «ЛЕТУЧИЙ ОТРЯД». Фильм 2-й 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 23.20 «ГОСУДАРСТВЕННАЯ ГРАНИЦА». «КРАСНЫЙ ПЕСОК». 2-я серия 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «ЛЕТУЧИЙ ОТРЯД». Фильмы 3-й и 4-й 16+
15.00 Военные новости 16+
17.05 «Легенды госбезопасности. Григорий Григоренко. Ас контрразведки». Док. фильм 16+
18.15 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Неизвестные сражения Великой Отечественной». Док. сериал. «Второй штурм «Линии Маннергейма» 16+
19.40 «Код доступа» 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
00.55 «ЗЕМЛЯ, ДО ВОСТРЕБОВАНИЯ» 12+
03.20 «БЛИЗНЕЦЫ» 6+
04.40 «ЛЕТУЧИЙ ОТРЯД». Фильм 3-й 16+

## 14 октябрь | Җомга

### ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Вести Приволжского федерального округа»
09.15 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хаерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.15 «Вести-Татарстан»

### ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 20.30 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 Утренняя программа «Здравствуйте!» 12+
09.00, 16.30 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
10.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
11.00 «Нәсыйхәт» 6+
11.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ШУЛЕР». (Татар телендә) 16+
13.00 «Башваткыч» 12+
14.00 «Актуальный ислам» 6+
14.15 «Классный час» 12+
14.45 «Татар халык җырлары» 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф» 0+
16.00 «Аулак өй» 6+
17.00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Автомобилист» – «Ак барс». Прямая трансляция 6+
20.00 «Туган җир» 12+
21.00 «Юлчы» 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.00 «ХОРОШИЙ ДОКТОР». Художественный фильм 16+
00.35 «Здоровая семья: мама, папа и я» 6+
00.50 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
01.05 «Сөю көтә йөрәк». Телевизион нәфис фильм 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Татар халык җырлары» 0+

### ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40, 23.05, 04.15 «Ком сәгате» 12+
09.40, 15.30, 00.15 «Нәсыйхәт» 6+
10.30 «Казаннан – казанга» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Татарлар» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Рабис Сәлахов турында телеочерк 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30, 00.40 «Калеб» 6+
18.20, 21.25 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
19.15 «Туган җир» 12+
19.40 «Заман көзгесе» 6+
20.10, 22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
01.05 З.Хәким. «КҮРӘЗӘЧЕ». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

### 1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.40 «Человек и закон» с Алексеем Пимановым 16+
19.45 «Поле чудес» (S) 16+
21.00 «Время»
21.45 ФАНТАСТИКА (S) 12+
00.05 К 75-летию со дня рождения Ивана Дыховичного. «ВДОХ-ВЫДОХ» 12+
01.05 «СУДЬБА НА ВЫБОР». Многосерийный фильм (S) 16+
02.05 «Информационный канал» 16+

### РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.15 Местное время. Вести-Татарстан
21.30 Премьера. «Ну-ка, все вместе!» 12+
23.45 Премьера. «Улыбка на ночь». Программа Евгения Петросяна 16+
00.50 Елена Радевич, Евгений Ширяков, Елена Валюшкина, Владислав Ветров, Юлия Такшина, Янина Соколовская. «ЯБЛОЧКО ОТ ЯБЛОНЬКИ» 12+

### МАТЧ ТВ

06.00 «Есть тема!» 16+
07.00, 10.00, 13.00, 15.25, 18.55 Новости
07.05, 14.40, 19.00, 21.25, 00.20 Все на Матч! Прямой эфир
10.05 Специальный репортаж 12+
10.25, 15.30, 03.00 Футбол. Еврокубки. Обзор 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.05 «Лица страны. Анастасия Максимова» 12+
13.25 Пляжный футбол. Московский международный кубок. Прямая трансляция
16.35 «Один на один. ЦСКА – Спартак» 12+
16.55 Футбол. МЕЛБЕТ-Первая Лига. КАМАЗ (Набережные Челны) – «Енисей» (Красноярск). Прямая трансляция.
19.25 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Зенит» (Санкт-Петербург) – «Автодор» (Саратов). Прямая трансляция
21.55 Борьба. Международный турнир Борцовской лиги Поддубного. Прямая трансляция из Москвы
00.00 «Точная ставка» 16+
01.00 Футбол. Чемпионат Германии. «Шальке» – «Хоффенхайм» 0+
02.55 Новости 0+
04.05 «Посттравматический синдром». Док. фильм 12+
05.05 «РецепТура» 0+
05.30 «Всё о главном» 12+

### НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 19.00 «Сегодня»
08.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим» (S) 6+
09.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ» (S) 16+
11.00 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СЕВЕРНЫЕ РУБЕЖИ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «ДНК» (S) 16+
17.55 «Жди меня» (S) 12+
20.00 Премьера. Остросюжетный сериал «ЛИХАЧ» (S) 16+
22.00 Детективный сериал «БАЛАБОЛ» (S) 16+
00.00 «Своя правда» с Романом Бабаяном (S) 16+
01.40 «Захар Прилепин. Уроки русского» (S) 12+
02.05 «Квартирный вопрос» (S) 0+
03.00 «Таинственная Россия» 16+
03.40 Остросюжетный сериал «МЕНТ В ЗАКОНЕ» (S) 16+

### ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.15 «Давай разведёмся!» 16+
10.15 «Тест на отцовство» 16+
12.20 «Понять. Простить» 16+
13.25 «Порча». «Лёгкое счастье» 16+
13.55 «Знахарка» 16+
14.30 «Верну любимого» 16+
15.05 «КАССИРШИ» 16+
19.00 «ТО, ЧТО НЕЛЬЗЯ КУПИТЬ» 16+
23.00 «Порча». «Шесть элементов» 16+
00.05 «Знахарка» 16+
00.35 «Верну любимого» 16+
01.05 «Понять. Простить» 16+
01.55 «Тест на отцовство» 16+
03.35 «Давай разведёмся!» 16+
04.25 «По делам несовершеннолетних» 16+

### ЗВЕЗДА

06.10 «ЛЕТУЧИЙ ОТРЯД». Фильм 4-й 16+
08.20, 09.20 «КО МНЕ, МУХТАР!» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
10.40 «ДОРОГОЙ МОЙ ЧЕЛОВЕК» 12+
13.20, 15.05 «ДРУЖБА ОСОБОГО НАЗНАЧЕНИЯ» 16+
15.00 Военные новости 16+
15.40, 19.00 «РАЗВЕДЧИКИ». «ПОСЛЕДНИЙ БОЙ». 1-я – 6-я серии 16+
18.40 «Время героев». Премьера! 16+
22.00 «Здравствуйте, товарищи!» 16+
23.00 «Музыка+». Родион Газманов 12+
23.50 «РАФФЕРТИ». 1-я – 3-я серии 16+
03.15 «ЗЕМЛЯ, ДО ВОСТРЕБОВАНИЯ» 12+

## 15 октябрь | Шимбә

### ВГТРК ТАТАРСТАН

08.00 «Вести-Татарстан»
08.20 Местное время. Суббота

### ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
07.00 «Sиңа Миннән Sәлам» 6+
09.00 «Әй, язмыш, язмыш…» Илһам Шәриф 12+
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00 «Туган авылым» 6+
11.30 «Казаннан – казанга» 12+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Видеоспорт» 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
13.30 Концерт Республиканского конкурса творчества работающей молодёжи «Безнең заман – наше время» 6+
14.30 «ЧАРОДЕЙКА» 12+
16.20 «Өмет йолдызы». Эльмира Кәлимуллина концерты 6+
18.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
19.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
19.30 Новости в субботу 12+
20.00 «Адымнар» 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
21.30 Новости в субботу 12+
22.00 «Кунак БиТ шоу». Гөлнур Галиева 12+
23.15 «ПУТЕШЕСТВИЕ ВО ВЛЮБЛЁННОСТЬ» 16+
01.00 «Вехи истории». Путь татарстанского кинематографа 12+
01.25 «Каравай». Пересечение культур. Иран и Чечня 6+
01.50 «Өмет йолдызы». Эльмира Кәлимуллина концерты 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+

### ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә». Рабис Сәлахов турында телеочерк 6+
07.00, 15.00 «Sиңа Миннән Sәлам» 6+
09.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00, 18.15, 03.00 «Башваткыч» 12+
12.05, 19.05, 03.50 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 «Туган авылым» 6+
13.20 З.Исмәгыйлев. «КОДАЧА». Әлмәт татар дәүләт драма театры спектакле 12+
17.10 «Казаннан – казанга» 12+
17.45, 05.05 «Халкым минем» 12+
20.00 «Адымнар» 12+
20.30 «Гомер китабы». Лилия Муллагалиева концерты 6+
23.10 Н.Хисамов. «ЙОСЫФ-ЗӨЛӘЙХА». К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры спектакле 12+
01.00 «Олы юл әйтте…» циклыннан. Үткәннәрне барлап… Айдар Фәйзрахманов 6+

### 1 КАНАЛ

06.00 Телеканал «Доброе утро. Суббота»
09.00 «Умницы и умники» 12+
09.45 «Слово пастыря» 0+
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 Премьера. «ПроУют» (S) 0+
11.10 Премьера. «Поехали!» 12+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Видели видео?» 0+
14.35 Сергей Пускепалис. «А У НАС ВО ДВОРЕ…» (S) 12+
16.45 Фильм Александры Франк. «ДОНБАСС. ДОРОГА ДОМОЙ» (S) 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Премьера. «Ледниковый период. Снова вместе» (S) 0+
21.00 «Время»
21.35 «Клуб Веселых и Находчивых». Высшая лига (S) 16+
23.45 Премьера. «МОЙ ДРУГ ЖВАНЕЦКИЙ». 4-я серия 12+
00.40 «Великие династии. Воронцовы» 12+
01.45 «Моя родословная» 12+
03.05 «Наедине со всеми» 16+
03.50 «Россия от края до края» 12+

### РОССИЯ 1

05.00 «Утро России. Суббота»
08.00 Местное время. Вести-Татарстан
08.20 Местное время. Суббота
08.35 «По секрету всему свету»
09.00 «Формула еды» 12+
09.25 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00 Вести
11.50 «Доктор Мясников». Медицинская программа 12+
12.55 Ольга Сухарева, Мария Ахметзянова, Светлана Тимофеева-Летуновская. «ЗАТМЕНИЕ» 16+
17.00 Вести
18.00 «Привет, Андрей!» Вечернее шоу Андрея Малахова 12+
20.00 Вести
21.00 Премьера. Ольга Арнтгольц, Алексей Фатеев, Антон Морозов. «ДЕВЯТЫЙ ВАЛ» 12+
01.05 Пелагея Невзорова, Олег Загородний, Сергей Баталов, Екатерина Травова. «РАДУГА В ПОДНЕБЕСЬЕ» 12+
04.10 Сергей Маковецкий, Екатерина Федулова, Иван Стебунов, Светлана Иванова, Илья Иосифов, Дарья Михайлова. «ИСКУШЕНИЕ» 16+

### МАТЧ ТВ

06.00 «Есть тема!» 16+
07.00, 08.55, 09.40, 12.20, 18.25 Новости
07.05, 11.45, 13.40, 18.30, 21.00, 23.45 Все на Матч! Прямой эфир
09.00 Паркур. Чемпионат мира. Мужчины. Прямая трансляция из Японии
09.45 Паркур. Чемпионат мира. Женщины. Прямая трансляция из Японии
10.00 «ЗАРЯДКА ДЛЯ ХВОСТА». Мультфильм 0+
10.10 «ТАЛАНТ И ПОКЛОННИКИ». Мультфильм 0+
10.20 «БРЭК!» Мультфильм 0+
10.30 Бокс. Bare Knuckle FC. Майкл Пейдж против Майка Перри. Трансляция из Великобритании 16+
12.25 Пляжный футбол. Московский международный кубок. 1/2 финала. Прямая трансляция.
13.55 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. «Торпедо» (Москва) – «Локомотив» (Москва). Прямая трансляция
16.00 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. «Динамо» (Москва) – «Зенит-Казань». Прямая трансляция
18.55 Футбол. Чемпионат Италии. «Торино» – «Ювентус». Прямая трансляция
21.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Аталанта» – «Сассуоло». Прямая трансляция
00.30 Регби. PARI Чемпионат России. «Химик» (Дзержинск) – «Динамо» (Москва) 0+
02.00 Смешанные единоборства. UFC. Алекса Грассо против Вивьен Араужо. Прямая трансляция из США.
04.30 Бокс. Bare Knuckle FC. Майк Ричман против Айзека Дулиттла. Прямая трансляция из США

### НТВ

05.10 «Спето в СССР» (S) 12+
05.55 Детективный сериал «ИНСПЕКТОР КУПЕР» 16+
07.30 «Смотр» (S) 0+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «Поедем, поедим!» (S) 0+
09.20 «Едим дома» (S) 0+
10.20 «Главная дорога» (S) 16+
11.00 «Живая еда» с Сергеем Малозёмовым (S) 12+
12.00 «Квартирный вопрос» (S) 0+
13.00 «Секрет на миллион». Владимир Девятов (S) 16+
15.00 «Своя игра» (S) 0+
16.20 «ЧП. Расследование» (S) 16+
17.00 «Следствие вели…» (S) 16+
19.00 «Центральное телевидение» с Вадимом Такменевым (S)
20.20 Оригинальное музыкальное «Шоу Аватар» (S) 12+
23.00 «Ты не поверишь!» (S) 16+
00.00 «Международная пилорама» с Тиграном Кеосаяном (S) 16+
00.40 «Квартирник НТВ у Маргулиса». Группа ЙОРШ (S) 16+
02.00 «Дачный ответ» (S) 0+
02.50 «Таинственная Россия» 16+
03.30 Остросюжетный сериал «МЕНТ В ЗАКОНЕ» (S) 16+

### ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
07.10 «ЛЮБОВЬ И НЕМНОЖКО ПЛОМБИРА» 16+
09.00 «ЗОЛОТЫЕ НОЖНИЦЫ» 16+
10.55 «ПЕРЕПУТАННЫЕ». 1-я – 8-я серии 16+
19.00 «ВЕТРЕНЫЙ». 9-я – 12-я серии 16+
22.30 «ЛЮБОВЬ И НЕМНОЖКО ПЛОМБИРА» 16+
00.20 «ЦЫГАНКА». 1-я – 6-я серии 16+
05.20 «Не отрекаются любя» 16+
06.10 «6 кадров» 16+

### ЗВЕЗДА

05.40 «НА ЗЛАТОМ КРЫЛЬЦЕ СИДЕЛИ…» 6+
07.00, 08.15, 00.00 «ВСАДНИК БЕЗ ГОЛОВЫ» 12+
08.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.20 «Легенды науки». Анатолий Деревянко. Премьера! 12+
10.05 «Главный день». «Оружие Победы и конструктор Василий Грабин» 16+
10.55 «Война миров». Документальный сериал. Премьера! 16+
11.40 «Не факт!» 12+
12.10 «СССР. Знак качества» с Иваном Охлобыстиным» 12+
13.15 «Легенды музыки». Вячеслав Малежик 12+
13.45 «Морской бой» 6+
15.05 «РАЗВЕДЧИКИ». «ВОЙНА ПОСЛЕ ВОЙНЫ». 1-я – 6-я серии 16+
21.00 «Легендарные матчи» 12+
01.45 «РАФФЕРТИ». 1-я – 3-я серии 16+
05.00 «Хроника Победы». Док. сериал 16+

## 16 октябрь | Якшәмбе

### ВГТРК ТАТАРСТАН

08.00 Местное время. Воскресенье

### ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Ничек сезнең хәлләрегез?» Зәйнәб Фәрхетдинова концерты 6+
08.00 «Адымнар» 12+
08.30 «Полосатая зебра» 0+
08.45 «Әти һәм мин» 0+
09.15 «Тамчы-шоу» 0+
09.45 «Яшьләр тукталышы» 12+
10.15 «Ачыктан-ачык». Чулпан Закирова 12+
11.00 «Туган авылым» 6+
11.20 Раяз Фасыйхов концерты 6+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество» 12+
13.00 «Адымнар» 12+
13.30 Концерт Республиканского конкурса творчества работающей молодёжи «Безнең заман – наше время» 6+
14.30 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Трактор» – «Ак барс». Прямая трансляция 6+
17.00 «Видеоспорт» 12+
17.30 «Соотечественники» 12+
18.00 «Башваткыч» 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш…» Илһам Шәриф 12+
23.00 «ПАРИЖ! ПАРИЖ!» 12+
01.00 «Ком сәгате» 12+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+

### ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Заман көзгесе» 6+
06.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
07.00 Н.Гаетбаев. «Ничек кияүгә чыгарга?» К.Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры спектакле 12+
09.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
09.30 «Йөрәктән – йөрәккә». Габделҗаббар Кандалый турында телеочерк 6+
10.30 «Калеб» 6+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник» 6+
12.05, 00.40 «Яшьләр тукталышы» 12+
12.35 «Халкым минем» 12+
13.00 «Туган авылым» 6+
13.20 «ҮКСЕЗЛӘР» 12+
14.50 «Йөрәк җылысы». Филүс Каһиров концерты 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате» 12+
20.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
21.10 М.Горький. «КОЯШ ТӨШМӘГӘН ҖИРДӘ». К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры спектакле 12+
23.20 «Шаян хәлләр» 12+
01.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
02.50 Н.Гаетбаев. «НИЧЕК КИЯҮГӘ ЧЫГАРГА?» К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры спектакле 12+

### 1 КАНАЛ

05.25, 06.10 Фильм «МОЯ МАМА – НЕВЕСТА» (S) 12+
06.00 Новости
07.00 «Играй, гармонь любимая!» 12+
07.45 «Часовой» (S) 12+
08.15 «Здоровье» 16+
09.20 «Мечталлион». Национальная лотерея (S) 12+
09.40 «Непутевые заметки» с Дм. Крыловым 12+
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 Премьера. «Жизнь своих» (S) 12+
11.10 Премьера. «Повара на колесах» 12+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Видели видео?» 0+
14.40 Константин Хабенский, Андрей Федорцов. «УБОЙНАЯ СИЛА» 16+
16.45 «Романовы» (S) 12+
18.50 Премьера. «Поем на кухне всей страной» (S) 12+
21.00 «Время»
22.35 «Что? Где? Когда?» Осенняя серия игр (S) 16+
23.45 «Романовы» (S) 12+
00.45 «Камера. Мотор. Страна» 16+
02.15 «Наедине со всеми» 16+
03.00 «Россия от края до края» 12+

### РОССИЯ 1

05.35 Любовь Баханкова, Михаил Пшеничный. «МОЙ ЧУЖОЙ РЕБЁНОК» 12+
07.15 «Устами младенца»
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым»
09.25 «Утренняя почта»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00 Вести
11.50 Премьера. «Большие перемены»
12.55 Ольга Сухарева, Мария Ахметзянова, Светлана Тимофеева-Летуновская, Алексей Анищенко, Михаил Дорожкин. «ЗАТМЕНИЕ» 16+
17.00 Вести
18.00 Премьера. «Песни от всей души». Вечернее шоу Андрея Малахова 12+
20.00 Вести недели
22.00 Москва. Кремль. Путин
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.30 «НЕ ГОВОРИ МНЕ «ПРОЩАЙ!» 12+
03.10 «МОЙ ЧУЖОЙ РЕБЁНОК» 12+

### МАТЧ ТВ

06.00 Бокс. Bare Knuckle FC. Майк Ричман против Айзека Дулиттла. Прямая трансляция из США
07.30, 08.25, 09.10, 09.55, 12.20, 18.25 Новости
07.35, 09.30, 13.40, 18.30, 23.30 Все на Матч! Прямой эфир
08.30 Паркур. Чемпионат мира. Женщины. Прямая трансляция из Японии
09.15 Паркур. Чемпионат мира. Мужчины. Прямая трансляция из Японии
10.00 «УТЁНОК, КОТОРЫЙ НЕ УМЕЛ ИГРАТЬ В ФУТБОЛ». Мультфильм 0+
10.10 «ФУТБОЛЬНЫЕ ЗВЁЗДЫ». Мультфильм 0+
10.30 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 0+
11.00 «ЦСКА – Спартак. Гонка за лидером». Прямой эфир
12.25 Пляжный футбол. Московский международный кубок. Финал. Прямая трансляция
13.55 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. «Крылья Советов» (Самара) – «Сочи». Прямая трансляция
16.00 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Женщины. «Локомотив» (Калининградская область) – «Динамо-Ак Барс» (Казань). Прямая трансляция.
19.00 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. ЦСКА – «Спартак» (Москва). Прямая трансляция.
22.00 После футбола с Георгием Черданцевым.
23.20 Новости 0+
00.00 Футбол. Чемпионат Германии. «Бавария» – «Фрайбург» 0+

### НТВ

05.00 Детективный сериал «ИНСПЕКТОР КУПЕР» 16+
06.35 «Центральное телевидение» (S) 16+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «У нас выигрывают!» Лотерейное шоу (S) 12+
10.20 «Первая передача» (S) 16+
11.00 «Чудо техники» (S) 12+
11.55 «Дачный ответ» (S) 0+
13.00 «НашПотребНадзор» (S) 16+
14.05 «Однажды…» (S) 16+
15.00 «Своя игра» (S) 0+
16.20 «Следствие вели…» (S) 16+
18.00 «Новые русские сенсации» (S) 16+
19.00 «Итоги недели» с Ирадой Зейналовой
20.20 «Ты супер!» Новый сезон (S) 6+
23.00 «Звезды сошлись» (S) 16+
00.30 «Основано на реальных событиях» (S) 16+
03.20 Остросюжетный сериал «МЕНТ В ЗАКОНЕ» (S) 16+

### ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
07.20 «БАБОЧКИ И ПТИЦЫ» 16+
11.00 «КАССИРШИ» 16+
14.40 «ТО, ЧТО НЕЛЬЗЯ КУПИТЬ» 16+
18.45 «Пять ужинов» 16+
19.00 «ВЕТРЕНЫЙ». 13-я – 16-я серии 16+
22.25 «ЗОЛОТЫЕ НОЖНИЦЫ» 16+
00.15 «ЦЫГАНКА» 16+
05.20 «Не отрекаются любя» 16+
06.05 «6 кадров» 16+

### ЗВЕЗДА

05.30 «СИЦИЛИАНСКАЯ ЗАЩИТА» 12+
07.15 «ПРИКАЗАНО ВЗЯТЬ ЖИВЫМ» 12+
09.00 «Новости недели» с Юрием Подкопаевым 16+
09.25 «Служу России» 12+
09.55 «Военная приемка» 12+
10.45 «Скрытые угрозы» 16+
11.30 «Код доступа». «Всемирный голод. Миф или реальность» 12+
12.20 «Легенды армии» . Мовлид Висаитов 12+
13.05 «Специальный репортаж» 16+
14.55 «…И БЫЛА ВОЙНА». 1-я – 3-я серии 16+
18.00 Главное с Ольгой Беловой. 16+
19.45 «Легенды советского сыска». Док. сериал 16+
23.00 «Фетисов». Ток-шоу. 12+
23.45 «ДОРОГОЙ МОЙ ЧЕЛОВЕК» 12+
01.45 «КО МНЕ, МУХТАР!» 12+
03.05 «НА ЗЛАТОМ КРЫЛЬЦЕ СИДЕЛИ…» 6+
04.15 «Звездные войны Владимира Челомея». Док. фильм 12+
05.05 «Оружие Победы» 12+

---

РАДИО РОССИИ

**«ТАТАРСТАН» РАДИОСЫ НИЛӘР СӨЙЛИ?**

Казан – FM 99,2 МГц
Чаллы – FM 92,01 МГц
Түбән Кама – FM 101,1 МГц

radiotatarstana.ru

### Дүшәмбе, 10 октябрь

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10 Фатих Әмирхан. «Фәтхулла хәзрәт». Моноспектакль
13.10 «Татарстан дулкынында»
18.10 Яңалыклар
18.25 «Сердәшханә»
18.35 «Җыр – минем гомерлек юлдашым»

### Сишәмбе, 11 октябрь

6.00-8.00 «Новый день». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуальное интервью»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Пар канатлар»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.20 «Вместе за безопасность»
18.30 Габделфәт Сафин җырлый

### Чәршәмбе, 12 октябрь

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 «Вместе за безопасность»
7.20 Туры элемтә
7.45 «Юллар чатында»
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Актуальное интервью»
11.40 Прокуратура разъясняет
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Яшьлек аланы»
18.25 «Алмалы җырлар». Концерт

### Пәнҗешәмбе, 13 октябрь

6.00-8.00 «Новый день». Панорама событий. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр». Җәүдәт Дәрземан шигырьләренә җырлар
6.45 «Перекресток»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Татарстан: национальные проекты
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Офыклар»
18.25 «Газиз тавышлар». Хәнәфи Шәйдуллин

### Җомга, 14 октябрь

6.00-8.00 «Иртәнге нур». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00-7.10 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Вести ПФО
11.30 «Доброе братство лучше богатства» (на башкирском языке)
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.25 Лирик музыка концерты

### Шимбә, 15 октябрь

8.10 «Көзге моңнар». Әдәби-музыкаль композиция
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00 Трансляция радио России
10.10 «Гөлбакча»
10.30 «7 көн». Атналык күзәтү
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 «Мин әтине өйрәтәм». Радиосериал
11.25 Татар халык көйләре
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 «Әдәбиятыбыз сәхифәләре»

### Якшәмбе, 16 октябрь

8.10-9.00 «Между Волгой и Уралом». Объединенный радиожурнал семи республик
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-16.10, 17.00 Трансляция радио России
10.10 «Көмеш кыңгырау»
10.30 «7 дней». Обзор событий недели
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 Ял концерты
13.10, 15.10, 16.10 «Татарстан дулкынында». Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиевнең иҗат кичәсеннән репортаж

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

# «КАЯ ТЕГЕ КӨНЕГЕЗ?»

## ТҮБӘН БИШ АВЫЛЫНДА ЫРЫМНАРГА ЫШАНАЛАР

Зәй

**Зәй районының Түбән Биш авылында халык сынамыш, ырымнарга, әби-бабайлардан килгән гадәтләргә ышана. Ышанмас идең дә, эшләре кирегә китә башлый икән.**



Илдар Мөхәммәтҗанов

### Өч нарат сере

Түбән Биш авылында татарлар һәм керәшен татарлары яши. Катнаш гаилә коручылар да аз түгел. Ике динне дә хөрмәт итәләр. Без бик дус яшибез, диләр. Ышанулары да – уртак.

Авылга кергәндә күзебез өч наратка төште. Аның ботакларына күп итеп яулыклар эленгән. Наратларга бәйле риваятьләр бер генә түгел. Мәккәдән кайтучы берәү шул җирдә вафат булган, дигән сүзләр дә йөри. Анда гарәпчә язулы таш та тора. Тик авылда, татарларда агачка болай яулык бәйләү гадәте булмаган, диләр. Шул ук вакытта авылның беренче кешеләре христиан булган дигән мәгълүмат та бар.

Яулык эләргә барганда сөйләшергә ярамый, бу эшне таң атканчы башкаруың хәерле икән. Берәрсе зур эш башларга җыенса – туй уздырырга ниятлиме, йорт саламы – теләк теләп, шунда яулык бәйли. Авылның мәдәният йорты мөдире Наталья Вәлиәхмәтова да аны имтиханга барганда да, ерак юлга чыкканда да элгән.

– «Бишкәй» ансамбленә йөрүче балаларны Кара диңгезгә алып бардым. Зур җаваплылык бит. Сәфәргә чыкканчы, наратлыкка килеп, теләк теләдем. Берәр тикшерү киләсе булса да, шунда китә идем. Сынаганым бар: ниятләгән эш һәрвакыт уңа, – ди Наталья, елмаеп.

Авыл халкы сөйләвенчә, яулыкларга кагылырга ярамый. Берәү әлеге наратларның  күркәсен җыеп, кайнатып, төнәтмәсен эчкән. Шуннан соң аның күзләре сукырая башлаган. Авылда республика күләмендә семинар үткәргәндә, түрәләр яулыкларны тизрәк юк итәргә кушкан. Шуларны җыйган абзый ничә еллардан бирле йокысызлыктан интегә икән. Менә шундый сәер хәлләр дә күзәтелгән.

Дини бәйрәмнәргә бәйле ышанулар да бар монда. Тройсыннан соң икенче көнне Җир бәйрәме үткәрәләр. Бу көнне җиргә казык кагарга ярамый. «Кояш оя итмәс көн» дә бар. Аны 7 апрельдә билгеләп үтәләр. Быел ул пәнҗешәмбегә туры килгән. Бу көнне берәү дә эш башламый, хәтта кошлар да оя кормый икән. Авыл халкы быел шуңа игътибар иткән: җомга көнне  бөтен оялар сыерчыклар белән тулган. Элегрәк колхоз рәисе бу ырымга ышанмыйча, чәчү чәчтерткән, тик ул елны ашлык уңмаган. Икенче елны: «Кая теге көнегез?» – дигән, имеш. Сүз уңаеннан, Пасха атнасында бүрек кадәр болыт күренсә дә, ел уңышлы килер, дип юрала.

### Сыерлары да тәртипле

Китапханәче Лариса Кузнецованы әбисе, кич идән себерергә ярамый, өйдән байлык китә, дип өйрәткән. Өшкерү сәләте дә булган. Балтаны учакта кыздырып, шуның мае белән диатезлы балаларны төсләгән. Шунысы кызык: маен тирегә тамызгач, берничә көннән чирдән җилләр искән. Күзгә арпа чыкканнарны ясмыкка охшаган үлән яки пешкән ипи белән өшкергән. Кайбер авылларда, күз тигәндә, артыш яндыралар. Түбән Биштә исә  миләшнең файдасына ышаналар, аны баш астына куеп йоклыйлар.

Көтүгә бәйле йоланы да сораштык. Лариса  әйтүенчә, сыерны мөгезеннән бау белән бәйләп көтүгә илтәләр. Шул бауны алып кайтып, казанга урап куялар. Сыер качып йөрмәсен өчен шулай итәләр. Чыннан да, маллар көтүдән туп-туры өйгә кайта икән.

– Серле урыннар, ырымнар башкаларда да бар. Күрше Кабан Бастрык авылында сәнәк сугышы булган басу бар. Ул басуга трактор керсә, ватылып кала. Яшьләр сөйләвенчә, җәй көне мотоцикл белән барганда, шул урынга җиткәч, һава салкыная, аннан кабат җылына, – ди Наталья Вәлиәхмәтова.

Сәрия МИФТАХОВА

### Ә СЕЗ ЫШАНАСЫЗМЫ?

**Гөлнара УСМАНОВА, Буа районының Югары Лашчы  җирлеге башлыгы:**
– Безнең татар авылларында армиягә киткәндә, егетләр зират капкасына яулык бәйли. Мин – Югары Лашчы авылы кызы. Бу йоланы күптән беләм, тик каян килеп чыкканын әйтә алмыйм. Зират авыл башында урнашкан. Авыл көтеп торсын дигән ишарәдер бу. Яулыкны егетләр хәрби хезмәттән кайткач сүтеп ала.

**Гөлүсә ЗАКИРОВА, журналист:**
– Безнең Апас районының Кече Болгаер авылында элегрәк туйда киленне чоланга табагач, кисәү, уклау куеп сынаганнар. Әгәр алып куя икән – уңган килен. Солдатка армиягә киткәндә бер кисәк ипи каптырып, калганын мич башына куялар. Икмәк тартып тора, дигән ышану бар. Аннан кулын онга манып, матчага эз калдыра. Аны бу вакытта егетләр күтәреп тора. Энекәшне Чечняга шулай озаттык.

### Белгеч фикере

**Ләйлә ДӘҮЛӘТШИНА,**
**Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гыйльми сәркатибе:**
– Ырымнарга сафсата дип кенә карап булмый. Традицион мәдәниятнең нигезендә йолалар системасы, шулар эчендә ырымнар бар. Халык бу әйберләргә ышанмый икән, димәк, бу ырым, йола төшеп кала. Йортка, аның хуҗасына бәйле ышанулар актуаль. Әлбәттә, бөтен кеше дә йорт хуҗасына ышанмый, әмма ырымын тотмаганы да «әйе, бар ул» ди. Берәр эшең була калса, ул тәрәзәгә шакый, эндәшә, уята, диләр. Яңа йортка күчкәндә, аны күчерү гадәте дә саклана. Кемдер мендәр, табагач белән күчерә, кемдер: «Йорт иясе, әйдә, безнең белән яшә, исән-сау бул!» – дип чакыра. Төбәккә карап аерыла гадәтләр.
Сабыйны беренче 40 көндә ялгыз калдырырга ярамый. Мендәр астына пычак, кайчы, тимер әйбер куючылар бар. Әстерхан татарларында туй йоласын әйтә алам. Киленне кияү йорты капкасыннан керткәндә учак аркылы сикертәләр. Чистарыну, алга таба яхшы булсын дип юрау бу. Быел Баулы районының Уба авылында булдык. Анда элек киленнәр үзләре белән ике чиләк бодай алып килгән. Теләк теләп, шуны ишегалдына сипкәннәр.

# Сыер кайгысы түгел

**Бер көн иртән торып чыксак, яшь ярымлык үгез күбенгән. Мондый чакта дару эчерткәннән соң иң яхшысы – авызына аркылы йомры таяк (авызлык диләр бездә) каптырып, мөгезләренә тарттырып бәйләп кую һәм йөртү. Тауга каршы алып менә алсаң, тагын да шәп.**

Тик безнең үгез арканга йөргән мал түгел, борынчагы да юк, аның холкына, безнең көчкә ышанып, урамга алып чыгып булмый. Дару һәм авызлык, күбенгән ягын төрткәләү белән чикләнергә туры килде. Балтачтагы ветаптекада дару сатучы ханым бер генә флакон дару алырга җыенганымны белгәч: «Сез нәрсә, бу чорда бит бу дару һәр йортта аптечкадагы кебек торырга тиеш», – дигәч, запаска өчне алдым. Сатар өчен әйтми ул аны, бердән, даруы кыйммәт түгел, икенчедән, ул әйткән «бу чор» баштан күп тапкыр үткән.

Без яшь чакта әле авылда әллә ничә бозау асрау гадәте юк иде. Хуҗалык саен бер сыер да бер бозау, дистәләп сарык. Шул бозауны, гыйнварда туса да, март-апрельдә туса да, декабрьгә сугым малы булырлык итеп үстерәсе. Ул чакта ит сату дигән нәрсә юк, шул бер бозау үз гаиләңә җитсә, шөкер. Гаҗәп, әмма үстерәләр дә иде. Хәзер инде тана бозаудан шунның кадәр, үгез бозаудан шунның кадәр май чыккан дип мактанышу-аптырау гадәте юк, теге чакта бу дәрәҗә иде. Хәзер эч майларын алып та тормыйбыз. Шуңа күрә бозауны имидән аерганнан соң әниләр аны ничек тә күбрәк ашату чарасына керешә, әнә шул көннән малның күбенү ихтималы зур була һәм сугым чорына кадәр берничә тапкыр күбенә иде. Кибетләргә ипи күпләп кайта, малга ашату өчен 13 тиенлеген капчык-капчык алалар, әле кышка таба, эшләр җиңеләйгәч, үзләре дә мич тутырып пешерәләр иде. Көзен йокларга ятар алдыннан да бозауларга чиләк-табак тутырып я ипи, я пешкән бәрәңге чыгарып салалар.

Менә шуңа да, көз җитүгә, бозаулар берәм-берәм күбенә башлый иде. Ул чакта дарулар булмагандыр инде, кабарган өлешен махсус энә белән тишәләр иде. Аны теләсә ничек тишәргә ярамый, күп очракта мал табибы үзе башкара. Безгә килеп арыгач, мал табибы булып эшләүче мәрхүм авылдаш Вәиз абый: «Менә шулай итеп тишәрсез», – дип өйрәтеп, энәсен биреп калдырган иде. Әле дә исән – кирәге генә чыкмасын.

Күбенү мал-туар өчен уен-муен әйбер түгел, коткара алмый калган очраклар да, чалып өлгергән кешеләр дә булгалады. Дөрес, хәзер инде акрынлап-җайлап ашатып та, ел ярым – ике елда маллар шәп булып җитешә. Тизрәк өлгертә алсаң, синең файдага, әлбәттә. Үзеңә дип тәгаенләнгән, шушы көз азагы – кыш башында башкарылачак малны соңгы ике-өч айда барыбер тырышыбрак тәрбияләргә кирәк. Артыграк тырышып җибәргән чаклар да була…

Теге ветаптекадан алган даруның файдасы тиз тисә дә, ярты көн үгез авызлыгы белән, ике көн коры печән һәм суда гына торды. Барыбер абзарга кереп-чыгып йөрисе. Шул көннәрдә сыерның да «срогы» тулган, үткән ел дүрт көн алдан бозаулап, элекке «графигы»н бозган, шуңа аны да караштырасы иде. «Шәһәр кешесенең шушындый берәр проблемасы бармы икән?» – Мондый чакларда без, авыл кешеләре, еш кына шулай дип зарланып алабыз. Юкса белеп торабыз: һәр җирнең үз проблемасы, үз мәшәкате.

Тик берничә көн үтүгә, бу проблемаларның чүп кенә булуы аңлашылды. Ил белән бергә булган борчулы хәбәрләр көнелдән барысын да куып чыгарды. Шәһәр белән авыл тигезләште. Күбенгән үгез дә, бозаулыйсы сыер да онытылды. «Син быел сыерны карамыйсың да», – дип аптырады өйдәгеләр дә, башка елны атна-ун көн абзардан чыкмауны искәртеп… Авылда да башка гамьнәр шул.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

**Бөтендөнья татар конгрессында Пенза өлкәсендәге Качкару авылында туып-үскән Фирдәвес Тумеркинаның «Шакир паша эзләреннән» дигән китабын тәкъдим итү булды.**




«Татар-информ»

# ШАКИР ПАША

Әлбәттә инде, укучыларыбызда хаклы рәвештә, «Кем ул Шакир паша?» дигән сорау туар. Шакир паша – 1877–1878 еллардагы рус-төрек сугышында катнашкан, Госманлы империясендә генерал дәрәҗәсенә ирешкән бердәнбер милләттәшебез, китап авторының карт бабасы, ягъни Фатыйма әбисенең бабасы. Интернет челтәрендәге материаллардан күренгәнчә, Шакир паша турында фикерләр бик каршылыклы. Рус армиясенә хезмәткә алынган, төрекләргә әсирлеккә төшкән солдат дип фаразлап, аны сатлык җан дип кабул итүчеләр дә бар. Фирдәвес ханымның 40 еллап архивларда казынуы бушка китми. Ул карт бабасының сугыш башланганчы ук шушы илдә яшәвен, анда хәрби училищеда укыганда Төркия гражданы булырак сугышка алынуын ачыклый. Бабасы турында ул менә ниләр сөйли.

### Тыю

– Мөхәммәтшакир бабам 1855 елда Пенза губернасының Качкару авылында Мөхәммәтшәриф бабай гаиләсендә туа. Бу гаилә авылда бик атаклы: барысы да белемле имамнар, мөгаллимнәр, указлы муллалар була. Мөхәммәтшәриф бабамның каберенә авыл халкы бүген дә, хәтемнәр укып, борчыган сорауларына җавап эзләргә баралар, авылыбызның әүлиясе дип олылыйлар. Бабамның 12 баласы була: 7 малай һәм 5 кыз. Шулар арасыннан 6 малай – мулла, Мөкәррәмә исемле бер кызы абыстай була.

> Шакир исә 1874 елда Төркиягә укырга китәргә ниятли. Әмма әтисе ризалык бирми. Ата белән ул арасында каршылык килеп чыга. Ул вакытта өлкәннәр сүзеннән чыгарга ярамаган, мулла гаиләсендә бу бигрәк тә тыелган. Абруена зыян килмәсен һәм башкалар аның артыннан иярмәсен өчен, Мөхәммәтшәриф бабам халыкка улының үз ризалыгыннан башка гына китүен белгертми. Сорашучыларга: «Минем улым юк, вафат», – дип җавап бирә. Хәтта аны искә алуны да тыя. Шулай булса да, китәсе көнне әтисе аңа юл догасы укый һәм артыннан азан әйтеп кала.

147 елдан соң бу китапны язуым – кайчандыр Мөхәммәтшәриф тыйган мәгълүматларны дөньяга чыгару. Шуңа да бу адымымны кичерүен сорап, мин башта Закир мулла мәчетендә ифтар уздырдым. Мәчетнең имамы Рафик Акмаев хәтемнәр укыды, 80нән артык кеше килгән иде, барысы да дога кылдылар. Мин шунда авыл халкына Шакир паша тарихын сөйләп күрсәттем.

### Төркиядә

Шакир бабам башта Урта Азия мәдрәсәләрендә белем ала. Төркиягә, Истанбул шәһәренә килеп җиткәч, ул кая барырга да белми. Иң элек бер мәчеткә керә дә намаз укый башлый. Аллаһы Тәгаләдән ярдәм сорый. Аның оста итеп, чын күңелдән укыганына хәйран калып, андагы мулла тыңлап тора да, укып бетергәч, кемлеге белән кызыксына. Шакир дөресен сөйләп бирә. Мулла аны өенә алып кайта һәм үз баласы кебек тәрбияли. Укырга керергә булыша. Башта Шакир шул мәчеттә эшли, соңрак хәрби училищега укырга керә. Шул ук вакытта авылы белән дә элемтәсен өзми. Сирәк булса да, әнисенә хатлар яза.

Тик укуын тәмамларга мөмкинлек булмый, аны башка шәкертләр белән бергә сугышка алалар. Ул хезмәт итәргә эләккән корабльдә төрле милләт кешеләре була. Җиде тел белгәнлектән, Шакирга аралашу шактый уңайлы, шул сәбәпле ул командирның уң кулына әверелә. Тик корабльне шартлаталар, исән калганнарны төрекләр, судан җыеп алып, ни өчендер зинданга утырталар. Шакир анда да төннәр буе намаз, догалар укый. Бервакыт шулай аның янына бер солдат килә, күргән төшен юравын үтенә. Шакир аңа, тиздән син өеңә кайтырсың, дип әйтә. Чыннан да, аларны зинданда озак тотмыйлар, чыгаралар. Солдат командирларга Шакирның бик белемле икәнлеген сөйли. Ул, чыннан да, кешенең ни уйлаганын бик тиз сизенә торган булган. Бу хәбәр Госман пашага да барып ишетелә. Ул да, төшен юратырга дип, егетне үзе янына чакыртып ала. Шакир аңа курыкмыйча, син әсирлеккә эләгерсең, дип әйтә. Берәү булса, бу сүзләр өчен сугышчының башын да кисеп төшерер иде. Әмма Госман паша көлә генә, мондый белемне кайдан алуын сорый. Шакир аңа Урта Азия мәдрәсәләрендәге мөгаллимнәрдә белем алуы турында сөйли. Нәтиҗәдә Шакир хәрби хезмәтен дәвам иттерергә рөхсәт ала һәм, дөрес карарлар кабул итүдә катнашып, командованиедә тәрҗемәче һәм киңәшче вазыйфасын башкара.

Соңрак Госман паша, чыннан да, әсирлеккә төшә. Сугыш тәмамлангач, Шакир турында исенә төшерә дә үз янына чакыртып ала, киңәшчесе итеп тәгаенли. Шакир укуын да тәмамлый, хезмәтендә дә зур уңышларга ирешә, ахырда аны паша чинына кадәр күтәрәләр. Аякка басып, мөстәкыйль яши башлагач, ул, хатыны белән улын үз янына җибәрүләрен сорап, әтисенә хат яза. Ләкин карт бабай килене Хәдичә белән оныгы Хәсәннне җибәрми, алар урынына энесе Мөхәммәтһади китә. Шунда ул абыйсының хатынына өйләнгәнен әйтә, ризалыгын сорый. Шакир аңа бик күп бүләкләр һәм фоторәсемен биреп җибәрә. Ул яхшы аңлый: димәк, әтисе аңа өйгә кайтырга юлны япкан, хәтта хатыны белән баласы да аныкы түгел бит. Төркиядә төпләнеп, тагын да тырышыбрак эшләүдән башка чара калмый. Бераздан солтан Абдулхәмид аны үз янына алдыра, акчалата да, рухи яктан да бик нык булыша.

Абыйсы янына Төркиягә Мөхәммәтһади тагын бер килә әле. Нәкъ шул вакытта әтисе үлеп китә. Шакир аны җирләргә акча бирә. Шул акчага әтисе каберенә имән бурадан төрбә ясап (ул хәзер дә җимерелмәгән), таш куялар. Соңрак аның янына тагын ике туганы килә. Закир, абыйсы биргән акчага авылда таш мәчет төзетергә дип, кире кайтып китә. Кәрим исә абыйсы янында кала. Шакир да яңа гаилә кора. Ике ул, ике кыз үстерә.

### Эзәрлекләү

Фирдәвес ханымның нәсел җепләрен барлавы авыл тарихын өйрәнүгә дә этәргеч була. Хәер, аның әби-бабалары язмышы үзе үк – шул авыл тарихы инде ул. Әтисе Казим Дашкин – морзалар нәселеннән, колхозда шофер булып эшли, скрипкада уйный. Әнисе Гөләндәм Яваева (Шакир улы Хәсәннең оныгы) муллалар нәселеннән, колхозчы була. Автор безгә танышырга дип тагын бер китабын алып килгән иде. Ул – авылдагы гореф-гадәтләр турында. Шигырь һәм бәетләр рәвешендә язылган. Сакланып калсын дип, электән килгәннәрен дә китапка керткән. Алар арасында әбисе, әтисе ятатып җырлый торган «Төрмә хәле», «Арлю сывы» дигәннәре дә бар. Өченче китабын кулъязма формасында гына алып килгән. Ул – Шакир пашаның әтисе турында булачак.

Фирдәвес ханым үз архивыннан шактый гына экспонатлар да алып килгән. Шакир пашаның ике фоторәсеме сакланып калган. Берсен ул энесе Мөхәммәтһади артыннан җибәргән була. Россиядә инкыйлаб башлангач, оныгы Фатыйма аны келәм артына тегеп куя. Оныклары шул фотоны 100 ел диярлек яшереп саклыйлар. Ә икенче фото Төркиядәге гаиләсендә сакланган була, андагы туганнары җибәрә.

Качкару авылында революциягә кадәр төзелгән бер генә мәчет сакланып кала. Ул – Шакир паша акчасына төзетелгән Закир мәчете. Бүген дә сафта. Мөхәммәтшәрифнең балалары иң авыр елларда да диннән аерылмаган, үзләре төзеткән мәчетнең дә кадерен белгәннәр.

> Авылдан киткәндә, Шакир истәлеккә үзе белән бер генә нәрсә алып китә, ул да булса – әнисе үз кулы белән теккән, чиккән намазлык. Ул аны улына үз куллары белән бүләк итә. Төркиядәге кардәшләре сөйләвенчә, Шакир һәрвакытта да шуңа басып намаз укый торган була, бервакытта да алыштырмый. Аның оныклары намазлыкны һаман да саклап торалар икән. Казанга алып килгән экспонатлар арасында Шакир паша бүләк иткән кружка да бар, аны Фирдәвес ханымга әбисе тапшырып калдырган. Бу нәселнең дүрт буын хатын-кызлары кигән дүрт күлмәк тә бик зур кызыксыну уятты.

### Туганлык

Тарих битләреннән күренгәнчә, ул заманнарда татар халкы белән төрекләр арасында туганлык җепләре бик көчле була. Төрек солтаны Россиядәге мөселман халкын үзләренә күчеп килергә чакыра. Төркиядәге татар авыллары – моның дәлиле. Шакир паша да Төркия гражданы булып гомерлеккә шунда яшәп кала.

– Без бабабыз белән бик горурланабыз. Ул – татар баласы, Төркиядә үз акылы, зиһене белән татарның данын күтәргән кеше, – ди Фирдәвес ханым. Очрашуда галимнәребез дә катнашты. Алар генерал милләттәшебезнең язмышын ачыклау эшен дәвам иттерергә теләкләрен белдерделәр. Бүген иң мөһиме – интернет битләрендәге дөрес булмаган фактларга каршы чыгарлык язмалар бастыру, халыкка чынбарлыкны җиткерү, диде алар. Ә Фирдәвес ханым һәм кызы – блогер Ильмира Мусаутова Төркиядәге туганнары белән элемтәләрне тагын да ныгытырга җыеналар.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Гөлгенә ШИҺАПОВА

# БӘХЕТЛЕ КАРТЛЫК

**Гомер көзе. Аны матур тормышта, балалар игелегендә каршылаучылардан да бәхетле кеше юктыр, мөгаен. Янәшәңдә якын кешеләрең булу үзе үк гомерне озайта. Питрәчтә яшәүче Александр Липатов үзен тәрбияләгән кызы Аннага бик рәхмәтле. «Моның кадәр тәрбия булмаса, озак яши алмас идем», – ди ул.**

Без тагын бер айдан 103 яшен тутыручы Александр бабайның хәлләрен шушы көннәрдә 73 яшен бәйрәм иткән кызыннан сораштык.

– Әтием биш ел инде урын өстендә ята. Моңарчы бер дә зарланмады. Авырыйм димәде. Тик менә бот сөяге сыну харап итте үзен. Шул көннән бирле ятып кына тора. Ул – миңа, мин – аңа иптәш, – ди кызы Анна Александровна.

Александр Липатов Питрәч районының Улан авылында туып-үскән. Гаиләдә җиде бала була алар. Әмма, кызганыч, алтысы да кечкенәдән вафат була. Александрга исә озын гомер насыйп булган. 14 яшендә колхоз эшенә керешә ул. Әти-әнисенә ярдәм итәсе килә. Берничә елдан егетне армиягә алалар. Озакламый Бөек Ватан сугышы башлана. Александр армиядә чакта авырып китә. Табиблар анда туберкулез авыруы таба. Шуннан соң егетне хезмәткә яраксыз дип, дәваланырга хастаханәгә озаталар. Берничә елдан ул тернәкләнеп, савыгып китә. Авылга кайткач, кибетче булып эшли башлый.

– Шул елларда әниебез Татьяна Ивановна белән таныша да инде. Эштән курыкмаган егеткә кызның да күзе төшә. Әти белән әнинең 6 баласы дөньяга килгән. Бер туганыбыз сабый чагында ук үлеп киткән. Икенче абыем 36 яшендә вафат булды. Дүрт кыз туган аралашып яшибез. Иң олы апама – 76, икенчесенә – 75 яшь. Иң кечебезгә 69 гына әле. Алар өчесе дә Пермь өлкәсендә яши. Бик кайтып йөри алмыйлар. Әмма телефон аша еш аралашып торабыз, – дип сөйли Анна Александровна. – Әниебез 11 ел элек үлеп китте. 7 ай урын өстендә булды. Аны да мин тәрбияләдем. Ул үлгәч, әтине үзебезгә алып кайттык. Берничә ел элек ирем дә бакыйлыкка күчте. Хәзер әти белән икәү яшибез.

Александр бабайның көннәре ничек үтә икән? Әнә шул хакта сораштык. Колаклары ишетми башлаган. Шуннан телевизордан сурәтен генә карый икән. Әмма үз кирәген аңлый, ди кызы. Тешләре булмагач, Александр Павлович ит ашаудан туктаган. Аш та яратмый икән. Бөтен ашаганы – ботка, иң яратканы – манный, ди Анна Александровна.

– Әти үзен карап кына ашый ул. Чәйне татлы әйберсез генә эчә. Кайчагында чәкчәк алып кайтам. Аны ярата инде. Кайчак шоколад та бирәм. Организмына кирәктер, дим. Сөтне дә бик ярата, – ди кызы.

Кайбер көннәрдә Александр Павлович бик сызлана икән. Анна Александровна көчле дарулар биреп тора.

Александр Липатовның шәхси архивыннан

Авырганда, йокы булыша. Колаклары ишетмәсә дә, күзләре күрә.

– Бөтен әйберне аңлый, хәтере дә яхшы. Әмма кайчак, бигрәк озак яшәдем инде, дип тә зарланып куя. Безнең нәселдә 80 яшькә җитүчеләр бик күп. Әни дә 87 яшендә вафат булды бит. Озын гомерле булуның сере гади аның – тырышлык, эш ярату. Әти бер дә зарланмады. Әнине бик яратып, татулыкта 65 ел бергә яшәделәр. Бер-береңне аңлау да тормыш сикәлтәләрен узар өчен кирәктер, – ди кызы. – Әтине бик яратып тәрбиялим. Бер авырлыгын да күрмим. Гел янында булырга тырышам. Төннәрен бер эндәшүгә, ярдәмгә килем. Бар якыннарымны кадерләп тәрбияли алганыма сөенәм. Әтием дә бик рәхмәтле. Шул рәхмәте мине бәхетле яшәтә дә инде.

### ТӘРБИЯГӘ БАЛА АЛГАН ТӘНЗИЛӘ ГОМӘРОВА:

# «ӘТИ-ӘНИ ДИЮЛӘРЕ КАНАТ КУЯ»

Гомәровларның шәхси архивыннан

**Актаныш районының Табанлы Күл авылында гомер итүче Тәнзилә һәм Җәүдәт Гомәровлар бер дә картаерга ашыкмый. Әти-әни дип өзелеп торган сабыйлары бар авыруларын, йөрәктәге сагышларын оныттыра. Йортка ятим сабыйлар кайтып кергән көннән башлап, тормышлары үзгәрә дә куя аларның.**

– Ирем белән 1986 елда гаилә кордык. Матур гына яшәдек. Ике ул үстердек. Тик олысы 20 яшендә фаҗигале рәвештә үлеп китте. Бик авыр чакларым булды. Кая барып бәрелергә белмәдем. Шул чакта күңелгә, әллә ятимнәр йортыннан берәр сабый алыргамы икән, дигән уй килде. Мин аны иремә әйттем. Ул да риза иде. Шулай итеп, без бала алырга киттек, – дип сөйли Тәнзилә апа. – Ятимнәр йортына барып керсәк, безне бер кызчык көтеп утыра. Бер гаиләдә яшәгән дә аны кире кайтарганнар икән. Безне күрүгә, йөгереп каршыга чыкты. «Әтием, әнием», – ди. Ирексездән елап җибәрдем. Шул баланы ничек итеп ташлап кайтасың?!

Алар Анеса исемле кызны үзләренә алып кайта. Шул кызчык бар дөньяларын яктырта да инде! Бала хәсрәтен бала куанычы баса.

– Кызыбызны үстереп ятканда, күрше авылдан әниләре үлгән, әтиләре тәртипсез яшәгән балаларны алырга дип чакырдылар. Ул чакта сабыйлар приютта иде. Ике кыз, бер малай. Барып алып кайттык. Олы кызларның берсе бездә 2 елга якын, икенчесе 3 ел гына торып калды. Олысын 18е тулгач кияүгә бирдек. Малаебыз бездә 5 елдан артык яшәде әле. Алар инде хәзер үз тормышы белән яши. Кызлар кияүдә, малаебыз үз авылына кайтып, йорт салды. Рәхмәтле балалар булды алар. Бездән китсәләр дә онытмыйлар. Кызларым да хәлемне белеп, бәйрәмнәрдә котлап тора. Улым кунакка еш килә, – ди Тәнзилә апа.

Өч ятимне чыгарып җибәргәч, өйләре тагын бушап кала. Күп тә үтми, район опека бүлегеннән тагын шалтыраталар. Дүрт ятимгә әти-әни кирәк, ди алар. Гомәровлар каршы килми. Документлар җыялар да тагын сабыйларны бәхетле итү эшенә керешәләр. 2021 елда алар өенә дүрт бертуган кайта.

– Бу сабыйларның әти-әниләре исәнсау. Әмма алар тормышта башка юл сайлаган. Ата-ана өчен бала җавап тотмый бит инде. Шулай дидек тә үзебезнеке итеп кабул иттек. Безнең йөрәктә ятимнәргә урын күп ул, – ди Тәнзилә апа. – Ул сабыйлар кайтып керүгә «әтием», «әнием» диделәр. Аптырап та киттем. Балалар бу сүзләрне әйтергә тилмергән иде. Олы кызыбыз Ольга гына барын да аңлый, шуңа күрә безгә «апа», «абый» ди. Аңа – 17 яшь. Әмма ул бик рәхмәтле икәнен яшерми. Ярый безне алдыгыз әле, дип кенә тора. Шушы олы кызым 6 яшеннән кечкенә туганнарын барлап торган. Сабый чагы булмаган аның. Кулыннан килмәгән эше юк. Хәзер дә туганнарын карарга булыша. Нәрсә эшли башласам да, ярдәм итә. Тормыш өйрәткән аны.

Тәнзилә апаның тәрбиягә алган икенче кызы 5 нче сыйныфта укый икән. 2 малай әле бакчага йөри, ди ул.

– Тиздән миңа 60 яшь тула. Паспортка карамасам, бу хакта исемә дә төшермим. Балалар белән яшәрәм. Аларның җылы сүзләре йөрәгемне дәвалый. Бакчага килеп керүгә, улларым «әнием» дип каршыма йөгереп чыга, кочагыма сарыла. Их, шул чактагы хисләрне белсәгез иде сез! Йокысыз төннәр дә, алар авырган чаклар да онытыла. Үз чиреңне әйткән дә юк инде. Без бит бу дүрт баланы да приюттан алган идек. Килүебезне бер елдан артык көткәннәр. Шул сабыйларга карыйм да, дөрес эшләгәнмен, дип куям. Үз әниләре барын да белә алар. Кайчакта телефоннан сөйләшәләр. Туган көннәре җитсә, килмәсме, дип көтәләр. Тик өметләре генә акланмый, – ди Тәнзилә апа. – Бүген өебездә биш бала бар. Алар укырга китсә, өй гел буш кала. Ирем – балаларны илтеп куеп, каршы алучы. Анеса кызыбызны 7 нче сыйныфтан Минзәләгә йөртеп укытабыз. Педогогика көллиятендә махсус сыйныфта укый. Әтисе шимбә барып ала, ял илтә. Шулкадәр җитми кала инде безгә. Каникулларны зарыгып көтәбез инде хәзер. Олябыз Актанышта техникумда пешекчегә укый. Аны әтисе җомга кич барып ала, дүшәмбе илтә. Менә шулай атна узганын сизми дә калабыз.

Тәнзилә апа белән юл йөрү турында сөйләшкәндә, ул борчуын да әйтте әле. Баксаң, бөтенесе бергә җыелып, беркая да чыгып китә алмыйлар икән. Машинага сыймыйлар. Җиде урынлысы кирәк, ди ул. Әмма үз көчләре белән генә машиналарын яңага алыштыра алмыйлар.

– Әгәр бөтенебез сыярлык машина булса, кая гына бармас идек. Балалар кечкенә чакта йөртәсе килә бит. Берсен алып, икенчесен иартмичә, йөрәкләрен яралыйсы килми. Алар тиз үпкәли дә бит әле, – ди Тәнзилә апа. – Бала алыйммы, юкмы, дип уйлануучыларга йөрәкләрен тыңларга кушар идем. Безнеке төсле хәсрәт килгәнен көтмәгез, яхшылык эшләргә тырышыгыз. Балаларның бер рәхмәте иңнәремә канат куя минем. Бездә чакта балаларны кешедән ким-хур итмибез. Инде тормышта үз юлларын тапканнары матур яшәсен иде. Бер генә теләк: калганнарын үстерерлек көч һәм куәт, сәламәтлек, гомеребез булсын иде. Әтием-әнием дип өзелеп торган сабыйларга бар җылыбызны озак еллар бирә алсак иде.

# ҖЫРЛАРГАМЫ, ЕЛАРГАМЫ?

«Татар-информ»

**Инде хәзер нишләргә? Өлешчә мобилизация башлангач, артистлар әнә шулай аптырап калды. Повестка алмаган нәсел калмады, халыкның кәефе юк, концертлар куеп, җырлап йөрү дә килешмәс кебек.**

Ticketscloud билетлар агрегаторы да Россиядә өлешчә мобилизация башлангач, концерт һәм фестивальләрнең кичектерелүен күрсәткән. РБК хәбәр иткәнчә, 19 сентябрьдән 25енә кадәр йөзләгән чараның үткәрелмәячәге турында игъланнар пәйда булган. Бу гадәттәгедән 270 процентка күбрәк. Белгечләр, әлеге хәл озакка барырга мөмкин, дип фаразлый. Татар эстрадасы җырчылары да уйда.

### «Иң мөһиме – бердәмлек»

Дөрес, югалып калмаучылар да бар. Әйтик, Татарстанның атказанган артисты **Фирдүс ТЯМАЕВ**, махсус операция башлангач ук, гуманитар ярдәм күрсәтүне үзенә төп юнәлеш итеп алды.

– Хәзер артистлар арасында да, нишлик, ничек ярдәм итик, дип уйлаучылар, нәрсәдер эшләргә тырышучылар бар. Без инде махсус операция башланууга эшкә тотындык. 6 октябрьдә өченче автобус гуманитар ярдәмне җибәрдек. Автобусны минем энекәш йөртә. Донецк, Луганскига, андагы безнең солдатларга, ОМОН, спецназ егетләренә, ополчениегә ярдәм иттек, балаларга мәктәп кирәк-ярагы, халыкка кием-салымнар, шулай ук медикаментлар җибәрдек. Хәзерге вакытта медицина әйберләре бигрәк тә кирәк, – ди ул. – Башта акчаны үз көчебез белән, кешеләргә белгертмичә җыя идек. Чыгымнар зур булса да, үзебез күтәрдек. Хәзер инде ачыктан-ачык эшлибез. Чөнки Нурлат районы хәрби комиссариаты да бу эшне хуплый. Алар белән бергә тотынгач, автобуска әйберләр сыймый башлады. Бөгелмәдән «ГАЗель» һәм тагын ике автобус бара. Шуның берсе безнеке. «Боевое братство» дигәннәре шушы була инде.

Фирдүс Тямаев эшен хуплаучылар да, тәнкыйтьләүчеләр дә җитәрлек. Ул исә бу эшен дәвам иттерәчәген белдерә:

– Халык арасында төрлесе бар. Безне дә төрлечә гаеплиләр. Башка җырчыларда эшем юк, һәркем үзе өчен җавап бирсен. Мин шушы юлны сайладым. Ничек булса да, концертларны да, ярдәмне дә дәвам иттерәбез. Иң мөһиме, Фирзәр энекәш исән-сау әйләнеп кайтсын. Алар бит соңгысында бәрелешләр иң каты булган җирләргә кадәр барып җитте. Бу юлы да шулай ук эчкә үтәргә исәпләре. Кирәкле әйберләрне, тепловизор, квадракоптерларны алдык, юлга әзерләдек. Рәхмәт дус егетләргә, булыштылар, кыйммәтле җиһазлар алдылар. Гомумән, безгә кем ярдәм иткән, барысына да ихлас рәхмәт. Бигрәк тә гади халыкка. Һәр шәһәрдәге «Братство»га рәхмәт. Хәтта мәктәп балалары да ярдәм итә. Коллегалардан Рамил Шәрәпов кушылды. Бәлкем, башкалар да кушылып китәр әле. Бүген иң мөһиме – бердәмлек.

Ә мобилизацияләнүчеләргә килгәндә, кайгырмагыз, коткыга бирелмәгез, бар да яхшы булачак. Сәламәтлеге начар икән, ай дәвамында аларны кире җибәрерләр. Башта исемлек буенча җыйганнардыр, аннары карарлар. Бездә дә кире кайтучылар булды. Яхшыга өметләник.

Чакырсалар, үзе дә барырга әзер икәнен әйтә ул:

– Әгәр повестка килсә, барыбыз да барабыз. Әйтәм бит, туганнан туган энем баштан ук шунда. Икенче гуманитар ярдәм алып барганда, энем Фирзәр белән очраштылар. Видео аша шалтыраттылар, күздән яшьләр килде.

Фирдүс Тямаев әйтүенчә, киткән егетләргә дә, калган гаиләләргә дә авыр. Шуңа күрә, рухларын күтәрү өчен, хәрби күнекмәләр узучы егетләргә «Казан Экспо»да концерт куярга нияте барлыгын да әйтте:

– Теләгебезне җиткердек, әлегә җавап бирмәделәр. Әмма безнең төп игътибар – «кайнар нокта»ларда көрәшкән егетләргә. Аларга күпкә авыррак.

### «Елап кына дөнья үзгәрми!»

Татарстанда концертлар дәвам итә. Бу уңайдан кемдер гастрольләрдә йөргән җырчыларны тәнкыйтьли, кемдер бер мизгелгә генә булса да онытылып торганга рәхмәт укый. Җырчы мондый вазгыятьтә нәрсә эшләргә тиеш? Бу сорауга Татарстанның атказанган артисты **Илсөя БӘДРЕТДИНОВА** җавап бирде.

Социаль челтәрдәге сәхифәсендә ул: «Мин үзем дә – ир-ат бала әнисе! Бу көннәрдә ниләр генә язмыйлар безгә. Укырга куркыныч хәтта. Имеш, без кеше елаганда җырлап йөрибез. Сугыш башланды дип, кибетләрдә әйберләрне бушка бирә башладыларммы соң? Сез эшкә йөрүдән туктадыгызмы? Хәер… акыллылары аңлый бугай инде. Шундый вакытта булса да кешедән начарлык кына эзләп, белер-белмәс пычрак атып ятудан туктап торсак идек! Беркайчан да кемгәдер ярдәм иткәнемне кешегә чыгарганым булмады! Тик бу очракта мәҗбүрмен. Мин айга бер концертымны тулысынча хәйрия концерты дип игълан итәм! Кергән барлык акча мобилизацияләнгән егетләр файдасына китәчәк. Безнең егетләргә! Акыллы, сабыр бердәм булыйк!» – дип язып чыкты.

Телефон аша элемтәгә кереп, без бу адымга нәрсә этәрүе турында белештек.

– «Молодец» дип әйтсеннәр өчен эшләмим мин моны. Кулдан килгәнчә. Бәлки, кемгәдер үрнәк булыр. Монда коллегалар турында гына сүз бармый, тулаем халыкны күз алдында тотам. Ә бит шуның кадәр нәфрәт, шуның кадәр ачу күпләрдә! Хәтта шушындый вакытта да кеше кадерен белергә кирәк икәнне аңламыйбыз. Бу – үзәк өзгеч хәл!

Илебезгә зур кайгы килде. Бу афәткә шәхсән мин берничек тә тәэсир итә алмыйм. Нишлисең, чынбарлыкны ничек бар, шулай кабул итәргә кирәк. Өйдә акырып елап ятып кына дөнья үзгәрми! Мәсәлән, минем ике бертуган апамның да уларына повестка килде. Уртанчы апа белән сөйләшәм. Елый, әмма сиздермәскә тырыша. «Иркәм, елап озатканда, улыма бик авыр булачак. Шуңа, улым, мин дөрес тәрбияләгәнмен сине, син молодец, син – безнең терәгебез, исән-сау кайт, без сине догада көтеп торырбыз дип озатам», – ди. Һәм бу – миңа калса, дөрес фикер. Инде хәзер барыбыз да капланып елап утырыйкмы? Безнең елаудан хәрби хезмәткә алынган егетләргә ни файда?

Илсөя Бәдретдиновадан шуны да сорадык: хәрби операция барган җирләргә концерт куярга барыр идеме икән?

– Барыр идем дип уйлыйм. Аллага тапшырдык. Илгә килгән афәттән мин генә читтә кала алмам.

### «Мәгънәле җырлар сайларга кирәк»

Бөек Ватан сугышы вакытында да концертлар булган, хәзер дә халыкка юаныч кирәк. Татарстанның халык артисты **Зәйнәб ФӘРХЕТДИНОВА** әнә шулай ди:

– Халык күңелен юата алса, артисттан иң зур ярдәм шул инде. Әмма репертуарны карарга, кешене ярсыта торган номерларны алырга, җырларның да мәгънәлеләрен сайларга кирәк. Әле менә «Казан Экспо»да чыгыш ясадык. Ана кеше буларак күңел халәтемне аңлатып бирә торган түгел. Фонограммага авыз ачып торырга гадәтләнмәгәч, җырлый алсам ярар иде, дип тә уйладым. Җырладым. Егетләрнең кәефләре күтәренке булгач, минем дә күңел тынычланды.

Музыкант, алып баручы **Илмир ЯМАЛОВ** әйтүенчә, Ватан чакырса, һәркемгә дә барырга туры киләчәк:

– Мин гел укуда булдым, шуңа хәрби билетта «рядовой, артист театра и ансамбля» дип язылган. Хезмәткә чакырсалар, хәрби рухны күтәрү юнәлешендә эшләргә кирәк булачак. Артистлар хәзер дә тик утырмый. Хәйрия концертлары оештыручылар бар. Дөрес, күп артистлар бу эшләрен күрсәтми, бу очракта мин үрнәк булсынга халыкка белгертү ягында. Мәсәлән, мин дустым Илсур Шәйдуллин турында даими язып торам. Соңгысында «Казан Экспо»га барып, мобилизацияләнүчеләрнең хәлен белешә аласыз, дип яздым. Күпләр өчен бу да – файдалы мәгълүмат. Илсур: «Бөтен нәрсә бирелде, ашау да яхшы, хәтта «гражданский» ризыктан баш тарттым», – ди. Шаярып, моның кадәр ял иткәне булмавын да әйтә.

## Халык фикере

**«ВТ»ның «ВКонтакте» сәхифәсендәге сораштырудан күренгәнчә, халыкның 67 проценты концертлар кирәкми дигән фикердә.**

**Айсылу Галиева:**
– Бу – аларның һөнәре, эше. Аларга да ашарга, яшәргә, гаиләләрен тотарга кирәк. Һөнәрләрен алыштырып, мобилизациягә киткәннәр урынына станок артына баса алмыйлар бит инде, аның өчен дә белем кирәк. Тракторга утырып, басуга чыгар өчен дә белем һәм тәҗрибә кирәк, фельдшерларны алыштырыр өчен дә белем кирәк. Репертуарга игътибар итәседер – шул гына.

**Гөлфизә Мулланурова:**
– Җыр-музыка – рухи азык, җыелышып елап утыру тагын да хәсрәтне арттыра. Хатын-кызлар терәк булса гына, ир-егетләребездә көч, җину дәрте булачак. Башкорт егетләрен карагыз: алар елап китми, җырлап китәләр. Концертларга килгәндә, күптән түгел шәһәр филармониясенең сезон ачылышы концертын карадым. Эштән соң арып барган идем, ару-ларым, борчуларым онытылды.

**Люция Шәрәфиева:**
– Мин «Казан Экспо»да ир-егетләргә куелган концертны карагач, аларның һәр ягышны ничек итеп алкышлавын күргәч, кирәк икән, дидем. Кемдер кайгы-борчуын җырлап, моңланып, кемдер күңел халәтенә туры килгән җырны тыңлап баса. Үз-үзеңә генә бикләнмәскә кирәк. Якыннарын озаткан хатын-кызларга игътибарлы булырга кирәк безгә, кайгы-борчулары белән үзләре генә калмасыннар.

**Лениза Шәехова:**
– Татар халкы бит инде гомер-гомергә, басу кырларда эшләгәндә дә җырлар җырлап эшләгән, җинүләр яулаган. Хәзерге артистлар күбрәк туган ил турында җырласалар, яхшырак булыр иде. Мин авыр чакта югалып калмаган җырчыларның шул җырчылар дип уйлыйм. Пандемия вакытында Илсөя Бәдретдинованың «Торып бас!» дигән җыры миңа көч-куәт бирде, яшәргә өмет уятты.

**Рәсим Зарипов:**
– Болай да халык бер-берсе белән аралашмый, концертлар да булмаса, тәмам эчкә бикләнешеп бетәбез бит инде. Артистлар эшләп ашыйлар, кемгәдер кирәк түгел икән, концертка килми генә ул. Күбесе бюджетта утыра торган артистлар да түгел, алар ничек көн күрсен? Кайчакны мин аларны җәлләп тә куям. 30–40 кешегә дә концерт куялар. Аннан нинди керем булсын? Юл бәясе, төркемендәге кешеләргә түләү, аппаратура... Чыгымнары күбрәктер дә әле.

**«Килмәгәне болай да килми»**

Алып баручы **Шәрәпҗан (Рамил ШӘРӘПОВ)** да концертлар кирәк дигән фикердә:
– Халыкны пандемия вакытындагы кебек видеолар төшереп кенә юатып булмый. Башка юлларын да уйларга кирәк. Мин, мәсәлән, Фирдүс Тямаев егетләренә чыгып, хәлдән килгәнчә матди ярдәм тапшырдым. Ә концертларны кичектерергә кирәкмидер. Кеше болай да депрессиядә. Ул бит синең концертыңа күңелен юатырга, онытылырга килә. Килмәгәне болай да килми. Концертлардан соң тамашачы, ярый әле килдегез, онытылып җырлап утырдык, ди. Хәзерге вакытта иң кирәге – бердәмлек һәм сабырлык.

Гөлинә ГЫЙМАДОВА

---

Табиб язмалары

Руфина ФӘТТАХОВА

# РИШВӘТ

< Ахыры. Башы 30 сентябрь санында

– Ник приказны үтәмисез, Фәттахова? – ди.

– Хәле начарайды, аның бит тире белән сөяк кенә, 30–40 кило гына ул, – дип аңлатырга тырыштым.

– Сез Мәскәүдәге академиклардан да акыллыракмыни?! – дип, өстәл сукты.

Мин кызарынып-бүртенеп:

– Институтта укыганда «индивидуальный подход» дип өйрәттеләр безне, – димен.

– Күрсәтермен мин сиңа «индивидуальный подход»ны, марш моннан! – дип куып чыгарды ул мине.

Садыйковага даруны арттырып язарга туры килде. Безнең бүлек мөдире бик укымышлы апа иде, ул профессордан консультация ясаткан да, стрептомицин дигән уколдан бөтенләй коткарган мескен хатынны.

Вакыт уза тора. 8 Март якынлаша. Шунда, Садыйкова инициативасы беләндер дип уйлыйм, миңа 4 кеше исеменнән бүләк бирергә килешкәннәр палатадагылар. Туганнары аша бүләген дә китерткәннәр. 7 март көнне бик тантаналы рәвештә миңа ниндидер тартма бирергә тырышалар болар. Баш тарттым. Болар үгетлиләр, мин баш тартам. Эш көне бит, мин палатага кереп-чыгып йөрим, башка авырулар янына китәргә дә туры килә. Болар «бүләкне алмый» дип миннән зарланып, бүлек мөдирен чакырганнар. Хәзер мине бүлек мөдире дә үгетли башлады.

– Институтта взятка алырга өйрәтмәделәр! – дип нык торам.

Шуннан тагын баш табибка чакырттылар. Ул башта:

– Син нәрсә, 4 кешенең берьюлы үлүен телисеңме? – дип кычкырынды. Аннары минем һаман киреләнгәнне күреп: – Җаным, алай ярамый. Алар бит хөрмәт итеп, чын күңелдән бирәләр ул бүләкне. Алай бик бай булсаң (кая инде ул бай булу, безнең иң мохтаҗ еллар дисәк тә, артык булмас), алган булып кылан да соңыннан күрсәтми генә ташларсың, – дия-дия үгетләде. Алдым. Кая ул ташлау! Бу безнең өйдәге беренче чынаяк-чәй тәлинкәләре булды.

Садыйкова апаның язмышы бик кызганыч булып тәмамланды. Безнең авыруларның иң йогышлы чоры аларның үлгән чагында була. Шуңа күрә, хәлләре авырайганда, башкаларга йокмасын дип, аларны сырхауханәдән чыгармаска тырышабыз. Шуңа да карамастан, ниндидер сәбәп белән Садыйкова апа сырхауханәдән чыгып китте. Ике-өч көннән эшкә килсәм, кабул итү бүлегендә ыгы-зыгы киләләр. Ашыгыч ярдәм машинасы белән авыру китергәннәр. Мин бу авыруны күргәч шаккаттым, Садыйкова булуын көчкә таныдым. Кабул итү бүлегендәге сәке өстендә бик нык кабарган кеше ята иде. Гәүдәсе дә юан, куллары-аяклары да, бите дә. Сулыш алган саен, тагын да ныграк кабара бу. Һава эчкә керә һәм үпкә тишегеннән чыгып, тире астына тула бара, кире тышка чыга алмый. Табиблар ике яктан да кабырга арасыннан гәүдәсен тишеп, үпкәсенә торба керттеләр. Әмма бу аның хәлен бик азга гына җиңеләйтте. Садыйкова үз аңында килеш, ярдәм сорый-сорый, сулыш алган саен, һава җитмәүдән буылып, бик интегеп бакыйлыкка күчте.

Әйе, кайчакта иң изге ниятле табиблар да табигать алдында бик көчсез булалар шул.

---

# «МАКАРЕНКО»

Аспирантура тәмамлап, бераз вакыт узгач, шәһәр читендәге Каменка авылы янындагы нарат урманы эчендә урнашкан туберкулез сырхауханәсенә эшкә чыктым. Мине хроник авырулар ята торган бүлеккә билгеләделәр. Бу авыруларның күпчелеге – эчкечеләр, берничә мәртәбә төрмәдә утырып чыккан кешеләр һәм шулар ише әтрәк-әләм. Матур гына эшләп киттем, күпмедер вакыттан соң беренче мәртәбә төнге дежурга чыктым. Кичкә табарак, көндезге табиблар кайтып киткәннән соң, минем янга дежур шәфкать туташы йөгереп килде:

– Фәлән палатада бер авыру аңын җуйган!

Шәфкать туташы белән икәүләп киттек теге палатага. Азмы-күпме тәҗрибә тупланган, 3–4 ел хирургия бүлегендә эшләүнең дә нәтиҗәсе булгандыр, авыруның юри кыланганын аңлап алдым. Кан басымы, пульсы нормада, иреннәре алсу, тәне чиста, кыскасы, бернинди дә аң җую галәмәте юк. Бөтен палата (6–7 кеше), тып-тын калып, мине күзәтә. Шуннан, авыруны «аңга китерү» өчен җиңелчә генә яңаклый башладым. Бераз катырак та китте бугай, моның башы әле бер, әле икенче якка «тәгәри», тик түзә. Әллә бәхәсләшкәннәр, әллә мине тикшерәләр (чыннан да, яңа кеше, яшь табиб ниндирәк, моны «биетеп» булыр микән дип тикшерүләре булган икән. Анысы соңыннан аңлашылды).

– Зонд китерегез, хәзер ашказанын юдырабыз, мөгаен, агулангандыр! – дигән идем шәфкать туташына, «аңын җуйган» авыру ялт итеп сикереп торды:

– Үзеңнекен юдыр!

Безне күзәтеп торучы авырулар кычкырып көләргә тотынды, без дә көлә-көлә чыгып киттек. Икенче көнне: «Үзе ябык, беләкләре нечкә генә, ә куллары ирләр кулы кебек каты икән», – дигән бәяләмә ишеттем. Ул елларны өй сала башлаган вакыт иде. Көн саен цемент болгатып, кирпеч ташып көч җыйганмын, күрәсең.

Әлеге палатаның этлекләре моның белән генә бетмәде. Беркөнне иртәнге обходка кердем. Бер авыру урынында юк. Палатадашлары: «Монда гына иде. Бәлки бәдрәфкә чыккандыр, хәзер керер», – дигән булдылар. Ләкин авыру ул көнне бөтенләй күренмәде. Соңыннан ачыклангaнча, төнлә дә палатасында кунмаган булып чыкты. Икенче көнне генә пәйда булды бу. Иртән обход вакытында:

– Кичә обход вакытында юк идегез, төнлә дә сырхауханәдә кунмагансыз. Кайда йөрдегез? – дидем.

– Авылга кайтып, әбине җирләдем (урыс егете иде, «тещу хоронил»), – ди.

Тәртип бозуы турында сүзне озынайтмадым, хәлен сорадым, үпкәсен тыңладым да бүтән кешегә күчтем. Обход беткәч, «әбисен күмүче»дән:

– Әбиегезнең исеме ничек иде? – дип сорадым.

Көтелмәгән сораудан ул аптырап калды, бер исем дә әйтә алмый азапланды һәм палатадашлары көлә башлагач кына:

– Мария Ивановна, – дип мыгырданды.

– Кайсы авылга җирләдегез әбиегезне?

Казан егете иде бу авыру. Бер авыл исемен дә белми иде, ахры, бөтенләй аптырап калды.

Бер үк әбисен 2–3 мәртәбә «җирләгәч», әлеге ялганчы авыруны сырхауханәдән чыгарырга туры килде.

Шул еллардан тагын бер вакыйга истә калган. Безнең Каменка Биектау станциясенә якын гына урнашкан, җәяүләп 10–15 минутлык юл. Кайвакыт кирәк-яраклары шундагы кибеткә барып алгалый идек. Ул елларны кер юу порошокларына кытлык иде. Берккөнне Биектау кибетенә кер юу порошогы кайткан. Каменкага ул хәбәр ничек килеп ирешкәндер – анысы билгеле түгел. Әмма табиблар, шәфкать туташлары Биектауга порошокка йөгереп барып кайтканнар (кайберәүләр эшсезлектән интегеп йөргән авыруларны җибәргән. Туберкулезның башлангыч чорында гадәттә авырулар үзләрен бик яхшы хис итәләр). Мин порошок турында ишетми калганмын. Төшкә табарак бер авыру (тегe мин яңаклаган кеше иде, ахры):

– Доктор, сез кер юу порошогы алдыгызмы әле? – ди.

– Юк, нинди порошок, каян алыйм мин аны? – димен.

– Соң Биектауга китергәннәр бит. Бөтен Каменка порошоклы булды ич инде. Сез белмәдегезмени? Ярар, зарар юк, хәзер үзем барып киләм, бирегез 3 тәңкәгезне!

Сөенә-сөенә 3 сум бирдем (хәзергегә әйләндерсәк, 250–300 сум тирәсе (10 ел элек язылган язма бу). Китте дә юк булды авыру. Бүтән Каменкада бөтенләй күренмәде. Икенче көнне әлеге вакыйганы коллегама сөйләгән идем, ул:

– И-и, Руфина… Нәкъ кешесенә биргәнсең! Карак бит ул. Онытсин ул 3 сумыңны, – дип көлде генә.

– Ник алай дисең. Макаренко карак балаларга ышаныч күрсәтеп тәрбияләгән бит, – дидем.

Шул көннән миңа «Макаренко» дигән кушамат тагылды. Акрынлап 3 сум да, теге вакыйга да, берәр елдан кушамат та онытылды. 2–3 еллап вакыт узгач, Каменкада минем янга таныш түгел бер ир килде:

– Сез Фәттаховамы?

– Әйе.

– Минә сезгә 3 сум.

– Сез кем, бу нинди 3 сум?

– Анысы не важно! Сездән кайчандыр 3 сум алып, кире бирмәгәннәр. Порошокка җибәргән булгансыз… Ул үзе би-ик еракта инде, – диде дә бүтән берни дә әйтеп-аңлатып тормыйча китеп барды.

## БАЗАРДА БУЛГАН ХӘЛ

**Тукаебыз әйтмешли, кемдер алдый монда, кемдер алдана. Бу хәлне бер егет сөйләде.**

Күзгә салкында кияр киеме калмагач, киткән бу базарга туп-туры карап. Ошаган курткасын киеп караган да сатып алган.
– Тагын кирәк әйберең юкмы? – дип сорый сатучы абзый.
– Джинсы чалбар кирәк иде шул.
– Әйдә, киттек минем белән!
Абзый моны үзенең джинсы сатучы дустына илтеп тапшыра һәм китеп бара.
– Бу чалбар ничә сум?
– Сиңа арзанрак бирәм, 5 меңнән.
– 5 мең??? Куп дигәндә 2 мең бит моның бәясе!
– Што син! Бу бит фирменный!
Егет бу абзый янынннан сызу ягын карый. Аңлашыла ки, бу бәядә куртка сатучының да өлеше бар, клиентны ул алып килде бит. Базардан чыгышлый куртка сатучы абзый очрый моңа:
– Алдыңмы джинсы?
– Әйе, бик зур рәхмәт, дустыгыз миңа бик шәп чалбар сатты һәм нибары 7 мең сумга гына! – ди егет һәм базардан чыгып тая. Соңыннан куртка сатучы абзый, 7 меңлек джинсы сатучы дусты янына барып, күпме процент сорагандыр, анысы безгә нәмәгълүм. Әмма теге егетнең менә дигән өске киеме бар хәзер һәм… янга калган 5 мең сум акчасы!

## Әз-мәз мәзәк

* * *

Пессимист булу бик уңайлы. Ахырдан син һәрвакыт йә хаклы, йә шатлык кичерәсең.

* * *

Матурлык дөньяны коткарачак, дигәннәр иде. Берәр срогы бар микән аның?

* * *

Бер ир-ат эшкә урнашырга килә.
– Кызганыч, сез безгә туры килмисез. Безгә креатив, иҗади үсә ала торган кешеләр кирәк.
– Алайса, хезмәткәрләрегез иҗади үсеп бетеп, эшләргә кеше калмаса, шалтыратырсыз.

* * *

Велосипедчылар юлыннан җәяүлеләр юлына күчәргә ашыкмагыз. Җәяүлеләр юлыннан элдерүче самокатлар күпкә куркынычрак.

**Сканворд җаваплары**

**Горизонталь:** Җидегән, чыбыркы, Ира, бәс, алма, лак, Ләбиб, балчык, сала, ул, Юлчы, Курку, яу, Сува, Яншык, Пяст, абсурд, талкыш, әй, апай, рия, бәгъзе, Биг, Рәшә, алаша, ак, зикер, Феррари, Фәндәс, Луи, раритет, пәри.

**Вертикаль:** Празат, Лилия, стакан, абыстай, баз, чикләвек, Илфар, Мисыр, ыргак, ау, балык, Аши, Кешнер, Бесы, Акуаб, яр, ИП, РБК, әз, пәлтә, чәүкә, скаут, суер, ыслау, бәлеш, Ити, әл, ядрә, баян, Гаяр, ушу, бу, Әзһәр, Лукойе.

## Беләсең килсә...

**1 Бу сүз мадьяр (венгр) телендә татарлардагы кебек үк яңгырый:**
а) балта;
б) мунча;
в) бакча.

**2 «Бамбарбия киргуду». Бу сүзләр кайсы кинофильмнан?**
а) «Бриллиантовая рука»;
б) «Операция «Ы» и другие приключения Шурика»;
в) «Кавказская пленница, или Новые приключения Шурика».

**3 Дәрдмәнднең чын исеме:**
а) Сәгыйть Рәмиев;
б) Шакир Рәмиев;
в) Закир Рәмиев.

**4 «Сезнең вакытыгыз чикле, аны кеше тормышы белән яшәүгә әрәм итмәгез». Бу сүзләрне кем әйткән?**
а) Стив Джобс;
б) Павел Дуров;
в) Билл Гейтс.

**Җаваплар: 1. а); 2. в); 3.в); 4. а).**

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде


**Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы**
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
**Индекс П2435**
**Тираж – 15318 данә**
**Газетага сертификат бирелде**
Заказ 347

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
**www.vatantat.ru**
**info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru**
**89179270040**

**Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)**
**П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)**
**П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)**
**П2435 (җомга саны)**

ТЕЛЕФОННАР
**222-09-70** – кабул итү бүлмәсе
**222-09-67** – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
**222-09-73, 222-09-69, 222-09-65** – баш мөхәррир урынбасарлары
**222-09-68** – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
**222-09-67** – дин, сәламәтлек
**222-09-64** – әдәбият, сайт
**222-09-66** – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
**222-09-65** – реклама бүлеге
**222-09-72** – бухгалтерия
**222-09-73** – компьютер үзәге
**221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә**

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
**R** тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
**N** тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+